PRESSA

1926–1991 ЕЛЛАРДА АЗАТ ХАТЫН 2021 СЕНТЯБРЬ № 9

СӨЕМБИКӘ

ISSN 0869-1398

ЯЛГЫЗ *иттең...* ачыктан-ачык

SOS! бала чәчен йолкый!

ЗАМАНА *Буратинолары* башсызлыкмы, чарасызлыкмы?

казан асабыз МӘҺӘР АШЫ

Аэлита ИБРАҺИМОВА: *«Әйткәнсең икән – эшлә!»*

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Мин әни булдым, әни!

Шушы сүзне әйткән мизгелдә барысы да үзгәрә! Аралар тагын да якыная, җылына, күңелләр бер-берсен сүзсез дә аңлый... Бер үк кичерешләр аша узганнарның якынлыгы башка аның. Сүзләр, хәрәкәтләр, теләкләр бөтенләй үзгә төсмер ала. «Менә әни ни өчен ул вакытта шулай дигән, шулай эшләгән (яки эшләмәгән) икән», – дип уйлыйсың... Барысы да мәңгелекнең үзе кебек гап-гади, чөнки син – Әни! Ә Әниләр инде бер телдә сөйләшә...

Өр-яңа проект башлыйбыз. «Мин әни булдым, әни!» дип атала ул. Бер фоторәсемдә өч буын – әниегез, сез һәм кызыгыз (улыгыз): буыннар чылбыры шулай тезелә!

Җылылык, яктылык, нур бөркеп торган мондый фотосурәтләр сездә дә бардыр – кушылыгыз!



Ләйсән ЮНЫСОВА

ТӨНГЕ ҖЫР

Еламачы, кызым! Балам, еламачы!
Әнә, кара, мырлап утыра соры мачы.
Ул да, ахры, балам, сине юатмакчы,
Еламачы, кызым, йокла. Еламачы.

Ә песинең күзе, кызым, шундый яшел.
Ә тизлеге, җитезлеге – инде яшен.
Уйлый бугай, сиңа карап, бәләкәчем,
Койрык белән сөртер идем, дип, күз яшен.

Ә койрыгы аның, кызым, шундый йомшак –
Ул кайчакта тиенгә дә кала охшап.
Син елмайсаң, кызым, балам, песи дә шат.
Син еласаң, ул да кала бугай каушап...

...Еламачы, кызым. Әйдә, йокла инде.
Әнә җиргә сиздермичә төн дә инде,
Кичке шәфәкъ күптән инде сулды, шиңде,
Күк түренә түп-түгәрәк ай да менде.
Песи йоклый. Йокламаучы син дә миндер.
Йокла, кызым, йокла, балам, йокла инде.

■ Безнең гаилә – традицион татар гаиләсе. Икебез дә авылдан булгангадыр, халкыбызның барлык йолалары, гореф-гадәтләре кечкенәдән күңелгә сеңгән. Улларыбыз тугач та, кызыбыз Зифа дөньяга килгәч тә, иң элек күркәм исем сайлап, исем кушу йоласын башкардык. Бәби чәе, сөннәт туйлары – алар безнең гаиләдә дә үтәлеп килә торган традицияләр. Елга бер тапкыр гаиләбез белән җыелып фотога төшү – монысы инде яңа заман йоласыдыр. Бергәләшеп шушы чарага әзерләнү, нинди киемнәрдән буласыбызны уйлашу безне тагын да берләштерә. Балалар алган бүләкләреңне онытырга да мөмкин, ләкин балачакта алган тәэсирләр күңелләреңдә мәңгегә сакланачак.

Алсу ФАЗЛЫЕВА.
Казан.

Фото: Анна Арахамия.

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2021



Фото: Ксения Богданова

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.

Баш мөхәррир
Л. Н. Маликова

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нурия Вәлиева, Искәндәр Гыйләҗев, Нәбирә Гыйматдинова, Айрат Зарипов, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Рафаэль Шәвәлиев, Равилә Шәйдуллина, Лотфулла Шәфигуллин.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77

Җитәкче урынбасары 222-09-78
Рәмзия Кашапова
Баш мөхәррир урынбасары 222-09-78
Гөлнур Хәсәншина
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова
Әдәби мөхәррир
Эльмира Закирова
Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Тышлыкта:
Аэлита Ибраһимова
Фото: Анна Арахамия

Мөхәррирләр
Чулпан Галиәхмәтова
Сөмбел Гаффарова
Алсу Шакирова
Фәгыйлә Шакирова
Верстка
Резеда Галиуллина
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Фотокорреспондент
Анна Арахамия
Гамәли хезмәткәрләр
Ильмира Сөләйманова
Виталий Матвеев

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Формат: 225х290 мм
Күләме 64 бит

Басарга кул куелды: 26.08.2021 ел.
Чыгу көне: 3.09.2021 ел.
Заказ Е-2975
Тираж 9591

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Басма Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр буенча федераль агентлык ярдәмендә нәшер ителә

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77

Язылу индексы
ПАП рәсми каталогы буенча:
Татарстанда П2204 (ярты еллык),
П8299 (берьеллык)
Татарстаннан читтә: П0279

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002

16+

PRESSA



Баш мөхәррир сүзе



Календарьда – сентябрь... Һәркайсыбыз өчен уку елының башы ул. Әйе, һәркайсыбыз өчен. Мәктәпне күптән тәмамласак та, без бит барыбыз да әниләр яки дәү әниләр... Берәүләрнең баласы быел тәүге тапкыр мәктәп бусагасын атлап керсә, икенчеләренең алдагы сыйныфка күчәчәк, ә кемнеңдер кызы яки улы (оныгы) инде югары уку йорты студенты. Яңалык ачуым түгел, бу юлны ике мәртәбә үткән әни тәҗрибәсеннән чыгып кына әйтәм: 1 сентябрь җиту белән безнең мәшәкатьләр дә бермә-бер арта... Баланы төрле секцияләргә, түгәрәкләргә йөртү: бию, бассейн, хоккей, музыка... (исемлекне дәвам итеп тормыйм, һәркемнең үзенеке, әмма күп вакыт ике-өч белән генә дә чикләнми әле ул!), төнгә кадәр дәрес әзерләүләр (бу иҗади процесс турында соцчелтәрләрдә җәй ахырында ук төрле видеолар йөри башлады: уенын-чынын кушсалар да, аларда хаклык юк түгел!)...

Журналыбызның беренче тышлыгында – Аэлита Ибраһимова – уңышлы бизнесвумен, әмма, беренче чиратта, ул да әни. Фотосессия вакытында да гел балалары турында сөйләде: «Улларым бик мөстәкыйль. Минем эшләр күп булгангадыр... Кайчак эштән шалтыратам: «15 минуттан бассейнда күнегүләрегез башлана, җыеныгыз», – дим. Подъезд төбенә килеп туктаганда, алар инде рюкзакларын тотып, әзер булып басып торалар...»

Әйе, бүгенге хатын-кыз барысына да җитешергә омтыла: ирләрдән калышмыйча эшләргә, балаларны тәрбияләргә, шәхес буларак үсәргә, менә диган хуҗабикә булырга... Ир-атлар өчен чыга торган «Esquire» журналының соңгы саны тулаем хатын-кызларга багышланган әнә. Баш редактор Сергей Минаев язуынча, бу санны ул ел ярым уйлап йөргән. Журналистлар Мәскәү Владивосток арасында йөрүче поездда сәяхәткә чыгып китәләр. Зур һәм кечкенә шәһәрләрнең, авылларның перроннарында гап-гади хатын-кызлар белән мәхәббәт, балалар, гаилә, ирләр тарафыннан җәберләнү, эш турында сөйләшүләр нәтиҗәсендә туган бу санның төп фикере – «Хатын-кыз – ил тоткасы». Ир-атлардан моны ишетү рәхәт бит?!.

Яратып,
Лариса МАЛИКОВА

Фото: Анна Арахамия

Безнең тышлыкта

«Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасында үзем кебек эшмәкәрләр, җитәкче ханымнар белән таныштым. Аларны күзәтеп, эш рәвешләрен, сөйләшүләр алып баруларын өйрәнәм. Күперләр салырга, яңа танышлар булдырырга ярдәм итәләр биредә.»



14
Аэлита
Алсу Шакирова

Заман һәм без

6 Замана Буратинолары
Чулпан Галиәхмәтова



18 Кем син? Кайдан син?
Гөлнур Хәсәншина



10 Игелек сукмагыннан
Мәдинә Авзалова

20 Чәчләр йолкыр чак?!.
Алсу Шакирова



24 «Шигырьләремдә чын мин»
Чулпан Галиәхмәтова

ЭЧТӘЛЕК

Татар дөньясы




26 Рафис киленнәре
Лилия Гәрәева



30 Морза Терегуловлар нәселе
Лирон Хәмидуллин

Мәдәни тормыш



36 Тамаша
Рафаэль Сибат

Яшәеш

42 Ялгыз иттең...
Гөлнур Сафиуллина



46 Назларымны кичер – соңардылар...
Эльмира Закирова

48 Тылсымлы шәрык әкияте
Рәмзия Кашапова

Хуҗабикә

57 Ханбикәләр сыны
Чулпан Юнысова

58 Бакча коралы тәртип ярата
Алсу Шакирова



60 Мәһәр ашы

ЗАМАНА БУРАТИНОЛАРЫ



Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА

«Золотой ключик, или Приключения Буратино» әкиятен барыбыз да белә. Хәтерлисезме, төлке Алиса белән мәче Базилио Буратиноның акчасы барлыгын сизеп алалар да аны таларга ниятлиләр. Буратинога Могҗизалар кыры турында сөйлиләр. Имеш, бу кырга барып акчаңны күмсәң, тылсымлы сүзләр әйтеп өстенә тоз сипсәң, икенче көнне яфраклары урынына алтын тәңкәләр булган агач үсеп чыгачак. Беркатлы Буратино алдакчылар сүзенә ышана һәм аларга ияреп байлыгын арттырырга китә. Ахыры нәрсә булып беткәнен беләсездер... Хәзер бу әкият бик актуаль. Бүгенге көн кырыкалдарлары акча арттыру ысуллары өйрәтә. Ә без, җәмәгать, ышанабыз.

Соңгы айларда бер-бер артлы финанс пирамидалары ишелә. Алар белән бергә кешеләрнең акчалары да яна – юкка чыга. Югыйсә беләбез – Мисырда гына пирамидалар гасырлар буе тора. Ә бу буш куыклар икътисад тарихында ничә тапкыр барлыкка килеп, ничә тапкыр шартлады. Замана алга барса да, җәмгыять тә, кешелек психологиясе дә үзгәрми. Цивилизация алга киткән хәзерге җәмгыятьтә дә бар мал-мөлкәтен финанс пирамидаларга тыгып, кәкре каенга сөялеп калучылар саны көннән-көн арта. Әле бит алдануын яшереп калдыручылар күпме. Уңыш белән генә бүлешәсе килә, уңышсызлык турында сөйләргә яратмыйбыз. Ирек тә (чын исемен күрсәтмәүне сорады) – шундыйлардан. Чәчәк аткан финанс пирамидасы хакында дусларыннан ишетә. Өч-дүрт ай эчендә акчаны бермә-бер арттыру теләге җиңә аны. «Бер танышым, финанс пирамидасына кереп, тиз арада машина алуы турында сөйләде. Минем дә машинаны яңартырга вакыт, әмма акча җитмәгәч һаман сузып йөрим... Акча күбрәк керткән саен, керемнең зуррак булачагын кабат-кабат аңлаткач, банкка барып, 1 миллион сум кредит алырга документлар тутырдым. Бәхетемә, айлык керемең аз дип банк ул кадәр күләмдә кредит бирмәде. Сораган сумманың яртысын гына алдым. Акчаны салгач, шәхси кабинетыма процентлар килә башлады. Кереп караган саен, шатланам... Күрәсең, коры саннарга карап кына шатланырга язган. Пирамида җимерелде дә куйды. Кредит алып каядыр салганымны хатыныма да әйтмәгән идем. Имеш, акчаларны кайтарып тоттырып сюрприз ясыйм. Ясадым инде сюрприз – ай саен 25 мең сум кредит түлисе бар. Әле ярый 500 мең сум гына дип үземне юатам. Зыян күрүчеләр чатында утырам. Анда нинди генә тарихлар язмыйлар. Берсе фатирын сатып, бар акчасын керткән. Хәзер әнә кеше фатирында көн күрәләр. Югыйсә бөтен нияте зуррак фатир алу булган. Гомере буе ипотека түлисе килмәгән... Бер атна буе күзе-

мә йокы керми дип яза. Кермәс тә шул, үзем дә ашаудан калдым. Ничек кенә хатынга сөйләп бирәсе дип борчылам. Сәламәт булып эшләргә генә язсын – бу бурычны түлисе бар».

Пирамида ничек төзелә?

Финанс пирамидасының төп алгоритмы нинди соң? Мәсәлән, Гали 100 сум сала, аңа 20 процент айлык керем вәгъдә итәләр. Галидән күреп (йә Гали күндереп) Бари да пирамидага 50 сум алып килә. Бу акчаның бер өлеше Галигә процентка китә. Алардан соң Сания тагын 100 сум сала. Аның акчасын Галигә, Барига һәм башкаларга процент итеп күчерәләр. Күрәсезме, пирамида үскән саен, беренче кертемнәр дә арта. Шуңа да мондый пирамидалар озак яши алмый. Иртәме-соңмы акча алып килүчеләр саны кими, ә иске «инвесторлар» армиясе күбәя һәм аларны «ашатып» бетереп булмый. Менә шул вакытта ул ишелә. Дөрес, оештыручылар һәм финанс пирамидасы башында торучылар өчен бу система су тегермәне кебек. Бик тиз акча җыялар да, эзсез югалалар. Аларның койрыкларын тоту бик авыр. Проект закон көчсез булган бер илдә, мәсәлән, Зимбабведа теркәлергә мөмкин. Акча агымын да дәүләт органнары контрольдә тота алмый. Шуңа да мондый финанс пирамидалары законсыз дип санала. «Финанс клубларын» ачып җибәрү өчен күп финанс кирәкми. XXI гасырда акча җыю өчен бары тик сайт та җитә. Сайт ясыйлар да, бөтен дөньяны яңгыратып пиар кампания башлап җибәрәләр. Блогерлардан реклама сатып алалар йә медиа шәхесләргә мөрәҗәгать итәләр. Чаллы эшмәкәре Эрик Гафаров спорт тотализаторларында акча эшләп, баю турында Россия футбол йолдызлары авызыннан әйттерде. Ниндидер Гафаровка караганда, танылган футболчыларга ышанып килүчеләр күбрәк, билгеле. Финанс пирамидаларын оештыручылар йә аның башында торучылар акча кертүчеләрен зиннәтле бай залларда җыярга ярата. Мактану, ышандыру, бәйрәм итүгә корылган бу чаралар, «остазлар» уздырган туры эфирлар белән социаль челтәрләр ленталары тула. Һәм бу чираттагы



Икътисад фәннәре докторы, профессор, КФУ проректоры Марат САФИУЛЛИН: «Алданмауның бердәнбер юлы финанс гыйлемле булу һәм фикерле белү».

корбан: «Бөтен кеше дә бу супер кәттә проектта икән, бер мин генә, ахмак, калганмын», – дип, акчасын тотып тизрәк йөгерсен өчен эшләнә. Һәм күпләр бу кармакка эләгә дә.

– Финанс пирамидалар яшәвендә берничә фактор уйный. Психологик, мәдәни һәм иң соңыннан гына икътисадый сәбәп бар, – ди икътисад фәннәре докторы, профессор, КФУ проректоры Марат Сафиуллин. – Бу феномен кешеләрнең көчсезлеген файдалана. Ә ул безнең балачакта ук тәрбияләнгән. Мәсәлән, һәркем диярлек нинди дә булса могҗизага ышанып яши. Без укыган әкиятләр дә шуңа корылган. «По щучьему велению» әкиятендә мич башында әмер биреп кенә яткан Емеляны күпләребез белә. Хәзер цифралы заманда да әллә нинди зур акча отулар турында һәрвакыт сөйләп торалар. Биткоин, блокчейн кебек электрон акчалар барлыкка килү дә роль уйнады. Һәм тагын бер җитди инструмент – гипнозга якын булган нейролингвистик программалаштыру. Маркетологлар уйлап чыгарган бу инструмент кешенең психоэмоциональ хәленә тәэсир итеп, алдан программалаштырылган гамәлне аннан кылдыртудан гыйбарәт. Әйе, кешене программалаштырырга мөмкин. Әлеге программа безнең компьютерларда да бар. Игътибар итсәгез, интернеттан нидер эзлибез икән, браузерларыбыз, социаль челтәрләрдәге ленталарыбыз шушы товар төрләре белән тула. Компьютер безне өйрәнә, психотибыбызны билгели. Әлегә бу безнең тарафтан рекламачыларның бәйләнүе дип кабул ителә, әмма технологияләр һаман алга бара. Киләчәктә моны безнең карар дип кабул итә башлаячакбыз – ясалма интеллект бик тиз үсә. Ә кешене программалаштыру өчен компьютер мониторы аркылы сөйләшү дә җитә. Финанс пирамидасын оештыручылар бу инструментны бик яхшы куллана. Аннан тагын бер психологик фактор бар. Әлеге система күп кеше җыюга корылган. Бер кеше керә икән, ул салган акчаларын кире чыгару һәм күбрәк процентлар алу өчен дусларын, туганнарын, танышларын тарта башлый. Ягъни үзе батмас өчен башкаларны батыра.

МММ нәрсәгә өйрәтте?

Советлар Союзында финанс пирамидалары булган дип әйтә алмыйбыз. Акча агымы, акча җыюның яңа алымнары бик нык контрольдә тотылган. Дөрес, азартлы уеннар, легаль булмаган кредит бирү формалары кебек «кара бизнес» яшәгән, әмма аның күләме ил икътисадында бик аз, бары 3–4 процент булган. Үзгәртеп кору елларында контроль югала, ваучерлар чыга, илдә кризис. Шул вакытларда МММ, Хопер барлыкка килә. Профессор әйтүенчә, алар башта дөрес ният белән оеша, приватизация өчен чыгарылган ваучер җыюны максат итеп куялар, әмма тора-бара халык талауга кайтып кала. Закон белән идарә ителмәгәнлектән, ул вакытта рупор булган телевидениегә барып керәләр. Бразилия сериаллары арасында күрсәткән МММ рекламаларында Леня Голубковның хатынына тун, сапоги алып бирүләрен әниләребез генә түгел, без дә шаккатып караганыбыз хәтердә әле. Ул бит ирләр кырылып эчкән вакытта! Акча булмаган чорда! Шуңа күрә дә финанс гыйлеме булмаган халык, аптыраганнан һәм могҗизага ышанып капкынга ки-

Фото: www.pixabay.com

Финанс пирамидалары килеп чыгуының төп сәбәбе – кешеләрнең җиңел акчага мөкиббән булулары.

леп эләгә. Ул елларда Леня Голубков, финанс пирамидасын төзегән Сергей Мавроди милли геройга әйләнә. Аны кулга алгач та, геройларын иреккә чыгаруны сорап, халык урамга чыга. Тарих кабатлана. Хәзер әнә «Финико» башлыгы Кирилл Доронинны иреккә чыгаруны таләп итеп петиция оештыралар. Чөнки пирамида башында утырганнар корбаннары китергән җиңел акчаны «ашап» өйрәнгән.

Дәүләт эшендә эшләп йөргән гаилә дусларыбызның финанс пирамидасына кереп киткәнен сизми дә калдык. Бер генә түгел, икешәр пирамидада утырды алар. Компаньон булырга чакыра башлагач, әлеге системаның озак яшәмәячәген, тизрәк акчаларын чыгаруларын, счетларындагы процентларның көле күккә очачагын аңлатырга тырыштык. Ә аларның җавабы бер һәм ныклы иде: «Финанс пирамидалары 90 нчы елларда гына булган. Ә без инвестицион проектта катнашабыз. Монда һава сатмыйлар, ә акчаларны биткоиннарга салып арттыралар». Гаилә башлыгы эшеннән китте. Читтән акча килеп ятканда, нигә әле дәүләткә бил бөгәргә, янәсе. Җитмәсә, хатынын да эшеннән чыгарга мәҗбүр итте. Дөньяның артына тибеп, кредитлар ала-ала ярты ел рәхәттә яшәп калдылар. Дөнья тирәли сәяхәткә чыгып китәргә иде ниятләре. Кыйммәтле круизлар эзләгәндә «инвестицион проектлар»ы ишелде дә төште. Түләнмәгән кредитлары гына калды. Инвестицияләр ярдәм итми, эш эзлиләр. Ә бит чынчынлап инвестор булуларына ышанганнар иде, дөресрәге, ышандырганнар иде. 90 нчы еллардагы финанс пирамидалары хәзергеләреннән әнә шуның белән аерыла да – халыкны яңа сүзләр белән җәлеп итәләр. Ә безнең халык колак ишетмәгән, җитмәсә, шунда үзенең дә катнашы булган яңа терминнарны үлеп ярата. Югыйсә авыл халкы инвесторның кем икәнен белергә тиеш тә кебек.

– Финанс пирамидалары цифралы акчалардан торган битлек кия. Вакытында тәвәккәлләп биткоиннарга акча салган кешеләр, үз акчаларын биш йөз, бер мең тапкырга арттыра алды. Менә шушы феномен намуссыз кешеләр тарафыннан кулланыла. Хәзер биткоиннар бәясе артык сикермәсә дә, миф яши. Финанс пирамидалары эшчәнлеген Россия Үзәк банкы күзәтеп тора. Әмма алардан качар өчен «эшмәкәрләр» акча агымын башка юридик кырга чыгара. Бер-берсе арасындагы акча алыш-бирешләрен биткоиннар артына яшерә. Цифралы акчалар әле тулысынча закон белән идарә ителми, салымнардан да качып котылырга мөмкин. Финанс хуҗалыклардагы операцияләр керемен контрольлек иткән органнар күзеннән шул рә-вешле яшереп була, – ди Марат Сафиуллин. Акчасын, имеш, биткоиннарга салып алганнар шулай итеп инвесторга әйләнә. Монысы финанс гыйлеме булмаганнар ышанган факт. Әле бит бу системаның алдауга корылганын белеп барганнар да бар. Һәм алар икеләтә күп. Хәзер барлык заманы. Мәзәктәге кебек: совет чорында акча бар, әйбер юк иде, ә хәзер бар нәрсә дә бар, акча гына юк. Гаджетлар, кыйммәтле машиналар, экзотик ризыклар, инстаграмда күрсәтелгән зиннәтле тормыш – барысы да күп акча сорый. Җитмәсә, халык муеннан кредитка баткан. Бар нәрсә кредитта: фатир, машина, тун, хәтта кулга тотып йөргән телефон да. Кредитларыннан котыласы килгәннәр теләсә нинди саламга тотынырга әзер. «Вакытында чыгачакмын, алданмыйм, мин бит күрше Гыйльмениса әби түгел», дип барып керә ул тозакка һәм чыга алмый. Әле бит финанс пирамидасына кредит алала килеп кергән «инвестор»лар бар. Бу адымга барганчы дөньяга танылган гуру-инвесторлар тәҗрибәсен укып карамыйлар. «Кредит алып инвестициягә тыгу – җүләрлек, – ди икътисадчы Марат Сафиуллин. – Бу мантыйкка сыймый. Төптән фикер йөрткән кеше болай эшли алмый».

Финанс пирамидаларының иң майлы калҗасы – кертелгән акчаларны ел буена 300% процентка кадәр үстереп бирәбез дигән вәгъдәләре. Финанс гыйлеме, анализлый белү сәләте булмаганнар өчен менә дигән бушлай сыр кисәге бу. Реаль икътисадта мондый үсеш була аламы, дип кызыксынам.

– Кызганычка, мөмкин, – ди профессор.

– Алайса бар кеше дә Уоррен Баффетка әйләнә ала?

– Моның өчен инструментлар бик аз. Даими рәвештә мондый керем алу мөмкин түгел. Әйе, инвестицияләрдә байлык туплаган инвесторлар бар, мәсәлән, бөтен дөньяга танылган Кирк Керкорян, Джордж Сорос. Әмма алар бармак белән генә санарлык, чөнки моның өчен талант, белем һәм тоемлау, бигрәк тә алдан фаразлый белү сәләте кирәк. Теләсә кем бу операцияләрне башкара алмый. Әмма икътисадта мондый күренешләр бар. Мәсәлән, премиум-класстагы брендлар, француз шәрабы, швейцар сәгатендәге маржа меңнәр белән санала...

Ничек алданмаска?

Гади итеп әйткәндә, дөньяга танылган брендтан баш җитмәслек керемнәр алырга була. Ә моның өчен хуҗалары күпме эш башкара. Акча күктән яумаганын белә алар. Ә менә Россиядә, соңгы вакытта Татарстанда чәчәк аткан пирамида хуҗалары үзләрен Керк Керкоряннан да кәттәрәк итеп күрсәтә. Мондый керемне алар еллар буена миллионнарча кешеләргә вәгъдә итә. Соңгы елларда мондый вәгъдә бирүчеләр Казанда ешайды. «Икътисадый яктан уңышлы төбәк феномены инде бу, – ди Марат Сафиуллин. – Беренчедән, Казанда хезмәт хакы дифференциациясе, ягъни байлар белән башка катлам кешеләренең керем аермасы зур. Икенчедән, бу республикада яшәүчеләрнең ирекле акчалары күбрәк булуы турында да сөйли. Финанс пирамидасы яши икән, димәк, халыкның соңгы акчалары гына түгел, күңел ачу өчен акчасы да бар. Аннан соң Казанны бе-

ләләр. Бу да намуссызлар «уен»ы өчен кулай. Шуны да әйтергә кирәк: башкалада халык та шомарган. Орлык уңдырышлы җирдә генә тишелә. Ә иң төп сәбәп, мөгаен, халыкның беркатлы булуыдыр. Безнең менталитет шундыйрак. Кешеләргә тиз ышанабыз. Ышаныч – иң зур капитал. Ул югала икән, бик күп социаль һәм финанс кыенлыклар килеп туачак».

Татарстан Эчке эшләр министрлыгының Икътисадый куркынычсызлык һәм ришвәтчелеккә каршы тору идарәсе башлыгы Руслан Дәвлетьяров белдерүенчә, Татарстанда финанс пирамидалары билгеләре булган 50 оешма бар. Алар халыктан 1 млрд. сум акча җыйган. Быел алардан зыян күрү буенча 126 гариза кергән, зыян күләме 143 миллионнан артык. (Статистика әлеге язма язылган вакыт өчен.) Финанс пирамидаларына тик торганнан гына җинаять эше ачып булмый, шуңа да алар «үсә». Җинаять эше башлар өчен җинаять булырга тиеш. «Ә кешеләрне җыеп, үз проектың турында сөйләү, акча җыю җинаятькә саналмый. Мәсәлән, бер агай авылда күпер салырга ниятли. Ул бизнес-план төзи белми. Авылдашларын җыя да бу хакта сөйли. Алар аңа акча җыеп бирә. Бу бит җинаятькә керми. Әгәр дә бу процессларны башында ук туктатсаң, бернинди инвестицион проектлар гамәлгә аша алмаячак. Агай акча җыеп, авылдашлары алдында үз бурычын үтәмәгән очракта гына җинаять килеп туа. Финанс пирамидалары белән дә шул ук хәл», – ди профессор. Дөрес, дәүләт бу мәсьәләләрне хәл итүдән читләшергә тиеш түгел. Дәүләт Думасында финанс пирамидалары эшчәнлегенә кагылышлы канун проекты әзерләнде, әмма аны карау, камилләштерү һәм кабул итү яңа чакырылыш депутатлары өлешенә калды.

Әлегә исә бары тик үзеңә ышанырга. Нәфесеңә хуҗа булырга. Финанс пирамидалары белән инвестицион проектларны аера белергә өйрәнергә. Ә бу бик гади. Акча җыеп, сездән корбан ясарга теләүчеләрнең иң беренче билгесе, язмадан аңлагансыздыр инде, табигый булмаган зур процентлар вәгъдә итү. Оешманың лицензиясен карагыз. Кагыйдә буларак ул, әйткәнемчә, чит илдә теркәлә. Әгәр дә җитди финанс проект икән, аның, һичшиксез, бизнес-планы булырга тиеш. Оештыручыларның шәхесен ачыклагыз. Аның абруе, биографиясе нинди? Җитәкченең тормыш юлы күп нәрсәләр хакында сөйли. Туганың йә танышың сөйләгәнгә генә акча илтеп салырга кирәкми. Син бит аңа бурычка бирмисең. Ә финанс пирамидалары шуның белән алдыра да. Оештыручылар үз йөзләрен югалта да, гади кешеләр аркылы акча җыя.

«Финанс пирамидасының тагын бер әһәмиятле билгесе – кешеләрне баетырга тырышуы, – ди Марат Сафиуллин. – Аларга мине кайгырту нигә кирәк? Менә шушы сорауга җавап табарга тырышыгыз. Әгәр баю өчен схемалары бар икән, нигә әле алар сезне дә баетырга тырыша? Чөнки ул башкача эш йөртә белми, аның бөтен нияте сезнең хисаптан баю һәм якыннарын баету. Бары шул гына. Калганнар аның өчен беркем түгел, ул аларны ике дә уйламыйча ярык тагарак янында калдырачак. Мин бик уңышлы компания җитәкчесен студентлар белән очрашуга чакырдым. Студентларга ничек баеганыңны сөйлә әле, дидем. Ә ул миңа: «Марат, син акылдан яздыңмы әллә?! Мин беркайчан да һәм беркемгә дә бу хакта сөйләмәячәкмен. Аннан соң ул Полишинель серенә әйләнәчәк һәм миңа керем килми башлаячак», – диде. Һәм мин аны аңлыйм. Һәр эшмәкәрнең үз финанс сере бар. Ә финанс пирамидасы ул эшмәкәрлек түгел.

Җинаять эше ачылган очракта да «финанс клублары» төзүчеләрне генә җаваплылыкка тарталар. Соңгы хәлләр белән бәйле арадашчыларны, ягъни пирамидага керергә өндәп йөрүчеләрне дә җаваплылыкка тартуны күздә тоткан канун кабул итү турында сүз бара. Алар да бит җинаятьче. Алдап талаучылар пычак тотып талаучылардан берничек тә аерылмый. Әле әхлакый яктан куркынычрактыр да! Туганлык, дуслык мөнәсәбәтләрен кулланып, чоңгылга өстериләр. Ә үзләре ярда калырга тырыша. Менә шундый кешеләрдән саклану, алданмас өчен бердәнбер юлны күрсәтә икътисад фәннәре докторы Марат Сафиуллин. «Икътисадый үсеш өчен капиталистик стройны сайлаганбыз икән, барыбызга да финанс белемле булу зарур. Бары тик белемле һәм фикерле белгән кешеләр генә алданмаячак. Билгеле, намуссыз кешеләр менә шундый проектларны булдырмасын өчен, дәүләт тә бар көчен куярга тиеш».

Финанс пирамидалары «Финико», «Frendex», «Антарес» белән генә туктап калмас. Эшләмичә генә акчалы булырга, бушка килгәнне бик яратабыз шул. Нәфес тә җитәрлек. Нәкъ шундыйлар өчен дә инде пирамидалар. Әмма, беләсез, бата башлагач, Нух пәйгамбәр көймәсенә утырып калучылар бик аз.



Рамил ГАРИФУЛЛИН,
психология һәм белем бирү институты доценты психология фәннәре кандидаты

Финанс пирамидаларының халыкны психологик яктан җәлеп итүендә берничә сәбәп бар. Беренчедән, хәзер иректә акчалар барлыкка килде. Икенчедән, пандемия вакытында социаль челтәрләр роле кисәк кенә артты. Онлайн рәвештә дә кешеләргә җиңел генә тәэсир итеп була. Ә кешеләрнең бик тиз һәм могҗиза ярдәмендә баеп китү теләге һәрвакыт бар. Хәзер бигрәк тә кеше муеннан кредитта – бурыч коллыгында. Тагын бер фактор: кредитны бик җиңел генә алырга мөмкин хәзер. Акча булмаса, проблема да булмас иде. Акчаны җайлы гына кулга төшерергә була икән, нигә әле аның белән уйнап алмаска?! МММ очрагында кредитлар юк иде. Ул пенсионерларның җыйган акчасы исәбенә үсте. Ә бүген финанс пирамидалары артуга кредитлар бик зур роль уйный.

ИГЕЛЕК СУКМАГЫННАН

...Моннан ун еллар чамасы элек, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил итеп сайланган Сәрия Харис кызы Сабурская турында: «Ул аның Аллаһы Тәгалә тарафыннан сынау итеп бирелгән язмышыдыр», – дип язган идем. Әле дә исемдә, игътибар үзәгеннән аз гына да китмәгән шушы җаваплы вазыйфага алынуына ел да үтмәде, ә инде халык арасында аның «безнең кеше» дигән даны таралып та өлгерде. Шуннан соңгы чорларны, халык яклаучысы катнашында узган берсеннән-берсе җитди чараларны күз алдына китерә, саный башласаңмы?! Аның республика, ил язмышы белән үрелеп барган тормышы ярларыннан чыгып, ярсып аккан елгаларны хәтерләтә. Һәр көне бер елга торырдай вакыйгалары белән күңелгә сеңеп калган ул мизгелләр һич онытылмый.



Мәдинә АВЗАЛОВА



Гәрчә без аның белән эш турында сөйләшмәскә сүз куешкан булсак та, барып чыкмады. Чыннан да, ничек инде бөтен гомерен яраткан эшенә багышлаган кеше шул турыда сөйләми түзә алсын?! Ә яраткан эше нәрсә дисез? Әйе инде, башкалар эшли алмаганны үтәүгә алыну, күзеңә карап ярдәм сораучыларны кире бормау, булдыра алганча булышу... Эше шул булганга түгел, йөрәге кушканга эшли ул боларны. Шулай булмаса, каршысында очраган киртәләрне үтеп чыга алмас иде. Дистәләгән ишекне кагып, өметләре өзелгәннәрнең үтенечен дә канәгатьләндерә алмас иде.

«Безне эшләтеп үстерделәр»

Үткәндә калган балачак еллары, яшьлек чоры кыяр-кыймас кына тормыш юлына аяк басып килгән кыз бала өчен үзе бер зур чыныгу мәктәбе була. «Мин – гади бер эшче гаиләсеннән», – ди ул горурланып. Бу сүзләрнең мәгънәсенә тора-бара төшенәм. Дөнья мәшәкатьләрен, бетмәс-төкәнмәс авырлыкларын аның шикелле кечкенәдән кичерсәң-татысаң гына, кеше хәленә керер халәткә ирешәсең икән ул.

Алар гаиләдә өч бала үсә. Әтисе Харис Мөхәммәтҗанов гомер буе «М. Горький исемендәге Яшел Үзән заводы»нда тәэминатчы булып эшли. Ә әнисе Мәрьям апа – техничка. Ул да әтиләре шикелле иртә дими, кич дими, эштә. Кыз әнисе белән бергә подъездларны җыештыра, кулыннан, көченнән килгәнчә ярдәм итәргә тырыша. Күреп тора, әнисенә авыр... Ул чагында хәзерге кебек гаиләгә социаль, матди ярдәм күрсәтү дә, мәктәпкә бала хәзерләүдә хөкүмәт булышлыгы да юк иде бит. Бүгенге кебек мәктәпләрдә ашханәләр дә юк иде. Дәфтәр-китапларың арасына бер телем ипи кыстырып китәсең дә, көне буена шуның белән шул. Әниләренең бөтен хыялы – балаларына югары белем бирү: «Күрермен микән шул көнне бер...» Шөкер, күрә: кызының Казан педагогика институтына укырга кергәнен дә, аны тәмамлап, югары белем алып чыгуын да күрергә насыйп

була. Әмма үзенең генә чәчәк кебек гомере һич уйламаганда-көтмәгәндә өзелә.

– 1980 елның 19 июле иде, – дип искә ала йөрәгенә мәңгелек җәрәхәт уеп калдырган ул кайгылы вакытларны Сәрия Харисовна. – Җәйге Олимпиада уеннары башланган көн. Бөтен җирдә тантаналы музыка яңгырый. Ә без әни белән хушлашабыз...

Тормыш юлының узган кадәресе әнә шулай югалту-табышлардан тора аның. Текә-кискен борылышлардан торган ул юлларда адашып калырга да күп кирәкми. Тик кыз андыйлардан – авырлыкта сыгылып төшә, бирешә торганнардан түгел. Йомшак, киң күңеле белән бер гаҗәпләндерсә, үҗәтлеге, үз сүзен сүз итә белүе белән янә хәйран итә ул әйләнә-тирәдәгеләрне. Урта мәктәпне уңышлы тәмамлаган кыз Казан дәүләт университетының тарих-филология факультетына документларын биреп карый, конкурстан үтми. Ләкин максатыннан кире кайтмый. Вакытлыча тукталыш кына ясый. Ә тукталыш дигәне... әтисе эшләгән завод. «Мине электрокар йөртүченең укучысы итеп алдылар да, дүрт ел шоферларга чакрымнар санап утырдым, – дип елмая ул хәзер. – Булачак ирем Вячеслав белән шунда таныштым. Без аның белән бик матур яшәдек».

Ул гомеренең институтта укыган, мәктәптә пионер-вожатый, озайтылган көн төркемендә тәрбияче, аннары тарих укытучысы вазыйфасын үтәгән, комсомол һәм партия эшендә кайнаган елларын сагынып, үзгә бер җылылык белән искә ала. Ни дисәң дә, бу аны шәхес буларак формалаштырган мөһим чор. Әнә шулай баскычларны сикереп үтмичә – түбәннән күтәрелгәндә генә беләсең ул тормыш кадерен.

Йөрәге кушканга...

Кайда гына һәм нинди генә эш башкармасын, һәрнәрсәгә үз карашы, үз фикере булган, яңалыкка омтылган яшь белгечне Яшел Үзән районының мәгариф бүлеге мөдире итеп куялар. Илгә кискен үзгәреш җилләре алып килгән иң авыр чорлар була ул.

– Бу өлкәдә эшлисе эшләр җитәрлек иде, – ди Сәрия Харисовна хәтер йомгагын сүтә башлап. – Балалар бакчалары, мәктәпләр җитми. Һәр эшнең – үз җае. Ә теләк булганда җае да чыга, юлы да ачылып кына тора икән аның. Мин эшләгән җиде ел эчендә – ә бу җәмгыятебезнең астын-өскә әйләндергән 90 нчы еллар – районда ун яңа мәктәп салынды, гөрләп бакчалар эшли башлады. Мәктәпләргә балалар туплый башлагач, аларны йөртү проблемасы килеп чыкты. Ул чагында колхозлар иде бит әле. Транспорт мәсьәләсен шул хуҗалыкларның җитәкчеләре белән хәл итәргә туры килде. Ул вакытларда ял да диелмәгән, көн дип тә, төн дип тә торылмаган. Машинага утырасың да чыгып китәсең... Авылларны йөреп чыгасың, мәктәп директорлары белән очрашасың. Руль артында – ирем. Ул гомер буена терәгем, таянычым булды. Кыен чагымда мин гел аңа сыена, аның белән киңәшләшә торган идем. Төпле, акыллы, гаҗәеп тыйнак һәм сабыр кеше иде... (43 ел күзгә-күз карашып, кулга-кул тотынышып яшәгәннән соң, кинәттән вафат булган ире турында

Кеше мәшәкатьләре артыннан чабу җиңел эш түгел. Ул бик сирәкләргә бирелә.

сөйләгәндә аның сагыш тулы зәңгәр күзләренә яшь тамчылары мөлдерәп тула.)

Замана таләбеме, әллә йөкләнгән вазыйфасына мөнәсәбәте шул дәрәҗәдә җитди-җаваплы булганмы, ул кайсы мәктәпкә нинди ярдәм кирәклеген, хәтта кайда, нинди такта черегән булуына кадәр белә. Бер генә проблема да аннан башка хәл ителми... Ә бит республикада капиталь ремонтка мохтаҗ мәктәпләр бүген дә җитәрлек. Сәрия Сабурская әйтмешли, «балалар җылы мәктәптә укырга тиеш». «Балалар игътибар үзәгендә булырга тиеш...» Монысын да ул әйтә. Җитәкче буларак түгел, ике бала анасы буларак әйтә. Мисаллары бихисап. Хатыны йөрәк өянәгеннән үлеп, яңа туган баласы белән калган бер әти кешенең аның янына килеп: «Үстерә алырмынмы, игътибарым җитәрме?» – дип өзгәләнүләрен әле дә онытa алмый ул. «Әллә әни тәрбиясе җитмәде, әллә әтисе артык иркәләде, кыз 8 яше тулганда бик дуамалга әйләнде, – дип искә ала Сәрия Харисовна моннан егерме ел элек булган хәлләрне. – Мәктәптә – укытучылар, өйдә әтисе уртак тел таба алмый гына бала белән. Аңлашыла инде, мондый ситуациядә психологлар кирәк. Кыз ана назыннан мәхрүм – аның нәрсә икәнен белми. Ул чагындагы сөйләшүләр... Шуннан соң ике дистә ел узып китте менә. Мин ул кыз баланы азга гына да күз уңыннан ычкындырмадым. Без аның белән электрон почта аша әле дә хәбәрләшеп торабыз. «Пешекче буласым килә», – дип язды. Хәзер әнә техникумны тәмамлап килә инде».

Мондый балаларга мөнәсәбәт үзгә булырга тиешлеге турында ул гел әйтә килә. Бер караганда, бу аның эше түгел. Мәгариф бүлеге мөдире бит ул, социаль хезмәткәр дә, психолог та түгел. Әмма Сәрия Харисовна, бая әйткәнемчә, вазыйфасы таләп иткәнгә түгел, йөрәге кушканга шулай эшли. Ятим баланың фатирын ремонт-



Мәрьям белән Харис Мөхәммәтҗановлар уллары Ирек, кызлары Сәрия белән. Артта – Харисның сеңлесе Сатирә.

«Әйттең исә – эшлисе!»

Бу – аның тормыш кагыйдәсе. Балаларын да ул шуңа өйрәтә.



Сәрия Харисовна ире Вячеслав, оныклары Булат, Лиза, Настя белән.

ларга булышу да, кыен хәлдә калган әби-бабайларның ипотека түләүләрен киметү мәшәкатьләре белән чабу да... Барысы, барысы да башкача булдыра алмау галәмәте.

Өстән яхшырак күренә

Бәлкем шуңадыр да Сәрия Сабурскаяны 1993 елда Яшел Үзән районы һәм шәһәре хакимите башлыгының социаль һәм милли мәсьәләләр буенча урынбасары итеп чакыралар. Илдә үзгәртеп корулар башланган вакыт. Моңарчы күз күрмәгән, колак ишетмәгән яңа оешмалар, социаль тәэминат, инвалидларны тернәкләндерү үзәкләре, ялгыз карт-карчыклар өчен йортлар, ятимнәрне вакытлыча яшәтеп тору өчен приютлар оеша-төзелә башлый. Бу игелекле чараларны башлап йөргән әңгәмәдәшем: «Здравушка» – без салган тернәкләндерү үзәге», – дип горурланып та куя.

2001 елда аны Татарстан Министрлар Кабинеты Аппаратының Социаль үсеш бүлеге җитәкчесе итеп билгеләләр. Бу вакытта хөкүмәт башлыгы булып торган Рөстәм Миңнеханов аны үзе чакыра. Зур эш, олы дәрәҗә... Кемгәдер ул үсеш, карьера булып тоелса, төрле эшләрдә эшләп, төптән күтәрелгән, тормышны энә аша күзләгән кеше өчен бу күтәрелү халыкка тагын да якынаю, кулына тапшырылган вәкаләтләрне мохтаҗлар файдасына җигү дигәнне аңлата: «Өстән бит яхшырак күренә».

2010 елның июлендә аның хезмәт биографиясенә янә бер яңа юл өстәлә. Шул көннән, шул сәгатьтән ул – Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил. Гомер буена тугры калган тормыш кыйбласы – яшәү мәгънәсе дә шул бит инде аның: кеше хокукларын яклау! Ә ул бик тә киң кырлы. Мөрәҗәгать итүчеләрнең сорау-үтенечләренә караганда, ул яшәешнең бөтен өлкәсенә кагыла шикелле: хезмәт өлкәсендә булган хокукларны бозу, хезмәт хакын вакытында түләмәү, эш урынындагы бәхетсезлек очраклары, эшкә урнашудагы авырлыклар, яшәү өчен яраксыз булган йортлардан кешеләрне яңа торакларга күчерүдәге кыенлыклар, тиешле медицина ярдәме ала алмау, инвалидларның тормыш шартларын яхшырту һәм эшкә урнаштыру, армия сафларында хезмәт итүчеләрнең эш урыннарын саклау, солдат егетләребезнең исәнлеген-иминлеген күзәтеп тору...

– Сезнең белән колониягә барганымны хәтерлим...

Ул шунда ук сүземне эләктереп алып, бүгенге көннәргә кайта. Вәкаләтле вәкил 2 нче һәм 19 нчы колонияләрдә булып, элеккеге наркоманнар белән очрашып кайткан икән. 2019 елда республикада мондый проблемасы булучылар өчен махсус программа эшли башлаган. Аны гамәлгә ашыру әнә шул тимер рәшәткәле, тимер ишекле урыннардан башлана.

– Аларның һәркайсының гаиләсе, якыннары бар. Һәрберсенең күңелендә югала барган өмет яши. Сүнәм дигән шул өметне яңадан кабызып җибәрергә, балаларны – әтиле, хатыннарны ирле итәргә булышабыз. Тормышка кайтарабыз. Җәмгыятебезнең иң зур кыйммәте, байлыгы – кеше булуын онытмыйк!

Ул колачлаган эшләрне санап бетерү мөмкин түгел. Сәрия Харисовна «Игелекле эшләр» хәйрия фонды, кризис үзәкләре белән алып барылган проектлар турында да искә төшерә. «Никадәр төрле, шуның кадәрле кызыклы», – ди ул эшләренә нәтиҗә ясагандай.

Гаилә – ул күңел учагы.

– Минем өчен ул шулай, – ди әңгәмәдәшем. – Бик авыр вакытлар була. Кайтып, эч серләреңне бушатасың да, җиңеләеп, тынычланып китәсең. Ireңнән, балаларыңнан гайре сине тагын кем шулай аңлый?!

Ире юк инде... Ә менә балалары – Алексей белән Татьяна, өч оныгы янында, гел янәшәдә. Аларны: «Әйткәнне – эшлисе!» – дип үстергән әни җитәкче урыннарда эшләгән балаларыннан бик канәгать бүген. Тәрбиялеләр, игътибарлылар. 12 яшьлек оныгы Булатның көненә икешәр мәртәбә дәү әнисенең хәлен белешүе үзе үк инде күп нәрсә турында сөйли.

...Игелек җирдә ятмый, дибез. Яшәү рәвеше итеп игелек сукмагын сайлаган Сәрия Харис кызы Сабурская өчен дә ул шулай. Әйе, кылган игелегең сиңа икеләтә әйләнеп кайта. Кайчандыр син булышкан, авырлыктан чыгарга ярдәм иткән кешеләрнең олы рәхмәте булып, балаларының җылы, якты мөнәсәбәте, чиксез яратуы булып... Димәк, тормыш заяга узмаган!

РЕДАКЦИЯДӘН: Бик күп мактаулы исемнәр, бүләкләр иясе, философия фәннәре кандидаты, журналның редколлегия әгъзасы Сәрия Харис кызы САБУРСКАЯны олы юбилее белән котлыйбыз! Гаҗәеп авыр һәм катлаулы эшендә уңышлар телибез!

МОНДА КАНАТЛАР КУЯЛАР

6–8 сентябрьдә Казанда Татарстан эшлекле хатын-кызларының VI форумы уза. Форумга килүчеләр өчен бизнес-тренингның автор программасы эшләнгән, мотивацион чыгыш ясаучыларның иң яхшылары чакырылган. Ике көн эчендә дустанә мөнәсәбәтләр урнаштыру да, Татарстанның традицияләре, мәдәнияте, тарихы белән танышу да каралган. Эшлекле ханымнарны бизнес-сәяхәт тә көтә.

«Форум – бер урында гына утырып торырга яратмаучылар, үз өстендә даими эшләүчеләр һәм дөнья буйлап партнерлар эзләүчеләр өчен. Хатын-кыз яшәү өчен бизнес төзи, шуңа да ул аның белән яши, бөтен җанын биреп эшли, – ди «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты Лиана Баһавиева. – Шуңа да форумның символын ясарга кирәк булса, канатлар сайлар идем, чөнки бизнес безне канатландырырга һәм рухландырырга тиеш».

Менә инде алтынчы тапкыр бу форумда берничә йөз хатын-кызга канатлар куялар. Бизнесын, карьерасын башлап җибәргәннәр, очрашып, бер-берсе белән таныша, тәҗрибә уртаклаша. Быел ул үзенчәлекле форматта уза. Эшлекле ханымнарны иммерсив бизнес-сәяхәткә чакыралар.

«Форумга килеп, көне буе тыңлап, язып кына утыру бик күңелсез ул. Без бит хатын-кызлар! Безгә һәрвакыт эмоцияләр кирәк! Хәтта бизнеста да. Шуңа башка төрле форма сайладык. Россиянең төрле почмакларыннан килгән көчле спикерларыбыз үз чыгышларына катнашучыларны да җәлеп итәчәк. Мәсәлән, психолог, финанс коучы Лили Гилем мастер-классында медитация уздырачак. Шәхси үсеш буенча халыкара тренер, Россиянең Энтони Роббинсы булган Дмитрий Васильевны да утырып кына тыңламаячакбыз. Шулай ук секцияләрдә коуч, бизнес-тренер Алексей Свободянюк, ТОП-стилист Виктория Колпакова, туризм буенча эксперт Юлия Рыбакова рухландырачак. Шуңа да без форумны бизнес-сәяхәт дип атадык. Моннан тыш чарага Россиянең төрле төбәкләреннән дә эшмәкәр хатын-кызлар килә. Алар үз төбәкләре, андагы атмосфера турында сөйләми калмас. Шулай итеп Россия буенча сәяхәт итәчәкбез», – ди Лиана Баһавиева. Форум кысаларында үзара эшчәнлеккә кагылышлы төбәкара килешүләр төзелә. Эшмәкәрләр үз бизнесларын тәкъдим итә, үзен күрсәтә. Яңа элемтәләр булдыра. Шуңа күрә дә дуслашып китеп, партнерларга әйләнүчеләр дә бар. Димәк, бизнес географиясе киңәя.

«Рухланган хатын-кызлар җыелган җирдә энергетика да зур. Ул тагын да алга барырга көч бирә. Яңа үрләр яулыйсы килә башлый, – ди оешма президенты. – Хатын-кызларыбыз бик актив булсын, яңалыктан курыкмасын иде. Пандемиядән соң бизнес белән идарә итү дә үзгәрде. Моңа кадәр эшләгән инструментлар хәзер нәтиҗә бирми. Форумда яңа шартларда бизнес төзергә һәм алып барырга өйрәтәбез, юнәлеш бирәбез, ярдәм итәбез, чөнки бөтен эшмәкәр хатын-кызларның да уңышлы булуын телибез».



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

0+



Фото: Анна Арахамия

АЭЛИТА

– Сез аны өйдә теләсә нинди исем белән йөртә аласыз, ләкин минем өчен ул Аэлита булачак, – дип кырт кисә әтисенең бертуган сеңлесе. Ничек итсә итә, Казанның ике бүлмәле фатирында тугызынчы кеше булып туган кызга Аэлита исемен кушалар. «Бала таба белдегез, исем таба белмәдегез», – дип ачуланган бабасы да әти-әнисен кире уйлата алмый. «Исем кушканчы, романны ахырына кадәр укып бетермәгән, ахрысы, апа... Аэлитаның бәхетсез мәхәббәткә дучар булганын исәпкә алмагандыр инде», – ди Аэлита ИБРАҺИМОВА. Роман героинясы белән бердәнбер охшаш яклары – әнә шул бәхетсез мәхәббәт бугай аларның...

Алсу
ШАКИРОВА

Аэлитаның тәүге хикәяте

Юк, тәвәккәллек, кыюлык, теләсә нинди авырлыкларга каршы тора алырлык холыклары да охшаш икән бит. Алексей Толстойның «Аэлита» романы аның китап киштәсендә русча һәм татарча вариантларда саклана. Үз чоры өчен чын фантастика, булмастай вакыйгалар сурәтләнгән романның төп герое исеме белән ансамбльләрне, оешмаларны, хәтта транзисторны атаганнар ул елларда. Яңгырашлы, колакка ят исем бит, башкалардан аерылып тора. Ләкин бу исемне кыз балага кушу – татар гаиләсендә гадәти булмаган хәл. Көчле исемне күтәрә белергә дә кирәк әле ул. Кыз кечкенәдән исемен акларга кирәген аңлап үсә. Укуда иң беренчесе, биюдә иң җитезе, җырда иң моңлысы, гомумән, бар җирдә дә алдынгы булырга тырыша. Тормышын күз алдыннан үткәреп, бу кадәр бөтен җиргә өлгерүенең сәбәбен Аэлита ханым хәзер яхшы аңлый:

– Без бер фатирда әби-бабай, дәү әти-дәү әни, әти-әни, әтинең ике сеңлесе һәм мин яшәдек. Бездә бөтен кеше дә нәрсәдер эшли иде. Бабай

читекләр тегә, киез итекләргә табан ябыштыра. Шуңа күрә җилем исен бик яратам, ул – минем балачак исе. Әби дә гел нәрсәдер тегеп утыра. Дәү әти белән дәү әнине күрмәдем дә кебек, алар гел эштә иде. Әни 15 яшендә үк Буадан тире эшкәртү оешмасына скорняк булып килгән. Әтием йорт җиһазы белән эшләде, соңрак Камал театры директоры урынбасары булып билгеләнде. Мин анда еш була идем, бик күп артистларны белеп үстем. Әтинең бер сеңлесе шулай ук бик әйбәт тегүче. Кечкенә генә тукыма кисәгеннән костюмнарга кадәр тегеп бирә иде. Әнигә туй күлмәген дә ул теккән, анык кебек капюшонлы туй күлмәге бер кешедә дә булмаган ул вакытта. Әтинең кече сеңлесенең чеканка, диварлар бизәү белән шөгыльләнгәнен хәтерлим. Исемне дә шул апам кушкан инде миңа.

Исемен күтәрергә ияләшә Аэлита. Ләкин йөрәккә тиюче бер сүзгә беркайчан да битараф кала алмый. Бөтен киртәләрне җимерергә, максатына ирешергә, туктамаска өйрәтә аны шул сүз: «Син моны эшли алмыйсың!» Әйтмәгез Аэлитага бу сүзне! Шуны ишетүгә, теләсә кайсы эшкә теш-тырнагы белән ябыша үзсүзле кыз. 31 ел буе һәр көнен багышлаган төп һөнәре – фитнес буенча тренер булуы да әнә шул сүздән башлана түгелме? Югыйсә мәктәпнең медицина сыйныфында укып, атнаның өч көнен хастаханәдә тәҗрибә туплап йөргән кызның юлы туп-туры медицина институтына илтергә тиеш булган бит. Тренер булырга рөхсәт бирүче таныклык алгач, дустының Аэлитага: «Синнән тренер чыкмаячак», – дип саксыз кагылуы олы юлның башы була. Икенче көнне үк Госкомспортка бара да: «Тренер буласым килә!» – дип әйтә кыз.

– Нишләргә кирәклеген аңлаттылар. Укып чыгып, 17 яшемдә тренер булып эшли башладым. Кешеләр ательеда, хастаханәдә аена мең сум эшләгәндә мин 2500 сум акча ала идем. Ательеда скорняк эше белән бергә алып бардым тренерлыкны. Туннар, башлыклар, дубленкалар тегә идем... Ике ел эчендә бөтен нәрсәне

Синнән булмый?! Бу сүзләрне аңа бөтенләй әйтергә ярамый!

тегәргә өйрәндем, – дип искә ала Аэлита ханым.

Бар җиргә дә өлгер кызның мәктәптән соң укырга керүе дә «кешечә» генә булмый. Мәскәүгә ял итәргә киткән җиреннән ике туган сеңлесенә химияне бирергә ярдәм итәр өчен имтихан тапшырырга кереп утыра ул һәм... Казанга Мәскәү югары уку йортының читтән торып уку бүлеге студенты булып кайта.

Качу

Гомер йомгагы шушы урында мәхәббәт тарихына җитте. Аны сөйләми генә үтеп китәр идек тә, Аэлитаның холкына, көчле булуына йогынты ясаган кешеләрне искә алмау дөрес булмас. Тиздән бөтен тормыш юлын тәфсилләп сөйләп, Аэлита Ибраһимова үзе дә китап язар. Һәрнәрсәне хәтерләтеп торучы көндәлекләре дә бар аның, шул хатирәләре белән китабында бүлешер, бәлки... Ә хәзергә ул 18 яшьлек гашыйк кыз бала. Кияүгә чыгып, эштән кайтып, кичләрен телевизор каршында үткәрү, ял көннәрен ике як әти-әниләрнең берсендә уздыру, кызганыч, Аэлита хыялланган тормыш түгел. Ничек тә үсәргә, мөмкинлекләрдән файдаланырга, яңа үрләр яуларга ашкына яшь әни. Кулына диплом ала, Казанның иң алдынгы фитнес үзәкләрендә эшли: дүрт клубта тренировкалар үткәрә, телевидениедә дә күренә, Шәрык биюләре федерациясен ача, бөтен Татарстаннан кызлар җыеп, биюнең яңа юнәлешенә өйрәтә башлый... Юк, хатыны белән бергә үсәргә теләмәгән ир кеше аңларлык тормыш булмый бу. Аэлита өйдә ашарга пешереп, идән юып, кичләрен телевизор каршында уздырудан бик ерак киткән була инде. Чираттагы: «Синнән барып чыкмый бу, йөрмә!» – диюенә яңа җиңү белән – спорт киемнәре кибете ачып кайткан хатынына кул күтәрә ир... Ишек артында ачыргаланып елаучы кызы

да туктата алмый аны. Икенче көнне үк эфирга чыгарга тиешле Аэлитаның исә бер генә теләге – йөзен саклап калу. Дүрт сәгать буе мендәрне тешләп ята ул. Җай чыгуга баласын җитәкләп чыгып кача.

Гаилә шулай таркала... Кире кайтырга бик үгетләсә дә, гафу үтенсә дә, «Сине беркем дә минем кебек яратмаячак», – дип сөйләнсә дә, Аэлита ире янына кире әйләнеп кайтмый.

– Фитнес клубларда эшләвем нык булышты ул вакытта. Мине күпме кеше белгәненә үзем дә аптырый идем. Барысы да ярдәм итәргә тырыша. Аерым яши башлагач, беренче ике ел бик авыр иде. Чарасызлыктан хатын-кызга хас булмаган өлкәләрне колачларга тотындым – дизайнер-проектировщик белгечлеге алып, төзелешкә кереп киттем.

«Кызым, берүзең генә башкарып чыкмастай эш, тотынма», – дип, хәтта әнисе дә әйтә. Тагын шул Аэлитага әйтергә ярамаган сүз!

...Ике атна эчендә Аэлитаның төзелеш оешмасы проект буенча район хакимияте бинасын эшләп чыга. Менә шунда барысына да өйрәнә инде эшмәкәр. Сигез бригада яллап, тәүлек буе эшлиләр, махсус заказ буенча тиз арада бөтен кирәк-яракны кайтаралар. Аэлита үзе ике атна дәвамында өенә дә кайтмыйча шул бинада иске креслода куна. Соңгы төнне радиаторларны үзе буяп, пәрдәләр элеп, иртән объектны хуҗасына тапшыралар. Нәкъ ике атна эчендә! Ышанычлы эшмәкәр булуын шундый кырыс шартларда раслый Аэлита. Алга таба исә районда бөтен объектларны аның белән эшлиләр...

Әнә шулай өр-яңадан аякка баскан Аэлита «яхшы хатын» булырга үзенә тагын бер мөмкинлек бирә – икенче тапкыр кияүгә чыга. Аэлита – үзен-үзе ясаган ханым, уңышлы эшмәкәр. Ире – дәүләт автоинспекциясе хезмәткәре. Хатыны артыннан үсә алмаган ирнең тынычлыгы беткәнен сизеп, аны күтәрер өчен үзе яңадан

Монда өйрәнгән, ишеткән, күргән әйберләрне башка беркайда да өйрәтмиләр.

«төпкә» төшәргә кирәклеген аңлый Аэлита. Ир хакын өстен куеп, табыш китерүче бизнесыннан – төзелеш компаниясеннән баш тарта. «Аңа минем янда авыр булмасын, бергә үсәрбез», – дип, хатын-кызларга туры килгән эш белән генә шөгыльләнергә карар кыла: пәрдәләр тегү салоннары ача башлый. Вакыт уза, ирнең генә үсеше озак көттерә. Дүртәр ай хезмәт хакы алып кайтмаганда да сүз әйтми Аэлита, гаилә дилбегәсен берүзе тарта. Хатынының тырышлыгы, һәрьяклап ярдәм итүе, канатландырып торуы үзенекен итә: ирне саклык хезмәте җитәкчесе итеп билгелиләр. Ләкин... Язмыш янә Аэлитаның тез астына китереп суга:

– Бер көнне кайтып, башка хатын таптым, диде. 8 Март бүләге иде бу миңа. Әйе, өч балалы гаиләне тартуга караганда, яшь хатын белән яшәү күпкә җиңелрәк... Шул көнне тагын бер тапкыр үлдем...



Онытылу

«Җилкәннәр җилдә сынала» дигәннәре Аэлита хакында сөйли кебек. Уттан да көчлерәк янучы, күбек булып өскә күтәрелүче, яңгыр тамчыларына кушылып җиргә төшүче, орлык шикелле тишелеп чыгучы... Үзе эшләп төзегән зур йорты, өч салоны, өч баласы берүзенә кала. Бу никахтан туган ике улы өчен әни дә, әти дә буласы бар. Шул вакытта яңадан аякка басар өчен, «Булмас бу юлы синнән», дип, үз-үзенә әйтте микән әллә Аэлита? Тезләнгән җиреннән елый-елый тагын торып баса ул.

Һөнәрле гаиләдә туганын куллары кабат исенә төшерә. Яшәргә акча кирәк булгач, иске диваннарны тышлап яңарту белән шөгыльләнә башлый. Җиһазларны тулысынча сүтеп, җитез генә яңадан җыюына үзе дә таң кала Аэлита. Тегүен уйламый да инде, 17 яшьтән бирле тегә ул. Ә менә җиһаз җыю...

– Аннары исемә төште. Әтинең эшендә – җиһаз җыю цехында булган вакытта бала хәтере бу эшне күңеленә салып барган... Күршеләр, шалтыратып, безнең диваннарны да цехыңа алып китеп яңарт, диләр. Эчтән генә көләм... Нинди цех? Уртакка эшләргә көчкә бер танышымны күндердем. Сүтәргә дә, җыярга да кешеләрем юк... Ирем юк, дип әйтергә дә оялам...

Тәгәрмәчтә туктаусыз әйләнүче тиен кебек яши башлый Аэлита ханым. Көне буе цехта эшли, аннары мәктәптән, бакчадан балаларын алып кайта, кич тренировкага чыгып йөгерә, төнлә ашарга пешерә. Иртәнге биштә торып, тагын яңа көнен башлый. Бизнесларын яңадан җайга сала. Хәтта үсәргә комачаулаучылар күп булса да... Еш кына алдарга, аяк чалырга тырышсалар да... Шул рәвешле Аэлитаны тагын да көчлерәк итүләрен генә аңламыйлар.

– Бу кадәр авырлыклар кичергәннән соң да энергияне каян аласың дип сораучылар күп. Балалар – минем тормыш чыганагым. Алар шулкадәр зирәк, шулкадәр дөрес сүзләр табып тынычландыралар. Каян килә аларга шулкадәр акыл дип исем китә. Олы улым минем белән йомшак итеп, Ромео кебек сөйләшә. Кечесе – чын ир-ат: беркайчан зарланмый, еламый, һәрвакыт көчле була белә, кочагына алып тынычландыра. «Мине акча эшләргә өйрәт, мин сиңа өй салып бирәм, бассейның булыр, ә ашарга безгә килерсең», – ди. Шөкер, тормышка яраклашкан балалар үсә. Танылган финансист белән сөйләшеп, олы улымны 12 яшьтән төрле программалар ярдәмендә платформалар эшләргә өйрәтүче курсларга яздырдым. Үзе акча эшләргә тели. Кызым чит телләр буенча белем алып, бер ел Америкада, ике ел ярым Вьетнамда яшәде. Хәзер үзе дә кыз үстерә. Минем фитнес-үзәктә тренер булып эшли башлады. Үз кызы да тренировка вакытында шушында – залда утыра. «Кызым, сиңа бу берәр нәрсә хәтерләтмиме?» – дип сорыйм. Көлешәбез. Үзе дә шулай үскән иде бит... Мин өчкә кадәр санаганчы, нәрсә әйтсәм шуны эшли балалар. Чөнки беләләр: начар әйберме ул, әйбәтме, мин әйткән сүземдә торам: алабыз дисәм – алам, барабыз дисәм – алып барам. Әйткәнсең икән – эшлә! Тормыш шигарем дә шундый.

Тормышында авырлыклары бихисап булса да, көлеп искә алырлык вакыйгалары да күп Аэлита ханымның. Ире белән аерылышкач, дус кызы белән төрле чараларда шәрык биюе башкарып йөри. Әлеге дә баягы акчага мохтаҗлык чыгара аны бу кәсепкә. Әле генә яшь кызларны шәрык биюләренә өйрәтеп йөргән остаз үзе дә тамашачы күңелен тиз яулый, зур җитәкчеләр катнашкан мәҗлесләрдә дә бии хәтта. Инде күптән биюләрен ташлаган булуга карамастан, кылыч белән биюче бердәнбер «шәрык кызын» танышлар аша ресторан ачылышына биергә чакыралар. Адрес буенча барып җиткәч кенә үз оешмасы ремонт ясаган ресторанны танып ала эшмә-

кәр ханым. Ләкин ышандыргач, кирегә чигенү матур түгел. Ресторанга килеп керүгә үк, директор танып ала аны: «Аэлита Равилевна, рәхим итегез түргә», – дип, олы кунаклар янына дәшә. «Бер минут, мин монда башка максаттан», – дип, киенү бүлмәсенә ашыга Аэлита ханым. Ә инде шәрык биюен искиткеч башкарган төзелеш оешмасы җитәкчесен күреп ресторан хуҗасы таң кала.

Киртләч тауларны кичкәч

Ун ел элек «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасына кергәндә зур тәҗрибәсе, тормыш багажы була инде Аэлита ханымның. Үзе кебек үк кайчандыр беренче адымнарын ясаган, хәзер уңышның югары баскычларына күтәрелгән, кулга-кул тотынышып, иңне-иңгә куеп эшләүче ханымнар белән бергә эшмәкәрлекнең яңа серләренә төшенү өчен килә ул монда. Ләкин теләгәненнән дә күбрәк ала. Лиана Бәһавиева җитәкчелегендә эшләп килүче «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» оешмасы үз бизнесы булган ханымнарны бергә җыеп, аларның үсешенә зур ярдәм күрсәтә. Тәҗрибәле эшмәкәрләр тагын да югарырак биеклеккә омтыла, яңа гына бизнес юлыннан атлап китүчеләргә киңәшче, дөрес юл күрсәтүче, яңа бәйләнешләр булдырырга ярдәм итүче вазыйфасын башкаралар. Гомумән, җәмгыятьнең төрле өлкәләрендә эшлекле хатын-кызларның әһәмиятен күтәрүче оешмаларга ярдәм күрсәтәләр, төрле дәрәҗәдәге форумнар, конгресслар уздыралар.

– Тормышта дусларым күп, ләкин аларның приоритетлары башка. Үсү теләге дә минеке кебек түгел. Мин монда яңа максатлар куям, үсәм, депутат, меценат булырга хыялланам. Тагын да күбрәк өлгерәсем, күбрәк кешеләргә ярдәм итәсем килә. Нишләп әле хезмәткәрләремә рәхмәт йөзеннән һәрберсенә машина алып бирмәскә? «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» оешмасында үзем кебек «түбәннән» – үз тырышлыклары белән үсеп чыккан эшмәкәрләр, җитәкчеләр белән таныштым. Аларны күзәтеп, эш рәвешләрен, сөйләшүләр алып баруларын өйрәнәм. Күперләр салырга, яңа танышлар булдырырга ярдәм итәләр биредә. Дусларым да күп хәзер монда. Гайбәт сату, кемнедер сөйләү гадәте юк. Бары тик нәрсәне ничек эшләргә, кайсы юнәлештә үсәргә кирәклеге турында әңгәмәләр корабыз.

Көчле идарәче булган ханымнар да тәҗрибәсе белән уртаклаша бу оешмада. «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» исемен йөртергә лаеклы эшмәкәрләрне Аэлита Равил кызы үзе дә тәкъдим итә. Оешманың һәр әгъзасы үзе дә файда китерергә, ниндидер яңалык алып килергә тырышса, тагын да нәтиҗәлерәк хезмәт булачак. Оешманың көче, куәте аның һәр кешесенә бәйле. Сентябрь аенда Казанда узган форумда да төрле дәрәҗәле спикерлар, бизнес тренерлары үз тәҗрибәсе белән бүлешеп, бизнес алып баруның яңа серләрен чишә. Кул кулны юа, ике кул битне юа дигән кебек, тәҗрибәле эшмәкәрләр өчен – тәҗрибә уртаклашу, яшьләр өчен – үсү мәйданы ул «Татарстанның эшлекле хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы.

Аэлита ханым өчен тагын яңа юллар ачыла. Семинарларның берсендә аны «Мисс Татарстан» иҗтимагый оешмасы президенты Изольда Сахарова белән таныштыралар. Кызларча җитез ханымның инде дәү әни булуы, өстәвенә, уңышлы эшмәкәр исемен йөртүен ишеткәч, Изольда Генриевна: «Син «Миссис Татарстан» конкурсында катнашырга тиеш!» – дип әйтә. Башланган эш – беткән эш: татар биюе белән финалга чыккан Аэлита «Миссис талант-2021» номинациясендә җиңү яулап, Россия конкурсына «Гранд Миссис» исемен якларга бара. Анда Аэлитаның биюен бәяләргә дә онытып, жюри әгъзалары кулларына телефон алып, чыгышның башыннан ахырына кадәр видеога яздыралар, аннары дәррәү кул чабалар. «Гранд миссис international» номинациясендә җиңеп чыккан Аэлита ханым сентябрьдә Австриягә Россия данын якларга барачак!

– Мин тормыштан бик күп әйбер алдым, шуңа күрә рәхмәтле дә була беләм. Икенче иремнең әти-әнисе белән әле дә аралашабыз. Кирәк булганда балаларны да гел алар карашты. Әле дә кайчан кайтсам да, якты йөз белән каршы алалар. Кешеләргә яхшылык кына телим, начарлык теләп үземне каралтасым, бозасым килми. Начарлыгың кешегә түгел, иң беренче үзеңә төшә. Изгелекнең үз хикмәте бар аның, ләкин бөтен кеше дә аны аңламый.

2020 елның язында халык пандемия аркасында өйләрендә утырырга мәҗбүр булганда бәрәкәтле эштә хәрәкәт таба Аэлита ханым. Хастаханәләрдә шәфкать туташы буларак туплаган тәҗрибәсе дә, машина йөртә белүе дә аны волонтерлар оешмасына алып килә. Авыру йоктырганнарны, ярдәмгә мохтаҗларны кирәк-ярак, ризык, дарулар белән тәэмин итә. Гомумән, нинди генә исеме, дәрәҗәсе булмасын, үзе тотынып эшләүдән беркайчан да тайчанмый. «Әби-бабай белән үскән кыз бит мин!» – ди ул горурланып. Яңа офиска күчкәндә ламинатны «эһ» тә итмичә үзе җәеп чыга!

Аэлита ханымның фитнес үзәгеннән тыш, тагын бер гомерлек шөгыле – тегү. Тәҗрибәсез яшь-яшь килеш эшмәкәрлек юлыннан тәүге адымнарын ясаган вакытта ук оеткысы салынган пәрдәләр ательесы аның өчен медитациягә тиң. Тегү машинасы артына үзе утырып, дөньяларын онытып җаны белән ял итә, уйларын тәртипкә китерергә ярата. Шуңа күрә клиентларының ихтыяҗын тулысынча үтәргә, өйләренә барып, пәрдәләрне кирәгенчә элеп китәргә һәрвакыт үзе йөри.

– Кемдер процесстан рәхәт ала, ә миңа нәтиҗәсе мөһим. Әйе, моны мин эшләдем диярлек булсын!

8-987-228-29-99
@aelita_rooms
AELITA ROOMS
/ авторские шторы / люстры /
/ дизайн-проект / карнизы /
/ производство мебели /
Мы переехали. Ждем вас по адресу:
г. Казань, ул. Родины, 24 Б
РЕКЛАМА

КЕМ СИН? КАЙДАН СИН?

Алтмыштан артык шәҗәрә! Кайберсендә меңнән артык исем! Кечкенә бер шәһәр бит бу! Һәрберсен ачыкларга, барларга, документ белән расларга... Балтач районының Норма авылында гомер итүче Татарстанның атказанган укытучысы Гөлсем Әдһәм кызы Миңнебаева озак еллар мәктәптә балаларга математика укыта. Ә тарих белән кызыксыну гел җанда була: мәктәп музеен оештыруда катнаша, төбәк тарихына багышланган материаллар җыя... Үз районнарында яшәүче тарихчы Бакый ага Зыятдинов шәҗәрәләр төзи башлагач, Гөлсем ханым да аңардан өч шәҗәрә ясатып ала: нәнәсе – әнисе ягыннан бабасы, әбисе һәм ире Мулланурның әтисе ягын. Ул шәҗәрәләргә җиде-сигез буын бабайларның исеме языла. Зур эш башкарылган кебек тоела... Әгәр туган авылы Кариле турында китап язуда катнашып, Бөтендөнья татар конгрессы үткәргән «Төбәк тарихын өйрәнүчеләр» җыенына эләкмәсә, шәҗәрә төзү белән чын-чынлап мавыга башлар идеме икән әле?! Бу вакытта инде мәктәптән китеп, эшмәкәрлеккә керешкән чагы була – мәшәкатьләре болай да җитәрлек. Җыенга килгән тарихчылар Мәскәү архивыннан документлар юллау серләрен ача, метрикалар белән эшләргә өйрәтә, «ревизия сказкалары» – салым салу максаты белән XVIII–XIX гасырның беренче яртысында Россия империясе халкының җанисәбен алуны чагылдырган документлар төп чыганак икәнен аңлата. Офыклар киңәя – шәҗәрәләрнең яңа буыннары ачыклана. Башта – үзенекеләр, иң якыннары әле. Аннары – авылдашларның шәҗәрәләрен төзүгә керешә.

Тарих күзгә күренеп якыная – серләр ачыла.

Кариле нибары 16 хуҗалыктан башланган икән. Алар уйлаганча, мәчет янында да, Югары очта да түгел, ә Түбән очта нигез салынган аңа. Шәҗәрәләргә аерым язмышлар урала: кем рекрутка алынган, кем бәхет эзләп читкә чыгып киткән, кем кая күченгән... Чукындырудан куркып, 1740 нчы елларда карилеләр Урыссу авылына барып нигез сала, аннан күпмедер вакыттан соң кире кайта. Казан ягыннан килгәндә, Кариле – Балтач районында үзенең мәчетен саклап калган иң беренче авыл. Аларда беркем дә чукындырылмаган. XVII гасырда Кариледә инде мәдрәсә эшләгән (башка төбәкләрдә мәдрәсәләр әле XIX гасырда гына төзелә). Кариле мәдрәсәсендә укыган шәкертләрнең исемлекләре Шиһабетдин Мәрҗани, Ризаэтдин Фәхретдиннең «Асар» китапларында сакланган: кемнәр кайдан килеп белем алган, аннан кайсы авылларга барып имам, имам-хатыйп, мөдәрис, ахун булган...

Тарих төпкеленнән бер-бер артлы күренекле авылдашлар калкып чыга. Татар тарихында тирән эз калдырган затлар! Менә Юнысовлар шәҗәрәсе. Шиһабетдин Мәрҗанине Казанга алып килгән, аңа бөтен җиһазлары белән йорт бүләк иткән аталы сәүдәгәрләр. Мәрҗани мәчетенә булышып торганнар, Нурулла мәчетен салдырганнар... Җиһанша Усманов. Солтан мәчетен ул салдырган. Холера вакытында больница төзетеп, халыкны дәвалау өчен табиблар яллаган. «Аның эшләгән игелекләрен бер Аллаһы Тәгалә генә белә», – дип яза Мәрҗани... Ишмуратов шәҗәрәсе. Юртаклар заводы тоткан. Романовларның 300 еллыгына башкалага барып, аларга үзенең иң яхшы юртакларын бүләк иткән. Ә патшага кунакка чакырылмыйча бара алмыйсың!

– Кариле авылында хәзер һәр нәселнең шәҗәрәсе бар. Шуның буенча күпләр үзләренең туганнарын таба, аралаша башлый. Мәктәпләрдә очрашу вакытында балаларга гел: «Үзегездән алдагы буыннарда яшәгән кешеләрдән үрнәк тә, гыйбрәт тә алыгыз. Шәҗәрәгезгә лаеклы өлеш кертергә тырышыгыз», – дим. Шәҗәрәне төзеп менәсең-менәсең дә, иң ахырда Николай, Иваннар барлыкка килә. Йөрәк авырта... язарга кул күтәрелми тора. Мәктәп балаларына да күрсәтәм: «10–12 буын буе татарлыкны саклап килгән әби-бабайларга хыянәт булмыймы соң бу? Бер шәҗәрәдән генә ун кешене югалтсак та, татар халкы ничә процентка кими, санагыз», – дим...

«Һәркем өчен иң мөһим, иң төп шәҗәрә – әти ягы шәҗәрәсе. Синең кем икәнеңне, кайдан чыкканыңны шул шәҗәрә сөйли», – ди Гөлсем ханым. Әтисе ягыннан бабасының шәҗәрәсен төзү өчен 20 ел (!) эзләнә ул. Бу – үзе бер тарих.

– Иң өйрәнгән шәҗәрәм – шушы. Сөйләгәндә дә күңелем тула... Бабамның бабасын гына белә идем – нибары җиде-сигез буын бу. Егерме ел буе ничек тилмереп эзләнгәнемә Мулланур гына шаһит. Җаным тыныч булмаганына да... Башкаларга шәҗәрә төзеп бирәм – унбишәр буын килеп чыга, ә үземнеке һаман шул җиде-сигез буын тирәсендә тора... 2020 елда очраклы рәвештә генә Альберт Шакировның «Юлчы» тапшыруын карадым. Мари Иле Республикасының Бәрәңге районында урнашкан Купай авылы турында күрсәтте ул. Ә безне «Купайныкылар» дип йөртәләр. Әбиләр сөйләве буенча, Рәхимҗан бабамның әтисе Шәрифҗан бабайның Карилегә Купайдан күчеп килгәнен белә идем – кулымда моны расларлык документлар гына юк. Шәрифҗан бабай Карилегә мәзин булып килгән... Купайның мәктәбенә дә бардым, өлкәннәре белән дә очраштым – җеп очы табылмады. Вакыт бик күп узган шул – Карилегә гасыр башында ук килгәннәр: 1886 елгы документларда алар әле юк, ә 1905 елгы документта, мулла итеп Габдерәүф дигән кешене куйган вакыттагы исемлектә инде телгә алыналар... «Юлчы»ның ул чыгарылышында Бәрәңге районы газетасы редакторы Фәнил Мусинны да күрсәттеләр. Ул да Купайдан, тарих белән дә кызыксына икән. Аның белән элемтәгә кердем. «Шәрифҗан бабам кайбер документларда Миршәрифҗан дип тә язылган», – дим. «Миңа бу исем таныш бит!» – диде ул... «Таптым!» – дип, Фәнил миңа хәбәр иткәндә кичке унбер иде. Төне буе йокламадым – көчкә таңны аттырдым. Бибисәйдә әбиемнең әтисе Мирхәлиулланы тапкан булып чыкты ул. Аннары – Шәрифҗан бабам белән Бибисәйдә әбиемнең никахлашу язуын. Бибисәйдә әби – Арча районы Кәче авылыннан, бабай Чистай районы Татар Талкышы авылыннан икән. Бибисәйдә әбинең әтисе Купайда мулла булып торган, шуңа күрә никах аларга биредә укылган. Мәһәр өчен – 200 сум, никах укыган өчен 8 тиен түләгәннәр, шаһитларның исемнәренә кадәр теркәлгән... Бөтен нәрсә шулай ачыкланды! Бибисәйдә ерак әбием ягыннан 22 буынымны беләм мин хәзер!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



– Шәҗәрә төзүчеләр, гадәттә, төнлә эшли. Бөтен кеше йоклаганда, тынлыкта... Борчуларың булмаганда, җаның тыныч чакта. Илһам килгәндә! Ансыз эшең алга бармый... Шәҗәрә төзү белән күбрәк минем кебек лаеклы ялдагы өлкәннәр шөгыльләнергә тиеш дип уйлыйм – безнең моңа вакыт бар... Кем заказ бирә, шәҗәрә төзүне шул кешедән башлыйсың. Әгәр ул җиде буын бабасын белә икән, ревизия документларына кереп китәсең. Бу инде авылның исемлеге дигән сүз... Буыннар чылбырын ачыклап, аска – тамырларга таба төшкәндә, үзеңә кирәк нигезне генә алып бармыйсың, уң һәм сул яктагы икешәр күршене дә өйрәнәсең. Мин күбрәк авыл кешеләренең шәҗәрәләрен ясыйм, ә авылда күршеләр бик сирәк үзгәрә. Күршеләргә дә күз салу хата китмәсен өчен кирәк. Башка нәселгә ялгыш кына кереп китсәң – кечкенә генә хата ясасаң да, ул аннары бик зурая, күбәя. Аска таба, гадәттә, бер генә буын белән төшәсең. Иң ахыргы документ бездә күбрәк 1678 елгы була. Ә менгәндә инде, җәеп-җәеп, бөтен нәселне язып барасың. Шәҗәрә агачының ябалдашлары күз алдында үсә башлый...

Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



– Улым үз дөньясына кереп китә дә, әллә нидән курыккан сыман күзләрен зур итеп ача. Моның өстенә тырнак ашау да өстәлде. Инде 11 яшен тутырса да, уйланып утырганда бармаклар гел авызда. Ярты ел тырнагын да кискән юк… Гел әйтеп торып та, тыела алмый. Күзен акайтканын читтән күзәтеп тору бигрәк тә күңелсез. Аны мин генә түгел, башкалар да күрә бит. Табибка да барып карадык, барыбер сәбәбенең очына чыга алмадык. Ничек туктатырга – һич белмим…



ҖӘЧЛӘР ЙОЛКЫР ЧАК?!.



Алсу
ШАКИРОВА

Сырхауханәдә табибка чират көтеп утырганда вакыт уздырыр өчен башка әниләр белән аралаша торган гадәтем юк. Әмма үзе сүз кушкан кешене тыңламый да мөмкин түгел... Малайны күзәтәм. Әйе, әнисе әйткәнчә, күзен әле бер якка, әле икенче якка акайтып карый. Әнисе сөйләгән белән килешми кебек: эчке каршылыгы бар – телдән әйтә алмаган сүзләрен күзләр аша «әйтә». Үзе бишле билгеләренә генә укый, ди әнисе. Невроздыр, дигән нәтиҗә чыгарам эчтән генә. Үзем дә кызымның юлында очраган аркылы сызыкларга басмыйча атлап чыгуы хакында киңәшләшергә килдем табибка. Асфальт чатнаган урынмы, плитка рәсемеме – бер сызыкка да басмый. Үзенчә киртәләрне атлап чыгарга тырышуы, дигән иде таныш психолог. Уку елы башланганын балалар гына түгел, әниләр дә борчылып көтә, ахры. Невролог ишеге төбендә чират торучыларның күбесе – мәктәп балалары.

Табиблар невроз халәтенең берничә төрен аера. Балада неврастения булса, ул еш борчыла, елый, тиз аруга зарлана, әкренрәк хәрәкәтләнә башлый, начар ашый. Неврозның бу төре психик травма биреп торучы сәбәп бар дигәнне аңлата. Әлеге сәбәпләр озак вакыт дәвамында йогынты ясап торганда бала ирексез бәйләнешле хәрәкәтләр эшли башлый – күзен акайта, еш йома, тырнак ашый, чәчен йолкый, үзенең берәр җирен тешли. Истерик невроз төре күзәтелгән балаларны балалар бакчасына йөргән яшьтә еш очратабыз: алар кычкырып елый, идәнгә ятып кычкыра, әйберләрне, уенчыкларны атып бәрә, үзен агрессив тота. Моносимптомлы неврозларга энурез, энкопрез, тотлыгу, йокы бозылу, төнлә йөрүләрне кертә табиблар.

Дус кызлар белән аралаша торган төркемебез бар. Күбебез – өч балалы әниләр. «Балаларыгызда невроз бармы?» – дигән соравыма сигез кешенең җидесе «әйе» дип җавап бирде. Чынлап та, өстә санап киткән симптомнарга күз салсак, һәр ана үз баласында аларның берсен булса да күзәткәне бардыр. Укулар башланып атна-ун көн үткәч, яңа карандаш, ручка башлары кимерелгәнен сизгәнегез бармы? Бу шулай ук баланың халәтенә игътибар сорый, дип саный белгечләр.

Республика балалар клиник хастаханәсе неврология бүлеге мөдире Винира Әюпова невроз бөтен балада да барлыкка килми, ди:

– Невроз – ул авыру түгел, организмның халәте дисәк, дөресрәк булыр. Аны барлыкка китерүче факторлар була. Мәсәлән, туганда травма алган, авырлы вакытта әнисендә анемия, вируслы йогышлы авыру күзәтелгән, кендегә чорналган балаларда ешрак күзәтелә. Баланың адаптация чоры укуның беренче ике аена туры килә. Җәйге ялдан, ирекле тормыштан соң укучыга бирелгән нагрузкалар ноябрьдә менә шул рәвешле килеп чыга. Беренче сыйныфка баручы балаларның күчеш чоры белән дә туры килә әле бу халәт.

Җәйдә туктап торган тренировкалар, түгәрәкләр дә сентябрьдә эшли башлый. Санап киткән сәбәпләргә әти-әнинең амбицияләрен дә китереп кушарга кирәктер, мөгаен. Тормышка яраклашкан, төрле яклап үсеш алган



Лилия САФИНА, «Сердәш» психологик-педагогик ярдәм бүлеге психологы

■ Йөзендә ихтыярсыз хәрәкәтләр ясаучы балага эмоция чагылдыра торган шөгыль табарга кирәк. Бию, актерлык осталыгы түгәрәкләре, мимика катнашкан башка уеннар. Кычкырып көләргә, аннары тынычланып калып уйнарга да була. Ягъни башта йөзне киеренкеләндерү, аннары җиңеләйтү.

■ Тырнак ашау, ручка башларын кимерү күзәтелгән бала белән тынычланырга өйрәнегез. Ачуланудан мәгънә юк, бала шул рәвешле киеренкелеген чыгарырга тырыша. Мәсәлән, күзләрне бәйләргә һәм тып-тын бүлмәдә нинди тавышлар барлыгын билгеләргә. Сәгать йөри, чәйнек кайный, урамда машина узып китә...

■ Мәктәптән кайткач, ниләр күргәнен, сизгәнен сораштырыгыз. Укытучының тавышы нинди: йомшакмы, катымы? Кайсы партада утырасың, күренәме сиңа? Партада утыручы күршең ничек сөйләшә? Бала бу сорауларга җавап бирсә, киеренкелекнең бер өлешеннән котыла дигән сүз.

■ Рәсем ясагыз. Дөрес рәсем түгел, үзе теләгәнчә ясасын. Сезнең фикерегезчә, бала куркыныч рәсемнәр ясаса, кара төсләр кулланса, димәк инде ниндидер вакыйга булган, ул аны бары тик кәгазьгә чыгарырга тели, бушанырга тырыша. Бу – шулай ук яхшы күренеш. Балага бу эмоцияләрдән арынырга ирек бирегез.

■ Китап уку да бик яхшы терапия. Персонажлар кичергән хисләрдә бала үзен күрә, җиңеллек кичерә. Яшүсмер бала белән сериаллар карарга да ярый. Иң мөһиме: геройлар яшьтәшләре белән аралаша торган, диалогларга бай сериал булсын. Берәр кызыклы кино табып, бергә карарга чакырыгыз. Ял итеп, әни кочагында бергә уздырган вакыт балага уңай йогынты ясый. Инде кочаклашырга теләмәгән үсмер янында йоклар алдыннан сөйләшеп утыру да файдалы. Әнинең салмак, тыныч тавышы баланы тынычландыра.

■ Баланың невроз симптомнарына артык игътибар бирмәгез. Иң беренче үзегезгә моны кабул итәргә, тынычланырга кирәк. Әйе, сезнең балагызның шундый үзенчәлекле ягы бар. Үсмер бала белән бу хакта шаярырга да була.

■ Гаилә традицияләрен булдырырга тырышыгыз. Хәзер күп кенә гаиләләрдә бергә утырып ашамыйлар да. Ял көне бергә кичке аш ашау, камыр ризыгы пешерү, йоклар алдыннан әти-әни караватында бергә ятып тору кебек кечкенә традицияләр дә балага тынычлык бирә.

■ Йокы, ашау режимы гына түгел, гомумән, психогигиена төшенчәсен истә тотарга кирәк. Ягъни режим бозылачагын алдан белеп торсагыз (мәсәлән, кунакка барасыз), ул көн алдыннан аны аеруча катгый сакларга тырышыгыз. Төшке йокыдан баш тартырга туры килсә, баланы соңрак уятыгыз. Командировкага китәсе булган очракта да баланы моңа әзерләргә кирәк.

Фото: www.pixabay.com

Бу гадәтеннән ул үзе дә туйгандыр инде, ләкин арына алмый.

талантлы бала үстерү теләгеннән бер генә түгәрәкне, бер генә спорт төрен түгел, берничәне колачларга тырыша әти-әниләр. Әйе, спортчы да булсын, баянда да уйнасын, рәсем мәктәбендә дә укысын – барысын да уздырсын... Уңышка ирешкән, муеннарына медаль аскан, сәхнәдә балкыган, төрле проектларда җиңү яулаган кеше балаларын социаль челтәрләрдә күреп: «Башкалардан ким булмасын, без дә булдырабыз, өлгерәбез!» – дигән теләк бала мәнфәгатен икенче планга күчерә.

«Мондый очракта үзеңне дә, балаңны да башкалар белән чагыштырмаска кирәк», – ди невролог. Сезнең бала мондый авырлыкларны күтәрергә әзерме? Алар балада киеренкелек тудырмыймы? Бу сорауга дөрес җавапны бары тик баланың көчле һәм көчсез якларын билгели алган, сәламәтлеген, кабатланмас холкын, үзенчәлеген белгән әни кеше генә җавап бирә аладыр. Ләкин күзләрен «уңыш» томалаган әниләрнең үз туксаны – туксан...

Чиратта утыручы икенче як күршемә – 4 яшьтән нәфис гимнастика һәм фигуралы шуу белән шөгыльләнә башлаган Лианага ике спортны берьюлы алып бару җиңелдән бирелә. Әнисе Гөлфия дә эшкә чыкмыйча, кызын үстерү белән генә мавыга. Беренче сыйныфка укырга кергәч тә шулай дәвам итәләр. Спортның бер юнәлешен генә сайлар иде, икесендә дә уңышлы шөгыльләнә кыз. Ләкин өлгереп булмый. Нәтиҗәдә, беренче чирекне тәмамлаганда ук кызда невроз башлана. Бертуктаусыз күзен йома башлаган баласын ачуланып та, тыеп та карый Гөлфия. «Начар гадәтеңне ташла, җитәр, дим!» – дип, кызын кеше янында шелтәләүдән дә тартынмый. Уку елы ахырына Лиана еш авырый башлый: тренировкаларына да зыян килә, укуы да кала. Күз йомуга тагын бер ирексез хәрәкәт өстәлә – Лиана башындагы чәчләрен йолкыштыра башлый. Бу инде әни кеше өчен чаң сугарлык вакыйгага була. Кичекмәстән психолог, невролог белән киңәшләшкәннән соң гына Лианага ярдәм итә ала әнисе. Нәтиҗәдә, спортның бер төрендә – фигуралы шууда гына калырга булалар. Игътибарын берьюлы өч шөгыльгә юнәлтергә мәҗбүр булган баланың ныгып җитмәгән организмы шул рәвешле стресс кичерә. Уку елы башлануын Гөлфия борчылып көтә. Кызының бу халәте кабатланмасмы?

– Балада теге яки бу симптом барлыкка килгән икән, әти-әниләр өчен сигнал бирүче кызыл лампочка дигән сүз бу. Димәк, проблема сезнең игътибарны таләп итә. Күз йому, акайту, җилкә сикертү кебек симптомнар – организмның авырлыкларга карата реакциясе ул. Каршылыклар туганда, ирешә алмаслык максатлар куелганда бала үз теләгенә каршы чыгарга, вазгыятькә яраклашырга мәҗбүр була. Кемдер моны уңышлы башкарып чыга, кайбер балаларның нерв системасы какшый. Балага бу турыда гел әйтеп торсаң, тыярга тырышсаң, ул моңа тагын да күбрәк игътибар бирә башлый – зур проблемага әйләндерә, – ди «Сердәш» психологик хезмәт күрсәтү үзәге психологы Лилия Сафина. – Балага сезнең тәнкыйтегез түгел, киресенчә, игътибарыгыз, ярдәмегез кирәк.

Уку елы башлану – бала өчен генә түгел, әти-әни өчен дә зур сынау. Шуңа күрә укытучылар да сентябрь аенда балаларга аеруча игътибарлы булырга куша. Баланың ел дәвамында уңышлы укуы, неврозларга бирешмәве өчен адаптация чорын бергә үтәргә киңәш итәләр.

– Балага уку шатлык китерми икән, адаптация дигән әйбер кирегә эшли башларга мөмкин. Монда, әлбәттә, укытучының да роле зур. Ул беренче көннән үк уңай психологик халәт тудыру өстендә эшли башларга тиеш. Шулай булмаганда бала кәефсезләнә, еш елый, еш авырый, мәктәпкә бармас өчен сәбәпләр эзли. Моннан тыш, дәрестә кычкырып утырырга, әйберләрен тотып атарга мөмкин, балалар белән дуслаша алмау, укытучының сүзен тыңламау очраклары да күзәтелә. Ә кайбер балалар, киресенчә, үз эченә бикләнә: сөйләшми, эндәшми, иптәшләре белән уйнамый башлый. Мондый вакытларда психолог, табиблар белән дә эшләргә, аларга мөрәҗәгать итәргә туры килә. Бу проблемалар мәктәп белән генә бәйле дип әйтеп булмый. Әти-әниләр белән сөйләшкәндә, бакчага йөргәндә дә, өйдә булганда да балада әлеге күренешләр күзәтелгәнлеге ачыклана. Бу да инде баланың негатив эмоцияләре артуын күрсәтүче фактор булып тора, – ди башлангыч сыйныф укытучысы Кадрия Гарәпшина.

Ирексездән еш кабатланучы хәрәкәтләр белән чагыштырганда, неврозның катлаулырак формалары да була. Тотлыга башлаган, төнлә астын юешләгән, зур йомышын үтәүче балалар әти-әниләрен борчуга сала. Бала бу халәтеннән үзе дә ояла, яшүсмер чорга җитеп килгәндә дә дәваланмаган неврозның бу төре аеруча уңайсызлык китерә.

– 9 яшьлек улыбыз төнлә астын юешли, – дип борчыла бер танышым. – Әйе, иремдә дә булган андый гадәт. Ләкин 6 яшендә туктаган. Улым да узган җәй көне туктаган иде, уку елы башлангач, бу гадәтенә яңадан кайтты. Төнлә уяту да, йоклар алдыннан су күп эчмәү дә ярдәм итми. Һәр төн саен диярлек кабатлана бу әйбер. Лагерьга ял итәргә дә бара алмый, хурлыкка калудан курка.

Мондый очракларны үтәр әле, дип, игътибарсыз калдырырга ярамый, дип саный белгечләр.

– Энурез балага нәселдән күчкән булуы да мөмкин. Әлеге диагноз дәвалауга бирешә. Бала әтисендә йә әнисендә күзәтелгән яшьне үтеп киткән вакытта бу инде неврологик проблема дигән сүз. Дәвалауга никадәр иртәрәк тотынсагыз, шулкадәр яхшырак. Иң беренче чиратта неврологка мөрәҗәгать итәргә кирәк, сәбәбен ачыклаганнан соң табиб башка белгечләргә дә юллар. Неврозның сәбәпләре тирәнрәк булган саен, аны дәвалау катлаулырак булачак. Башлангыч билгеләренә үк игътибар итәргә кирәк. Кызларга караганда, малайлар неврозга ешрак бирелүчән. Иң гади нәрсәдән – режим көйләүдән башларга киңәш итәм. Кайвакыт йокы туюю да симп-

томнарны бетерә. Төне буе телефонда, интернетта утырган балага невроз гына түгел, башка авырулар да тиз йогучан була. Ләкин невроз тышкы факторларга да бәйле. Дәвалау уңышлы булса да, бала берәр стресс кичерсә, бөтен симптомнар яңадан әйләнеп кайтырга мөмкин. Ничек кенә гади яңгыраса да, кояш, саф һава һәм су процедуралары – неврозданиң үтемле чара. Әлеге режимны кечкенәдән көйләсәгез, даруларсыз да неврозны җиңеп чыгарга була, – ди невролог Винира Әюпова.

Әйе, 9 яшьлек улында энурез булган танышым кечкенәдән режим сакламаганлыгын искә ала. Җәй көне төнге икеләргә кадәр паркларда, кафеларда йөрүләре, кунакка барып, еш тоткарланулары турында сөйләде. Үзе эшләмәгәч, улы бакчага йөрми: иртән торуга ихтыяҗ юк. Вакытында йокламаган, уянмаган баланың организмы да үзен ничек тотарга белми, күрәсең. Табиблар, психологлар, укытучылар бертавыштан баланың психологик тотрыклыгы нигезендә, укуда өлгерүендә режимның йогынтысы зур, диләр. Ләкин, ни хикмәт, совет чорында төгәл режим саклап үскән буын булгангамы, ул тәртипләрдән туйгангамы, үзебез үк режимнан качарга омтылабыз. Бала иреген, аның ихтыяҗын сакларга тырышабыз, имеш... Тормыш куып, биреп бетерә алмаган игътибарыбызны баланың һәр теләген тормышка ашырып акланырга тырышабыз түгелме? Соң гына булса да паркка барып кайту, ярамаса да, туңдырма алу... Барысын да баланы яратудан эшләгән кебек булса да, үзебезгә ошамаган рольне башкарырга – «режим сакчысы» булырга теләмибез. Алай гына да түгел: «Ярар, тәмам туйдырдың, барсак барыйк, иртәгә мәктәптә йоклап утырсаң, үзең гаепле буласың», – дип, җаваплылыкны бала өстенә аударабыз кайвакыт. Җаваплылык алырга теләмәвебез баланың режимын бозуга китерә. Әни беренче чиратта дус түгел, нәкъ менә әни булырга тиеш. Баланың теләгенә каршы торырга да, аңлата белергә дә кирәк.

Ничә яшьтә булуына карамастан, баланы невроз халәтенә җиткермәү өчен профилактик чаралар да җитә. Вакытында йокларга ятарга, бер үк вакытта уянырга кирәк. Саф һавада йөрү, йөзү белән шөгыльләнү, су процедураларын тулысынча файдаланудан башларга кирәк терапияне. Гаджетлар замана чире булса да, аларны тулысынча тыю мөмкин түгел. Ләкин вакытын чикләү шулай ук әти-әниләр җаваплылыгында. Бу киңәшләрне кулланалармы яисә дару ярдәмендә дәваланалармы – анысын һәр кеше үзе хәл итә, ди белгечләр. Еллар, буыннар белән сыналган сәламәтлек кагыйдәләре бүген дә баланың психологик халәтенең нигезен тәшкил итә. Вакытында чарасын күрмәгән очракта бу гадәтләр олы тормышка да ияреп керергә мөмкин, моны да онытырга ярамый.

...Безнең чират җитеп килгәндә табибның кирәге калмаган кебек булса да, үз фикерләремә инанып өчен барыбер кереп чыктым. Башкаларга карыйсың да, безнеке Аллага шөкер икән әле, дисең. Чиратымны бушка уздырмадым, тормыш сабагы алдым монда. Бу юлы дару түгел, профилактик чаралар сайларга булдык. Чәчләрен йолкырлык хәлгә калдырасы килми баланы...



Кадрия ГАРӘПШИНА, укытучы, Россия Федерациясе Тәрбия һәм белем бирүнең мактаулы хезмәткәре

Укырга керү белән баланың тормышы нык үзгәрә. Моңа кадәр күп вакытын уен белән уздырган булса, хәзер парта артында дәресләр күп көч, дисциплина, тырышлык таләп итә. Баланың мәктәпкә әзерлегенә карап, адаптация чоры бер айдан ярты елга кадәр дә сузылырга мөмкин. Баланың уку процессына тиз кереп китүендә әти-әнинең дә роле зур.

- Балаларны мәктәпкә килгәнче мөстәкыйльлеккә өйрәтә башларга кирәк. Киенергә, чишенергә, үз әйберләрен җыярга, уку әсбапларын бергәләп сатып алырга, үз әйберләрен танырга өйрәтергә кирәк.
- Бала белән сөйләшкәндә мәктәп белән куркытырга ярамый. Кайбер әти-әни: «Укый белмәсәң, «икеле» куялар, синнән көләләр», – дип куркыта. Ә кайберләре, киресенчә, мәктәп тормышын артык бизәп күрсәтә. Чынбарлык баланың көткән күзаллавына туры килми. Баланың күңеле кайтуга бу сәбәп булып тора. Артык басым ясамыйча, реаль тормышка туры килерлек итеп аңлатырга, сөйләшергә тырышырга кирәк.
- Августтан ук баланы режимга кертә башларга кирәк. Тугыздан да калмыйча йокларга ятарга, вакытында торгызырга, телевизорны сүндереп, телефоннарны ераграк куеп, китаплар белән кызыксындырырга тырышырга.
- Укый башлагач, тагын да күбрәк игътибар кирәк. Уку башлану белән баланың йокысы туймый, арый. Шуңа күрә авыр эшләрне кичкә калдырмаска тырышырга, төнгә кадәр дәресләр эшләтеп утыртырга ярамый. Әти-әниләргә бала белән тыныч булырга, сабыр итәргә киңәш итәр идем. Дөрес туклану һәм саф һавада булу да мөһим.
- Бер сыйныфтан икенче сыйныфка күчкәндә (коллектив алыштыру күздә тотыла), яшүсмер чорда невроз аеруча ачык күзәтелә. Шуңа күрә баланы мәктәптән тыш лагерьларга, башка коллективларга кертүдән курыкмаска кирәк. Никадәр күбрәк коллектив белән аралашса, балага тормышта шулкадәр яхшырак, җиңелрәк була.
- Хәзерге заманда тормышның нинди булуына карамастан, килгән авырлыкларны җиңеп, гаиләдә тынычлыкны саклап, бала белән бергә булырга, гаилә традицияләрен булдырырга, ярату һәм мактау сүзләрен күбрәк әйтергә тырышырга кирәк.

«ШИГЫРЬЛӘРЕМДӘ ЧЫН МИН»



Күпләр аны юморист, кеше көлдерүче итеп кенә белә. Әмма ул бөтенләй башка кеше. Төпле, хисле, фәлсәфә иясе, үтә җитди... Соңгы вакытта социаль челтәрләрдә чыккан шигырьләре дә аны башка яктан ача. Бүгенге көндә күпләргә хас булмаган ихласлыкны аңарда күреп сокланасың. Беркатлы булуы яшәргә комачау итми микән дип уйланасың. Көтмәгәндә шаяртып куюыннан дөньяны онытып көләсең. Аның кебек чип-чиста татарча сөйләшә белгән иҗат кешеләре, кызганыч, сирәгәя бара. Юморист, күпкырлы талант иясе Әбри ХӘБРИЕВ белән сөйләшәбез.

Сиңа күбрәк кем дип эндәшәләр? Әбриме, әллә Даниярмы?

– Авылга кайтсам, өйдәгеләр, дуслар үз исемем белән эндәшә, сәхнә тирәсендә Әбригә әйләнәм. Икесе дә бертигез яңгырый, әмма күбрәк Әбридер. Хәтта күп кеше чын исememне белми дә. Үземә икесе дә бик якын.

Әмма алар икесе ике мәгънәдә яңгырый кебек. Әбри юморга якын, Данияр – җитди...

– Әйе, яңгырашы буенча шулайдыр. Әмма асыллары бер. Әбриендә дә җитдилек тә, фәлсәфә дә бар...

«Рәвешләр» юмор төркеме таралды? Кызыгы беттеме, үзең ул юмордан үстеңме?

– Яшьләр эстрада театры булсын дигән теләк белән оештырган идек без аны. Нәрсәгә таркалдымы?.. (*Уйланып алганнан соң.*) Примитив мәзәкләр арасына интеллектуаль юмор кертергә тырыша башладык. Әмма барып чыкмады. Шуңа туктаттык. Илдәге икътисадый-сәяси хәлдән алҗыган халыкның залга килеп тә уйланып утырасы килмәдеме, зәвыгы җитмәдеме – кабул итмәделәр. Безнең халык гадилек ярата бит ул.

Данияр, мин шәхсән сине билдән түбән юморлар сөйләп йөргән юморист дип кабул итә идем, соңгы елларда үзгәрдең...

– Чынлап та, күп кенә тамашачылар минем хакта җилбәзәгрәк, тормышта да шундый ахмактыр бу дип уйлыйдыр. Бу – элекке сәхнә образларыннан туган тәэсир. Әйе, без яшь идек. Җитмәсә, ул чорда тамашачы билдән түбән юморны таләп итте. Шуннан кул чабып көлде, караганнан соң эт итеп сүкте. Примитив юмор заманы иде. Эстрадага халык зәвык эзләп бармады. Һәр номер – ул тәҗрибә. Элек примитив юморга басым ясаган булсак, хәзер, яшь барган саен, аның кирәк түгеллеген, ул юморны сөйләп йөреп рухи яктан үсә алмаганны аңладык. Яңа буын тамашачы үсеп килә, аның таләпләре дә башкачарак. Үзебезгә дә кызык түгел. Без хәзер икенчерәк юнәлештә эшли-

без. Акыл да үсә, тормышка караш та башкача... Без инде – бала аталары. Үзебез үрнәк булырга тиеш. Мин, гомумән, рус эстрадасындагы Евгений Гришковец кебек камералы концертлар ясар идем.

Син юморист кына түгел, күңелләргә үтеп керерлек шигырьләр авторы да...

– Бер-берсен тулыландырып тора инде алар. Миндә бит әллә ничә холык яши. Тирән мәгънәле шигырьләр дә язасың икән дип шаккатучылар да, үзе язмагандыр әле, диючеләр дә бар. Әмма беренчеләр армиясе күбрәк. Халык ихласлыкны тоя ул. Шигырьләрем барысы да ихлас. Аларда – мин үзем. Әле күләмле әсәр язу теләге дә бар. Аның өстендә эшлим.

Сине романтик җырчы дип әйтеп буламы?

– Миндә Филүс, Ришатныкы кебек көчле моңлы тавыш юк. Әмма җырлый алганча җырларга тырышам. Нота аера белмәгән, әмма акчалы кешеләр җырлап йөргәндә, музыкаль белемем була торып, нота грамотасын, гармонияне энәсеннән җебенә кадәр белә торып, нигә әле миңа җырламаска?! Тугыз ел тиккә укымаганмындыр бит. Кызганыч, шәп тавышлы җырлый белүчеләр бар, әмма алар сәхнәдә түгел, чөнки мөмкинлеге юк. Хәзер сәхнә тулысынча акчага корылган. Бер җырны чыгарыр өчен генә дә 50–60 мең сум чамасы акча кирәк. Шуның аркасында халыкка таныла алмаганнар бик кызганыч.

Портретлар остасы икәнеңне дә беләм. Бигрәк киңкырлы талант иясе булып чыгасың түгелме?..

– Әйе, бераз бар ул сәләт. Мәктәпкә укыганда архитектор булам дип хыяллана идем. Әмма укытучы әтием белән әниемнең пропагандасы аркасында укытучы булу теләге уянды. Арча педагогика көллиятенә киттем. Тик укытучы була алмаячагымны аңладым. *(Көлә.)* Сәхнә телен, музыка нигезләрен ныклап өйрәнүне максат итеп куйдым. Барыбер архитектор була алмас идем. Озаклап утырып эшли торган эшләрне яратмыйм. Тиз арыйм.

Инстаграмда популяр артистлар арасыннан синең исемең генә татарча итеп язылган, һәм син генә аккаунтыңны бары тик татарча алып барасың. Чип-чиста итеп татарча сөйләшүеңә дә игътибар иттем...

– Бу – минем принципиальлегем. Өйдә дә балаларга «татарча» дип кенә әйтеп торам. Бер кул селтисең икән, бик тиз ана телен онытачаклар. Институтта укыганда сөйләм телен бик нык өйрәндем. Урысча сүзләр кыстырып, калька белән сөйләшкәннәрне җенем сөйми. Туган тел сөйләме камил булырга тиеш ул. (Бу урында Данияр миңа татар телендә сүзләргә дөрес итеп басым ясау буенча тулы бер лекция укый! – *Ч. Г.*) Туган телдә ясалмалылык тудыру телне хөрмәт итмәү ул. Үземнең телемне яратканга күрә, соңгы вакытта телгә карата вазгыять куерганын, игътибар кимегәнен, ясалмалык артканын, тел тирәсендә бары тик хайп кына ясарга тырышуларын күреп-белеп торам, шуңа битараф кала алмыйм. Татар тамашачысына эшлим, татар баласымын, телемә хөрмәтне менә шушылай кечкенә кыйпылчыклар аша булса да күрсәтергә тырышам.

Сәхнәдә кеше көлдереп йөргән Әбри пәрдә төшүгә ниндигә әйләнә?

– Әллә нәрсә аерылмыйдыр. Әмма тормышта җитдирәкмен. Дөрес, мохиткә, ситуациягә карап юмор элементлары да керә. Ә сәхнәдә – башка. Син анда бөтен проблемаларыңны онытырга тиешсең. Ул – синең эш урының. Әмма хәзер сәхнә эш кенә түгел, тормышның бер өлеше инде. Мин иҗатны яратам. Акча эшләү өчен генә сәхнәгә чыгып кеше көлдерәм дигән максатым юк. Акчаны аны банкетларда эшләргә була, ә сәхнә ул – иҗат мәйданы... Син тудырган образлардан тамашачы рәхәтләнеп көлә икән, җанга шундый рәхәт булып китә. Эх, аңламыйсыз аның ләззәтен...

Текст: Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА.
Фото: Анна АРАХАМИЯ. Видео: Булат ГАЗИЗУЛЛИН.
Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.



РАФИС КИЛЕННӘРЕ



Лилия ГӘРӘЕВА

Язманың исемен башта «Хөрмәтле кешеләр» дип куярга уйлаган идем. Болай атау дөрес тә булыр иде, чөнки Мөслимдә кемнән сорасаң да, аларны бары матур итеп кенә телгә алачаклар. Районыбызның иң хөрмәтле гаиләсе диячәкләр. «Бәхетлеләр» дип тә атарга теләдем. Гомер буе туган якларында, үз халкы арасында яшәп, шушы җиргә игелек китергәннәрне ничек бәхетле димисең?! «Хәбибуллиннар» дисәң, язмамның төп герое Фәнисә апа үз нәселе фамилиясендә – Гыйльметдинова булып йөри икән…







// **Фәнисә Гыйльметдинова-Хәбибуллина: «Мин, татар теле укытучысы буларак, оныкларыбыз чын татарча итеп сөйләшә белсәләр, халкыбызның, милләтебезнең гореф-гадәтләрен, йолаларын үти алсалар, киләчәктә дә туган телебезне саклап кала алырбыз дип ышанам».**

– Өч улыбыз, өч кызыбыз бар. Оныкларны кушсаң, тагын да күбрәк, – дип каршы алды безне Фәнисә апа белән Рафис абый. Тукта, тукта, алар белән таныштырганда, өч уллары бар дигәннәр иде, кызлары турында да ник әйтмәделәр икән соң?

Капка төбенә безне каршыларга Сабантуй мәйданы кадәр халык җыелган. Барысы да Хәбибуллиннныкылар! Бай гына офисның парковкасын хәтерләткән машиналар арасыннан узып, ишегалдына кергәндә һәрберсенең бер үк төсле булган номерларына игътибар итәм.

– Хәбибуллиннрның гаилә номеры бу, барыбызныкы да бер – 555, – ди олы малай Илдар, гаҗәпләнүемне күреп. Никадәр бердәм, тату гаиләгә килүебезне раслар өчен шушы бер генә деталь дә җитәр иде.

...2018 елның салкын бер кышкы көнендә Мөслим урамнарына көмеш кыңгыраулар тавышы сибелә. Шарлар белән бизәлгән җигүле туй аты Рафис абый белән Фәнисә апалар капка төбенә туктый. Алтын туйларын билгеләп үтүче әти-әниләренә балалары сюрприз ясый шулай – әниләрен килен булып төшкән яшь чакларыннан тагын бер уратталар.

Сүземне Фәнисә апаның үзеннән башлыйм әле. Булса да булыр икән кешедә бу кадәр җылылык, ягымлылык. «Балакаем, бәбкәм, кызларым, улларым...» – аның телендә иң еш кабатланган сүзләр бу. Татарстанның атказанган укытучысы, өченче дәрәҗә Хезмәт даны ордены иясе Фәнисә ханым Сөләймановна. 1966 елны Минзәлә педагогика училищесын тәмамлагач, Актаныш районы (ул чакта әле Калинин) Күҗәкә авылы кызын Мөслим районының Түбән Табын авылы мәктәбенә билгелиләр.

– Ике елымны гына укытам да, аннары китәм, дип килгән идем, гомерлеккә Мөслимнеке булдым да калдым, – дип искә ала ул елларны Фәнисә апа. – Мәктәптә яшь укытучы кызлар байтак идек. Кышкы каникуллар якынлашкан чак. «Хәлиулла абыйның бик чибәр улы кайтасы бар. Кайсыгызны сайлар икән», – диләр. Аларның төпчек кызлары Зөлфия минем классымда иде. Абыйсы Рафис каникулга кайткач, безгә яңа апа килде, дип, фотомны күрсәткән. Әнә шул елны таныштык Рафис абыең белән. Мәхәббәтебез кыш көне чәчәк атты... Рафис ул вакытта Казанда медицина институтында укый иде. Кабат Казанга киткәч тә, бик матур хатлар язды ул. Шигырь белән яза иде. Хатларына: «Фәнисә, кадерлем», – дип куя. «Кадерлесе түгел бит әле, ник болай яза икән?» – дип бик аптырый идем. Икенче елны кышкы каникулга кайткач: «Әйдә өйләнешик», – дип кыстый башлады. Ә минем хыялым – югары белем алу. (Бу хыялына ирешә ул. Рафисе дәүләт имтиханнары тапшырганда, Фәнисә апа Казан педагогика институтына керү имтиханнары бирә.)

Рафис алты балалы бик үрнәк гаиләдә үскән. Хәлиулла әткәй белән Нурлыбәнат әнкәй, әрләшү түгел, балалар алдында үзара усал караш та ташлашмыйлар, шулкадәр сабыр кешеләр иде. Аларның алты балалары янына җиденчесе булып килдем. Рафис китте, мин аларда яшәп калдым. Үзен чит итеп сизмәсен дип, әнкәй бәгырем кайтышыма мичкә ягып коймаклар пешереп торыр иде. Килен димәделәр миңа, кызым, диделәр. Мин дә киленнәремә кызым, дим. Килен дип әйтү – чит иткән кебегрәк тоела үземә.

Өч кызларын нигә әйтмәделәр дигән соравымның җавабы да чишелде... Өч кызлары – өч киленнәре аларның. Гөлшат, Лилия, Гөлназ Хәбибуллиналарны Мөслимдә «Рафис киленнәре» дип йөртәләр.

Фәнисә апа гомере буена укытучы булып эшләгән, башта башлангыч класслар, аннары югары классларда татар теле һәм әдәбияты укыткан. Үзе әйтмешли, ул да, Рафис абый да дәүләт кешеләре булганнар.

– Бу орден икебезнеке дә, дим. Рафис булышмаса, балаларны карашмаса, мин мәртәбәле исемнәр алырлык итеп эшли алмас идем, – ди Фәнисә апа. – Сабырлыгы әткәй белән әнкәйдән.

– Күбрәк әбекәйдәндер ул, Фәнисә, – дип сүзгә кушыла сөйләшкәнебезне ни гомер түзем генә тыңлап утырган Рафис абый. – Әбекәй гомере буе кияве – безнең әткәй белән яшәде. Ул эштән кайтмыйча торып, беребезне дә табын янына китертмәс: «Балалар, әтиегез кайтсын», – дияр иде.

Рафис абый Хәбибуллин да, Фәнисә апаныкы шикелле, дөньядагы иң игелекле һөнәр ияләренең берсе, ул – табиб, СССРның сәламәтлек саклау отличнигы. 1968 елны Казан дәүләт медицина институтын тәмамлап, Мөслимгә стоматолог булып кайтса да, үз белгечлегенә керешкәнче, башта бер ел терапевт, аннары ике ел хирург булып эшләп торырга туры килә әле аңа.

– Остазларым бик әйбәт кешеләр иде. Баш табиб Хәбибуллин Ильяс Абдулловичтан, терапия буенча Лотфирахман Фәйзерахманович Фәйзерахмановтан күпкә өйрәндем, – ди Рафис абый.

Ул елларда Мөслимдә теш дәвалый торган стоматология кабинеты була булуын, ләкин тешләр куйдыру өчен район халкы читкә йөрергә мәҗбүр. Казанга белемен күтәрергә киткән бер ай эчендә җиде тапкыр министрның үзендә, унбер тапкыр медицина техникасы кибетендә булса була – теш куйдыру кабинеты өчен кирәкле барлык җиһазларны юнәтә Рафис Хәлиуллович. 1971 елның 25 октябрендә Мөслимдә беренче теш куйдыру кабинеты ачыла.

Рафис абый табиб кына түгел, спортчы да, шагыйрь дә. Чаңгы һәм велосипед спорты буенча спорт мастеры кандидаты. Шигырьләре республика матбугатында

Фото: Анна Арахамия



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Видео: Анна Арахамия.

басылып тора, берничә шигъри җыентыгын, автограф куеп, безгә дә бүләк итте.

Өйләренең уртасында түм-түгәрәк өстәлләре бар аларның. Дуслык өстәле ул. Түгәрәк өстәлнең түре дә, почмагы да юк. Һәр елны укытучылар бәйрәме көнендә зур бәлеш пешереп, Фәнисә апа балаларын түгәрәк табынга җыя. Без килгәндә дә бар туганнарны сыйдырган иде ул. Өстәл тирәли тезелешеп утырган олы малай Илдар белән Гөлшат, аларның кызлары Алия һәм Эльвира, уртанчы малай Илшат белән Лилия, тиктормас Ислам (олы уллары Рамис Чаллыда булып калды), төпчекләре Илгиз белән Гөлназ, кызлары Лиана (быел унберенче сыйныфка бара, җырчы), Регина, Шамил – бар да бәлешнең капкачы ачылганны көтә. «Әби, миңа төбен салырсың әле», – дип, бәлешнең иң тәмле төшен оныклар үзара бүлешеп тә куйды инде. Үз җирләрендә рәхәтләнеп татарча сөйләшеп, назга, яратуга коенып үсүче иң бәхетле балалар болар.

– Җимешләрем бит алар, – дип сөя әбекәйләре үзләрен. – Лиана беренче куанычыбыз. Әле юньләп теле дә ачылмаган иде үзенең, зәңгәр тышлы Әлифбаны тотып килер иде дә: «Әби, «тита» (китап дию) укы!» – дип, алдыма килеп утырыр иде. Теле ачылганчы ук шул Әлифбаны яттан өйрәнде бит. Иллә дә яхшы иде ул Әлифба. Балалар иҗек һәм хәрефләрне тиз өйрәнә иде аннан. Безнең балалар уенчык белән уйнарга яратмады, «диктант язабыз», диләр иде. Шулай уйный-уйный татарчаны менә дигән итеп өйрәнделәр. Хәер, Мөслим татар районы булгач, монда болай да гел татарча инде безнең. Алиябез 4 яшеннән чатнатып татарча шигырьләр сөйли. Чаллы, Түбән Кама, Мөслим, Минзәләдә узган конкурсларда катнашып, җиңеп кайта.

– Балаларыбыз шушы йортта, әбекәй-бабакайлары белән үсте, – ди килендәшләр. – Авырып, бакчага бармый калсалар, дарулары белән бергә иртән китереп куяр идек тә, кич эштән кайтышлый алып китәр идек. Алмадык «больничный»лар. Әле дә шулай: баланы берәр җиргә илтәсе, алып кайтасы булса, әти бер дә иренми, машинасын кабыза да чыга да китә. «Әти, гел җайларына гына торма», – дисәк, «Ярату артык булмый ул», – ди.

– Лианабыз кечкенәдән җырларга ярата иде, – дип искә ала әнисе Гөлназ. – Бөтен бала-чаганы җыеп, концерт әзерлиләр. Кич түр як ишегенә белдерү эленә: «Кичке җидедә барыгызны да концертка чакырабыз». Әбиләре белән бабайлары, җитәкләшеп, «концерт залына» иң беренчеләрдән булып кереп утыра. Балаларны ачулану юк аларда. Уеннарын да җитдигә алып, алар белән мәш киләләр.

Гөлназ – Хәбибуллиннар йортына беренче булып төшкән килен. Үзе дә Мөслим кызы. Хатын-кызлар консультациясендә акушерка булып эшли.

– Без гел бергә, – ди Рафис абыйның киленнәре. – «Өч килендәш» дип аталган төркемебез бар. «Хәерле иртә» белән уянабыз, «тыныч йокы» теләп көнне тәмамлыйбыз. Бәйрәмме, эшме, берәребездә тәмлерәк ризык пештеме – уртак. Ватсаптагы төркемебезгә бер фото кую җитә – йөгерешеп киләбез.

Традиция буенча, 9 Май – Хәбибуллиннарның бәрәңге утыртa торган көне. – «Эш ул – бәйрәм!» – ди безнең әти, – дип көлешә килендәшләр. – Кемнең бакчасы әзер, көтүебез белән киләбез дә, утыртып та китәбез. Кайчагында хуҗалар үзләре эштә дә булып калырга мөмкиннәр. Көзен бергәләп алабыз аннары».

– Гөлшатыбыз бәлешләр, тортлар пешерергә ярата. Берьюлы дүртәр бәлеш пешерә. Ник бу кадәр күп дисәң, берсе – әниләргә, берсе Илшат абыйларга, берсе сезгә, – ди. Барыбызның да туган көннәренә зу-ур торт әзерли, – дип, килендәшенең күркәм сыйфатларын барлый Гөлназ. Гөлшат та Мөслимнеке, ул – бухгалтер.

– Өчесе дә уңган аларның. Мичкә берәр ризык тыксалар, кайнар килеш әниләр авыз итсен, дип, беренчесен безгә җибәрәләр. Шундый киленнәрне ничек яратмыйсың, – дип, тагын киленкәйләрен мактап ала Фәнисә апа.

– Безнең әни шикелле кеше юктыр ул! – Уртанчы уллары Илшатның хатыны Лилия шулай ди. – Нәрсә кисәк тә, и-и, бигрәк матур булган, ди. Ни эшләсәк тә, кызларым, дөрес эшләгәнсез, ди. Яшьрәк, тәҗрибәсезрәк чакта ирләребездән дә аңа килеп зарлана идек. Безгә кушылып, ул да үз малайларын ачуланыр иде.

Лилия һәм Илшат Хәбибуллиннар гаиләсе турында аерым бер мәкалә итеп язарлык. Аларныкы кебек – икесе дә укытучы, икесе дә мәктәп директоры булган гаиләләр тагын бармы икән? Илшат Рафисович –







Мөслим районы Тойгелде сигезенче төркемдәге коррекция мәктәбе директоры. Волгоград дәүләт педагогика институтын тәмамлаган егет хезмәт юлын 2 нче номерлы Мөслим гомуми урта белем бирү мәктәбендә физик тәрбия укытучысы буларак башлый. Ә Сарман районы Иске Минзәләбаш кызы Лилиянең беренче һөнәре – хореограф. Алабуга мәдәният училищесын тәмамлагач, башта үз авылларының мәдәният йортында, аннары Мөслимнекендә эшли. «Бию сәнгатен Мөслимгә Лилия алып килде», – ди мөслимлеләр. 1994 елдан ул – мәктәптә. Чаллы дәүләт педагогика институты дипломын алган яшь ханымны 2003 елда Мөслим лицеена тәрбия эшләре буенча директор урынбасары итеп билгелиләр, 2016 елдан шунда ук директор була. Быелдан исә вазыйфаның тагын да җаваплырагы һәм катлаулырагы йөкләнгән. 2021 елның августыннан Лилия Хәбибуллина Мөслим районы Мәгариф идарәсен җитәкли. Булдырачак! Ул директор чагында Мөслим лицее Россиянең иң яхшы 100 мәктәбе исемлегенә керә. Җитәкче урынында утырса да, укыту эшен дә ташлыйсы килми әле аның. Яңа уку елында да рус телле балаларга татар телен укытуны дәвам итәчәк. «Яраталар бит! Өйрәнәселәре килә. Светлана Макарчян дигән бер укучым татар теле буенча республикакүләм олимпиада призеры булды. Яратмасалар, чатнатып татарча сөйләшә белмәсләр иде», – ди Лилия ханым.

Илдар, Илшат, Илгизнең аралары алтышар яшь.

– Безнең әти 18 ел «садик»ка йөрде, – дип шаярта уллар. – Әнинең балалар бакчасына илткәнен бик хәтерләмибез дә...

– Иртәнге сигезенче яртыда мәктәптә булырга кирәк иде бит. Әтиләре уятып, киендереп илтер, кич алып кайтыр иде... Улларыбызның өчесе дә рәсемгә һәвәс. Монысы да әтиләреннән. Дәрес өчен кирәкле барлык күргәзмә әсбапны Рафис абыегыз ясап бирә торган иде... – Фәнисә апаның бу сүзләрендә иренә ихтирам да, рәхмәт тә бар.

– И-и, ул иҗекләрне, хәрефләрне күп ясадым инде, – дип, хатирәләрне элеп ала Рафис абый. – Әле кочагы белән дәфтәр тикшерешәм. Фәнисәнең өйдә торырга вакыты да булмады бит аның. Бер кызык сөйлим әле. Илдарның кечкенә вакыты. Әниләре Казанга укырга китте. Көн дә чиста киемнәр кидереп, бакчага илтәм. Беркөнне тәрбиячесе: «Әниең укуда, син кем белән яшисең?» – дип сорый икән. «Әти белән!» – ди икән Илдар. «Киемнәрең бигрәк чиста, кем юа соң аларны?» – дигәч, Илдар: «Безнең әти кыз бит ул!» – ди икән.

– Малайлар бик тырыш булды, – ди Фәнисә апа уллары хакында. – Эшне хатын-кызныкына, ирләтныкына бүлмәделәр. Мал-туарны да карадылар, пешерделәр дә... Уртанчысы Илшатка күбрәк эләкте инде. «Мич тә ягарга кирәк, мал да карыйсы бар, әйбәт укырга да кушасың...» – дияр иде балакаем. – Ул арада каяндыр сабый кулы белән язылган бер бит кәгазь алып килеп, өстәлгә куя. Төпчекләре Илгизгә үзе әйтеп торып яздырган бәрәңге тәкәсе рецепты икән. Ничә еллар саклаган шуны.

Илгиз үзе дә хәтерли әле аны:

– Әни гел эштә. Мәктәп икешәр сменада эшләгән елларда аны күрми дә идек. Тәмле әйбер дә ашыйсы килә бит. Еллар җиткәч, бәрәңге тәкәсе пешерермен, бәрәңгесен юып, әрчеп, турап куегыз, дип, әни күрсәтмә биреп китә. Ул әйткәннәрне эшләп куябыз. Кайта да, бүген бик арыдым, дип, шул бәрәңгене кыздырып кына ашата. Шулай булгач, ашарга пешерергә дә үзебезгә өйрәнергә туры килде.

– Нинди эшкә тотынсалар, шуны эшли торган уллар үстергән әти белән әни, – ди килендәшләр. – Кирәк икән – бәлеш салалар, кирәк икән – түбә ябалар.

...Быел Мөслимдә Россия Федераль Сабан туе узды. Мөслимгә кадәр кил дә, Ык буйларын бер урама, имеш! Велосипедларга утырган Хәбибуллиннарга ияреп, Сабантуй мәйданы булган уйсулыкка юнәлдәбез. Илгизләр, Илдар, Илшат, Гөлназ, Гөлшат, Лилияләр, алардан алда балалар – җилдерәләр генә.

– Җәй көне барыбыз да велосипедта, кыш көне чаңгыда без. Беребез әйткәнне калганнар күтәреп ала. Бездә – коллективизм, – ди алар.

«Безгә бергә күңелле!» Бу сүзләрне әллә ничә ишеттек ул көнне алардан. «Сез чынлап та шулай бердәмме?» – дип, кат-кат сорадым. «Чынлап!» – диләр.

Аһ итәрлек матур җирләр! Шундый матур кешеләр! Ул матурлыкны шушы язмага сыйдырырга шулкадәр тырыштым, сыйдырып бетереп кенә булмады кебек...







PRESSA

МОРЗА ТЕРЕГУЛОВЛАР НӘСЕЛЕ

Лирон ХӘМИДУЛЛИН

Әзәрбайҗан мәдәнияте тарихында милләттәшләрем эзе турында язарга алындым (Без, гадәттә, азәрбайҗан рәвешендә язабыз. Шул милләт вәкилләре белән аралашканда исә күпчелеге үзен «мин әзәри» дип таныта иде. Кем хаклы? Бу сүзнең язылышын Энциклопедия институты галимнәре раслаганча кулланам.)
Дөньяви тәрбия алган, заманча укый-яза белгән татар кызлары узган гасыр башларында Урта Азия халыкларында да, Кавказ мөселманнарында да «затлы килен» саналган. Бигрәк тә кардәш казакъ халкында безнең милләт кызларын үз иткән гаиләләр ишле булган. Казакъ халкының танылган язучысы Сәүрбәк ага Бакбиргәнев бервакыт миңа үз милләттәшләре арасында элегрәк бик еш кабатланган бер әйтемне кәгазь битенә язып та күрсәткән иде: «Казакъ баласы укып белем алса, бер нугай кызына кияү булыр». (Әйе, казакъ кардәшләр үзара сөйләшкәндә безнең милләт вәкилләрен еш кына «нугай» дип атый.) Шул әйтемгә нигезләнеп, ул совет чоры казакъларының зыялы катламыннан шактый гына мисаллар да китерде.



Абдул-Мөслим Магомаев хатыны Бәдыйгөлҗамал (Терегулова) белән.

Кавказда яшәп, төрки телдә сөйләшкән кешеләрнең күпчелеге үзара аралашканда еш кына «татар» булып йөргән.

Хәер, үзем якыннан аралашкан казакъ язучыларында да шундый язмышлы шәхесләр шактый иде. Шул ук Сәүрбәк ага да, сугыш чорында Әгерҗе госпиталендә дәваланганда, үзенә тиң ярны безнең кызлар арасыннан сайлап ала. Совет чоры казакъ әдәбиятының күренекле вәкилләре Шерхан Мортазаев белән Саин Моратбәковның аналары, Әнүәр Әлимҗановның исә сөекле җәмәгате безнең милләт кызлары иде.

Инде Кавказ төбәгенә бәйле бер мисал. XIX йөзнең егерменче елларында ярым мөстәкыйль рәвештә яшәгән Кавказ халыкларын Россиягә «кушу» башлана. Ул сугышларда байтак кына татар яисә татарга күпмедер дәрәҗәдә мөнәсәбәте булган кешеләр дә катнаша. Мисалга, руслашкан татар әбисе тәрбияләгән Михаил Лермонтовны атап китү укучылар өчен кызыклы булыр. Кавказда хәрәкәт итүче армиягә эләккәч тә ул, кумык, нугайлар белән аралашып, җирле төрки сөйләм теле белән кызыксына башлый. Моны аның шигырьләрендә дә, атаклы повестенда да күреп була. Повестендагы баш героиня Бэланы гына искә төшерегез. Бу шук кызны туган абыйларының «бәла, бәла» дип йөрткәнлеге әсәр тукымасында ук китерелә. Һәм әлеге сүз яшь офицер Печорин өчен исемгә әверелә...


Касыйм ханлыгыннан чыккан морза Хәсән Сафар улы Терегулов гаиләсендә үскән кызларның язмышы да Сәүрбәк аганың минем дәфтәргә язып куйган әйтемгә бик тә туры килә. Кавказ таулары артына барып чыккан йомышлы татар морзасы Сафарҗанга һәм аның шул төбәк тарихында тирән эз калдырган гаиләсенә багышланган истәлек язмаларына күз төшереп алыйк. Әзәрбайҗанлы Исмаил Умидле (Өметле) «Татарский род Терегуловых» дигән мәкаләсендә болай дип яза: «Идел төбәгендә туган татар морзасы Сафарҗан егерме еллап рус армиясендә күпер төзүче буларак хезмәт итә. 1845 елда отставкага чыккач, гаиләсе белән Тифлис каласында яшәп кала. Ул вакытта аның Владикавказ шәһәрендә хезмәт иткәндә туган кызы Фатыйма белән ике улы – Хәсән һәм Ибраһим була. 1835 елда туган Хәсән соңрак Тифлистагы сөнниләр мәзһәбен тотучы мөселманнар мәчете имамы итеп сайлана. Ә 1889 елда ул бертуганы Ибраһим белән шул ук шәһәрдә рус-татар мәктәбен ачып, балалар тәрбияләүгә дә үз өлешен кертә. Тифлис каласының шәрәфле әгъзасы Гасан (Хәсән) Сафар углы 1911 елда вафат була». (Кавказ халыклары арасында яшәгән милләттәшләребезнеңшул төбәк йоласына хас рәвештә, Хәсәннең соңрак Гасан булып теркәлүе, Хәнәфинең – Ганафи, Фатыйманың Патимат дип атала башлауларына аптырамаска тиешбез.)

Сафарның өлкән улы Хәсән-Гасан шулай ук Касыйм төбәге морзалары нәселеннән булган Мәскәү кешесе Акмаев кызы Раббияга өйләнә, диелә әлеге язмада. (Бу хатын-кыз исеме Рабиганың да Кавказ халыклары теленә тартымрак итеп үзгәртелгән булуы ихтимал.) Хәсән мулла белән Раббияның XX йөз башында төшкән фотолары сакланган. Алар алты кыз һәм өч ул тәрбияләп үстергәннәр.

Иң элек уллары Хәнәфи (Мөхәммәдхәнәфи, кавказчалаштырганнан соң Ганафи, 1877–1942) Бакуга күчеп, шунда танылган шәхескә әверелә. 1908 елда әзәрбайҗан телендә куелган тәүге операларның берсендә («Ләйлә вә Мәҗнүн», композиторы Гозәер Гаҗибәков) төп рольләрне башкара, хор җитәкчесе була. «Каспий» газетасының 1909 елга караган бер санында Гасан Тернекулзадә башкарган роль турында: «Играл удачно, пел недурно», – дип язалар. Әзәрбайҗанның милли җанлы нефтьче магнатлары ачкан музыкаль театрда уйналган беренче милли опера була бу әсәр. Әлеге вакыйгадан соң театрда музыкаль әсәрләр еш куела. Шул ук газетаның 1915 елгы санында җырчы артист Хәсән турында: «Выделялся своим голосом и игрой», – дигән сүзләр дә теркәлгән. Аның опера җырчыларын тәрбияләүче педагог булуы да билгеле. Башка операларда да, шул исәптән, «Гозәер кияү»нең «Аршин мал алан» музыкаль комедиясендә дә төп рольләрне башкара. Сәхнәдә аны Терникулзадә (Терегулов фамилиясенең әзәрбайҗан теленә тартым варианты) буларак күбрәк беләләр. Операларда җырларлык осталыкка ул Тбилисидан ерак булмаган Гори шәһәрендәге укытучылар семинариясенең төрки-татар бүлегендә укыганда өйрәнә. (Шул ук шәһәрдә ул елларда Иосиф Джугашвили-Сталин да укыган.) Ул уку йортында җырларга, музыка коралларында уйнарга өйрәтү дәресләре югары дәрәҗәдә оештырылган. Әзәрбайҗан халкының рәсми танылган беренче композиторлары Гозәер (Узеир) Гаҗибәков белән Мөслим (Абдул-Мөслим) Магомаевларның да шунда музыкаль белем үзләштерүләрен әйтеп китү кирәктер. Алар анда Хәнәфи һәм Али Терегуловлар белән бер чордарак укыйлар. Тифлиска бергә кайтып йөргәндә Терегулов морзаларның тәрбияле сеңелләре белән дә танышалар.

1917–1920 еллардагы түнтәреш вакыйгаларында да катнаша Хәнәфи. 1917 елда Бакуда милләттәшләребезнең «Берлек» берләшмәсен оештырыша, 1918–1919 елларда Идел–Урал тарафларында акларга каршы сугышып йөри. 1920 елда янә Бакуга әйләнеп кайта, Әзәрбайҗан Республикасы

Әзәрбайҗанда исә нәсел җепләре морза Терегулов белән Акмаевларга барып тоташкан гаиләләр байтак.



Раббия Фәхретдин кызы һәм Хәсән (Гасан) Сафар улы Терегуловлар. XX йөз башы.



Хөршидә һәм Әдһәм Акмаевлар.



Бибилатыйфа һәм Ибраһим Акмаевлар.



Мәликә һәм Гозәер Гаҗибәковлар.

коммунистларының Үзәк Комитетында эшләп ала. 1929 елда аңа Хезмәт Батыры дигән мактаулы исем бирелә.

Энесе Али Хәсән улы Терегулов (1883–1950) гомерен педагогикага багышлый. Аның скрипкада оста уйнаганлыгы мәгълүм. Гозәер Гаҗибәковның «Ләйлә вә Мәҗнүн» операсы беренче мәртәбә сәхнәләштерелгәндә, аңа баш скрипкачы вазыйфасын башкарырга туры килә. Ул да Гори шәһәре семинариясенең төрки бүлеген тәмамлаган. Шунда укыганда ул булачак композиторлар һәм кияүләр Гозәер Гаҗибәков һәм Абдул-Мөслим Магомаев белән дуслашып китә. Алар да шул семинариядә укыганда скрипка һәм фортепианода уйнау серләрен үзләштерәләр.

Хәзер инде укымышлы мулла Терегулов гаиләсеннән чыккан тәрбияле, укымышлы кызлар тирәсенәрәк килик. Аларның икесе – Мәликә белән Бәдыйгөл – әзәрбайҗан милләтенең иң мәшһүр ике композиторы Гозәер Гаҗибәков белән Абдул-Мөслим Магомаевта, ә өченчесе – Хөсниҗамал – шушы ук даирәгә якын торган Хәмзә (Гамзат) Хәлиловта кияүдә булалар. Гомерен укыту эшенә багышлаган, 1954 елда Бакуда бакыйлыкка күчкән Мәрьям Терегулованың ире Гобәйдулла Гасыймовның да музыкага якын кеше булуын әйтеп китү кирәктер.

Әүвәл Хәлиловларның ике улын искә алып үтик. Руфат (Роальд) Гамзат улы Хәлилов (1894–1970, Франциядә вафат) үз илендә – җырчы-артист, ә 1920 елларда иленнән киткәч – чит ил сәхнәләрендә Кавказ халыклары биюләре остасы буларак дан казана. Рамазан Гамзат улы Хәлилов (1901–1999) исә республикада җәмәгать эшлеклесе буларак таныла. 1950–1960 елларда ул Бакуда опера театры директоры вазыйфасын үти. Элегрәк исә җизнәсе Гозәер Гаҗибәковның шәхси сәркатибе һәм депутат ярдәмчесе була. Ә пенсиягә чыккач, Г. Гаҗибәков музееның директоры булып эшли. Руфат Хәлиловның биографиясенә безнең илдә бик әһәмият итүче юк бугай. Әзәрбайҗанлылар да аны сирәк искә алган. Ә менә атаклы җырчы, композитор Мөслим Магомаевның оныгы Мөслимгә багышланган кинофильмда ул күренеп китә. Мөслим Магомаевның көндәшләре, аның Парижда Руфат агасы белән очрашуыннан файдаланып, «чит илдә калырга ниятләде», – дип яла ягачаклар. Аны чит илләргә чыгучы артистлар исемлегеннән сызып ташларга тырышачаклар.

Мәликә Хәсән (Гасан) кызы Терегулова (1893–1966) белән Гозәер Гаҗибәков (1885–1948) Бакуда 1909 елда өйләнешәләр. Ул вакытта инде Гозәер, беренче операсын сәхнәләштереп, әзәрбайҗан кардәшләребез арасында зур дан-шөһрәт казанган була. Бер-бер артлы «Мәшһәди Ибады», «Көр углы» кебек атаклы опералары, «Аршин мал алан» музыкаль әсәре сәхнәләштерелә. Соңгы әсәр исеме шулай ук русча да тәрҗемәсез язылa. «Аршинлап мал алыгыз» дигәнне аңлата. Ә «Көр углы» операсы шул исемдәге борынгы төрки дастаны сюжетына нигезләнгән. Ул либреттолар авторы буларак та билгеле. СССРда яшәп иҗат иткән

төрки композиторлардан беренчеләрдән булып консерватория бусагасын атлап кергән шәхес. 1913 елда Петербург консерваториясенә барып урнаша, соңрак укуын Мәскәүдә дәвам итә. Баҗасының һәм яшьлек дустының оныгы, мәшһүр җырчы Мөслим Магомаев «Живут во мне воспоминания» китабында консерваториядә укыганда Гозәергә бабасының матди ярдәм итеп торганлыгын әйтеп үтә. Икенче бер автор язмасында исә «преданная супруга Мелика ханум»ның да Гозәернең иҗади эшендә даими ярдәмчесе булганлыгы бәян ителә. Хәсән мулла кияве Гозәер Гаҗибәков соңрак Әзәрбайҗан Республикасы Композиторлар союзы рәисе, шул республика академиясенең академигы булып сайлана, СССР Югары Советының 1 нче, 2 нче чакырылыш депутаты була.

Бәдыйгөлҗамал Хәсән кызы Терегулова (?–1963) – Мәликәнең туганы. 1907 елдан ул музыкант Абдул-Мөслим Магомаевта (1885–1937) кияүдә. Оныгы Мөслим Магомаев истәлекләрендә дә, кайбер башка язмаларда да аның «искиткеч гүзәл гөл» мәгънәсенә тиң исемен «Байдигюль» (болын, кыр гөле) рәвешендә үзгәртеп тә язалар. Семинария тәмамлагач, Абдул-Мөслим берничә ел Ленкоран шәһәрендә укыта. Шул вакытта алар кавышалар. Алар гаиләсе 1911 елда Бакуга килеп урнаша. Алда телгә алынган бертуган Терегуловлар һәм Гозәер Гаҗибәков белән Мөслим Гори семинариясендә укыган елларында таныша. Үзе Грозныйда туган. Бер язмада аның кумык милләтеннән булуы әйтелә. (Оныгы Мөслим аның кайсы милләттән икәнен белмим дип яза.) Безнең төбәкләрдән чыгучыларны аерып күрсәтергә кирәк булганда гына, әзәри кардәшләр «Идел буе татары» яисә «Казан татары» төшенчәләрен кулланган. Абдул-Мөслим дә, гомерен әзәрбайҗан сәнгатен үстерүгә багышласа да, әлеге семинариядә уку елларында безнең милләт вәкиле исемен дә йөрткән бугай.

Абдул-Мөслим ятим үсә. Яшьтән үк төрле музыка коралларында уйнау белән мавыга. Тырышлыгын истә тотып, укыган елларында ук аңа скрипка бүләк итәләр дип яза оныгы. Олы Мөслим иҗат иткән һәм сәхнәләштерелгән опералар: «Исмаил шаһ» (1916) белән «Нәргиз» (1934), ә тәмамланмаган әсәре «Һаруз бәй» дип исемләнгән икән. Яшьтән төрле оркестрларда, төрле уен коралларында уйнаудан тыш, ул Әзәрбайҗан Республикасы радиокомитетының музыкаль бүлеген дә җитәкләгән. Бадыйгөл белән алар ике ул тәрбияләп үстерәләр. Җамалетдин Магомаев (1910–1977) – дәүләт эшлеклесе, гомеренең соңгы елларында Мәскәүдә Әзәрбайҗан ССР вәкиле булып тора. Кече Мөслимне – атаклы опера җырчысын тәрбияләп үстерүче дә була ул. Җәмәгате – рус милләте вәкиле Мария. «Безнең өйдә аралашу теле рус теле иде. Мине ачуланасы булса гына әбием татарчага күчәр иде», – дип яза җырчы Мөслим. Аның әтисе Мөхәммәт (Магомет) Магомаев (1916–1945) театр рәссамы булган, сугыш кырыннан әйләнеп кайтмаган. Аның үлү хәбәре килгәч, хатыны Бакудан китә, РСФСР шәһәрләрендә, рус театрларында эшли. Берничә мәртәбә кияүгә чыга. Шул рәвешле, 3 яшьтән кече Мөслим, ата-анадан аерылып, Бәдыйгөл әбисе белән атасының олы агасы тәрбиясендә үсә. Әлеге истәлек китабында ул «татар әбисен» бик еш искә ала. «Мине ул тәрбияләде, – дип яза. – Берәр кирәкмәс эш эшләсәм, мине татарча орышыр иде», – ди. Әйе, Мөслимнең әнисе улына 3 яшь тулыр-тулмастан читкә китә. Өйдә хуҗабикә рәвешендә өлкән килен Мария да яшәгәнлектән, төп сөйләшү русча булган. Бәдыйгөл карчык, килен алдында сер бирмәс өчендер, мөгаен, оныгы белән шулай «үз» телләрендә дә сөйләшкәләп алгалагандыр, күрәсең.

Гозәеров белән Магомаевларның Мәскәүдә яшәгән туганнарын – Раббия Акмаеваның якыннарын да искә алыйк. Әминә (ире буенча Бабкәева) һәм Ибраһим Акмаевлар белән элегрәк кем, ничек аралашкандыр, әйтә алмыйм. Әмма үзара элемтәләре өзелмәгән. Сугыш алды елларына караган истәлекләр дә бар. Ә сугыштан соң Гаҗибәковлар гаиләсе дә, Бәдыйгөл белән улы Җамал да Мәскәүдә яшәгән туганнарына еш барганнар. Шуны дәлилләгән кайбер фотолар да сакланган. Миндә алар бар. Җырчы Мөслим, 1959 елда Мәскәү консерваториясе белән танышырга килеп, түләүле студиядә тавышын яздыргач, акчасыз кала. «Монда безнең туганнар да бар инде, тик минем кешедән соранып йөрисем килмәде. Әбием акча җибәргәнче, дүрт көнләп ач яшәдем», – дип яза ул.

Ибраһим белән Бибилатыйфа Акмаевларның улы Әдһәм ага Акмаев (1916–2006) Казанда гомер итте. Һөнәри белем бирүче уку йортларында укытучы да, директор да булды. Пенсиягә чыкканчы, ун-унике ел чамасы һөнәри белем бирүче республика мәгариф оешмасы башлыгы урынбасары булып эшләде. РСФСРның атказанган укытучысы иде. Ара-тирә очрашкалаган вакытларда ул Әзәрбайҗандагы туганнарын да искә төшергәләде. Югары Совет депутаты Гозәер Гаҗибәковның кайнеше һәм ярдәмчесе булган Рамазан Хәлилов белән бергә Мәскүдәге Әминә апалары дачасында төшкән күмәк фото саклана. Анда Әдһәм Акмаев та бар. Ләкин Мәскәүдә яшәмәгәч, ул алар белән сирәгрәк очрашкан шул. Хәзер инде ул фотолар һәм истәлекләрне Әдһәм аганың җәмәгате, пенсиядәге табибә Хөршидә ханым белән кызы Алия Акмаевалар бик кадерләп саклап тоталар. Бу язмама тотынганда мин дә аларда сакланган истәлекле язмаларга таянып эш иттем.

Казанда шул ук кавказлы Терегуловлар нәселенә бәйле икенче бер гаиләнең яшәгәнлеге дә мәгълүм.

Фотолар: автор архивыннан



Шагыйрә Флёра апа Гыйззәтуллина бу көннәрдә үзенең 90 яшьлек юбилеен каршылый. Тормышның ачысын-төчесен күп күргән, ятимлекне кичергән, җилкәсендә шпаллар ташып, Себердә тимер юллар салган, Донбасс шахталарында эшләгән, ательеда киемнәр, туннар теккән Флёра апаның иҗаты да язмышы кебек тирән, кичерешләргә бай. Анда җылылык-наз да, тылсым-могҗиза да, батырлык-тәвәккәллек тә бар. Төрле төсле җепләр белән чигү чиккән кебек кенә итеп яза да, шигырьләре нәфис сурәт, матур картина, кайнар хисләр булып күңелгә кереп кала. Укып карагыз әле, үзегез дә инанырсыз шуңа...

Флёра ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА

СЕР АЧКЫЧЫМ БИРДЕМ СЕРДӘШКӘ

Үлемсез ил моңы

Көрәшкә омтылыш,
Гомерлек киң сулыш
Бирелә кешегә тумыштан.
Туган ил кайгысы,
Төннәрнең айлысы
Җаннарга моң булып тулышкан.

Азатлык җылысы,
Өметнең нурлысы
Сарылган илемә, йортыма...
Коллыкта ут йотып
Ярсыган йөрәкләр
Иреккә, иреккә омтыла.

Үлемсез ил җыры,
Гасырлар зынҗыры
Аерылмый моң-зарлы татардан.
Кай юлдан узсак та,
Кемгә кул сузсак та,
Сүзне без башларбыз Ватаннан.

Җырларбыз җырларның
Көмештән койганын,
Чорларга дан итеп уйганын.
Татарстан, син минем
Йөрәгем, иманым!
Юк сине яратып туйганым.

Тарих сөйли

Һәр гасырның моңы, сагышы бар,
Ташка язылып калган тарихы бар.
Һәр гашыйкның сөю җилкәне бар,
Сөю сере ачкан Коръәне бар.

...Кулда – тарих!..
Өстәлемдә – Коръән!..
«Бисмилла...» дип сыйпыйм
Коръәнне –
Тәңрем язган сөю нигъмәтендә
Мин соң дөрес фикер йөртәмме?

Тиешенчә аңлый аламмы мин
Милләтемнең сихри җыр-моңын?..
...Борынгы моң, чорлар аръягында
Талгын гына тибрәлдереп ала
Моң агышын көмеш быргының.

Быргы моңы сайрый хәтерләтеп
Чишмәләрнең челтерәп акканын,
Кияү белән кәләш туйлап килгән
Ак атларның тояк какканын.

Тарих сөйли: дөнья имин торса,
Шатлык чәчеп йөзләр балкыган...
Ә Иленең иминлеге китсә –
Көрәшкән дә, татар кан койган.
Көрәш кырында да азан әйтеп
Каршылаган таңны,
Иртәне...
«Чишмә җыры» төшләренә кергән,
Үзе белән йөргән Коръәне.
Үзе белән йөргән бакыйлыгы,
Моңга ашкан мәңгелекләре,
Тормыш ярларыннан тулып ташкан
Ак хыялы, ак өметләре...

Кулда – тарих!
Өстәлемдә – Коръән!
Күзләремдә – Иман нурыдыр...
Җырлы, нурлы дөньям,
һай, олыдыр:
Мин шул олылыкның колыдыр.

Кичерерсең әле...

Туган телем!
Шундый моңлы бит син –
Җир шарларын җырлап әйләнәсең.
Бөдрә таллар бөреләнгән чакта
Талга ефәк булып бәйләнәсең.

Туган көнем!
Шундый якты бит син,
Сихри алкышларга күмелгәнсең.
Саф күңелле халкым йөрәгенә
Үрмә гөлләр булып үрелгәнсең.

Туган ягым!
Шундый шәфкатьле син:
Бөтен гөнаһымны кичергәнсең.
Миллиард еллар аккан таң суына
Татлы ширбәт кушып эчергәнсең.

Сөйгән ярым!
Күккә чөйгән ярым!
Син дә мине кичерерсең әле...
Ак күлмәкле айлы кичләреңне
Исләреңә төшерерсең әле.

* * *

Ни хикмәттер,
салкын кышлар җитсә,
Искә төшә Себер яклары...
Туган якны үлеп сагыну хисе
Бураннардан мине саклады.

Башкаемны тирән моңга салды
Тайгалары шаулап Себернең.
Шул тайгалар аша мин көн саен
Поезд каршыларга йөгердем.

Каршы алдым...
озатып калдым илгә,
Санап ничә вагон... эшелон...
Җанны тетрәндергеч михнәтләрдән
Эшелоннар төяп бушандым.

Гомеремнең минутын да ләкин
Уздырмадым анда бушларга:
Бозлы шпалларга рельс суздым,
Ут чәчрәтеп ялан учларда.

Бүген исә минем кулда каләм!
Шигырь уйлап һушым таркала!
Әйтерсең мин тирән тайга гизәм,
Чуен юллар кочып аркама.

Кое әйләнәсе яшел чирәм

Миңа бүген сагыш җиле тигән:
Көйсезлектән иреннәрем көйгән...
Кемнең иҗат коелары тирән? –
Коесына су алырга киләм.

Иҗат коеларын эзләп таптым,
Көннәр буе шуннан сулар тарттым.
Коеларга чүпләр төшермәдем –
Шик алмасын иҗат кешеләрен.

Кое әйләнәсе яшел чирәм,
Үзем эчмим, суын шунда сибәм.
Сибелә-сибелә сусавымны җиңәм –
Гомерләрем зая үтте димәм.

* * *

...Гомер уза...
Ә мин алга барам,
Яргаланам язмыш ярыдай.
Сөембикә алкасына охшап,
Баш очыма калка ярым ай...

...Гомер уза...
Узган гомер өчен
Айлы кичләр – моңлы тамаша!
Айның яктыртуы – борынгыча,
Моңаюы гына яңача.

...Гомер уза...
Еллар аръягына
Аударыла гомер олавы...
Сөембикә елавына охшаш
Җилләрнең дә быел елавы.

Рухы яши Казанда

Татарымның ачы аһ-зарларын
Җуялмаган чорлар агышы.
Казан ярындагы ак дулкында
Ханбикәнең үкси сагышы.

Дулкын сөзеп йөзә көмеш көймә
Сөембикә аһы тирәли.
«Сагышларга, гүзәл, бирешмә!» –
дип,
Ак болытлар ләйсән сибәли.

Бу ләйсәннәр өмет яңгырыдыр,
Никадәрле якты наз анда!
Сөрелсә дә үзе сөргеннәргә,
Рухы яши аның Казанда.

Рухы яши аның һәр татарда,
Азатлыкка, алга чакырып,
Иман иркендәге ярым айлы
Манаралар булып калкынып.

Иртәләрен ул да уйлангандыр,
Чумып ак дулкыннар шавына...
...Ничә гасыр инде Идел яры
Гүзәл ханбикәсен сагына.

Хәтердә

Күк күкрәп яңгырлар яуганда,
Пар яшен йөрәкне чорнады.
Яшенләп, тетрәнеп, сөюем,
Ярыннан чыгарды елганы.

Бу нинди газаплы сөю соң
Йөрәккә сүнмәс ут кабызган?
Без сузган мәхәббәт күперен
Ярсулы ташулар агызган.

Хәтердә вәгъдәләр елгасы:
Ашкына хыялга җитәргә...
Кызганам яшьлегем ярларын
Күперсез калдырып китәргә.

* * *

Җырда – аһәң,
Фәндә – гыйльми ачыш,
Йолдызларда сер дә сер инде...
Бу йолдызлы кичләр күзләремә
Бигрәк серле булып күренде.

Җыр җирлегем булган серле дөньям
Күз алдыннан мәңге югалмас!
Тәбрикләдем җирне, җыр агышы
Йолдызларга кадәр юл алгач.

Мин үзем дә сердә тирәнәйдем,
Сер ачкычым бирдем сердәшкә.
Дөнья белән серләр килешкәндә,
Без йолдызлар белән бер яшьтә.

Чәчләремне җилләр тарады

Илдә чакта башым түбән исәм дә,
Түбәнлеккә күңел бер дә күнмәде.
Кылганнарын сибелдереп, үрдәге
Таулар мине биеклеккә өндәде.

Үр менгәндә тау ташына абынсам,
Таш өстенә тамды кайнар яшьләрем.
Тауларга мин кара кайгы чәчмәдем –
Ак кылгандай ап-ак иде чәчләрем.

Чәчләремне минем җилләр тарады,
Алтын иде ул җилләрнең тарагы.
Илләр белән якынайтып араны,
Язмышларны дәвалыйсы бар әле...

* * *

Шатлыгың булса, уртаклаш,
Юлымны уңга юра!
Хәлемне беләсең килсә,
Син сандугачтан сора.

Сандугач кунган талларга
Калдыр син тамга уеп...
...Кипкән керләрне чылатып,
Яңгырлар яуды коеп.

Яңгырда тапланган керне
Агартып була кабат...
Күңелгә керләр кунмасын,
Калмасын хисләр сазап.



Ул үзе Рафаэль Хуҗин, әдәби псевдонимы – Рафаэль Сибат. Нократ буенда, Киров өлкәсенең Түбән Шөн авылында туган. Казан дәүләт университетының татар теле һәм әдәбияты бүлеген тәмамлаган. Укытучы, мәктәп директоры булып та, халык театрында – режиссер, классик көрәш буенча тренер булып та (яшьлек елларында үзе дә мәйдан тоткан, күп тапкырлар батыр калган!) эшләгән. Әдәбият дөньясында аны «татарның Шолоховы» дип йөртәләр. Талантлы прозаик, үзенчәлекле шагыйрь, ялкынлы публицист, оста тәрҗемәче... Кыска гына гомерендә дә 9 роман, 21 повесть, дистәләрчә хикәяләр, поэма, шигырьләр иҗат итәргә өлгергән. Быел Рафаэль Сибатның тууына – 75 ел. Игътибарыгызга язучының «Тамаша» хикәясен тәкъдим итәбез. 1978 елда язылып, моңарчы әле беркайда да басылмаган әлеге хикәя Рафаэль Сибатның архивыннан алынды.



Рафаэль СИБАТ

ТАМАША

Хикәя

– Менә нәрсә... – дип сүз башлады Гамир, колак артын кашып һәм идән ярыкларына караган килеш. – Торып та карадык... Булмас, ахрысы... Аерылышыйк...

Алдына чип-чиста алъяпкыч бәйләп, савыт-саба юып ятучы Сәрия иренә бер мәлгә сәерсенеп карап торды, аннан соң авыр итеп уфтанды, хәтта коңгырт чәчләре һәм калын күкрәге дерелдәгәндәй итеп селкенеп куйды. Гамирның аерылышыйк дип әйтүе беренче генә түгел, шуңа ул битараф кына эшен дәвам итте. Гадәттә «аерылышыйк!» дигәннән соң ире капылт кына сүздән тукталып кала иде. Ә бүген... Ир сүзен дәвам итте:

– Күңелдә сиңа карата бер җылы юк...

«Ничек инде җылы юк?» – дип уйланды хатын.

– Төннәрен йокы аралаш аяк-кулларыңны миңа ялгыш салып җибәрсәң дә, чирканып уянып китәм...

«Ходаем, шулай ук бака яисә елан тәнле микәнни мин?» – дип уйлый хатын.

– Үзең дә аңлыйсыңдыр бит...

Хатын аңлый: биш ел бергә торып, берсе 25 кә, икенчесе 30 га җитүләренә карамастан, аларның балалары булмады, шуңа күрә ире көннән-көн аннан читләшә, хәтта салып кайткан көннәрендә мәңгелек буйдак кебек аерым йоклый, шуның өстенә йөрәгеңне әрнетерлек, мендәреңә капланып үкереп еларлык итеп, тәмсез һәм укшыта торган сүзләр әйтә иде.

– Миңа бала кирәк, бала! – дип тәкрарлый ире.

– Балаларга кадәр мәхәббәт кирәк! – ди торган иде Сәриянең кияүгә барып кайткан дус кызы.

Шул сүзләрне исенә төшергән саен, безнең арада мәхәббәт дигән нәрсәнең эзе дә булмаган икән дип, соңгы көннәрдә үзе дә борчыла башлаган иде бит ул.

– Яратмыйм мин сине... Куралмыйм... – иренең соңгы сүзләре идәнгә бәрелгән кыйммәтле чынаяк ватыклары кебек өйнең тирә-ягына чәчелеп, аның колакларына ямьсез кайтаваз булып орылды.

«И Ходаем! Зинһар өчен сабырлыклар бир! Яратам бит мин аны. Аннан башка миңа беркем дә кирәкми!» дип, гомердә чынлап бер тапкыр да мөрәҗәгать итмәгән Аллаһка сүз кушты хатын, аптырап һәм хәйран калып.

– Бүген үк кит! Бүген үк!!

Гамир өстенә әле ул кичә генә өзелгән элгечен тегеп куйган бишмәтен киде һәм:

– Малларга печән салып керәм әле, – дип чыгып китте.

Аңа авыр иде... Әгәр футбол тубы булса (алар телевизор буенча барган бер генә футбол матчын да калдырмыйлар иде), хатын түзмәс, шартлар иде...

* * *

Гөлзифа карчык күршеләреннән чәйләп кайтып керсә, өй эче таң алдындагы кебек тып-тын, ә улы Гамир караватта йокымсырап ята.

– Килен кайда, улым?

– ... ...

– Килен кайда, дим?

– Китте...

– Кая китте?

– Бөтенләйгә...

Карчыкның башына мәрхүм карты Гыйльметдин ясаган имән тукмак белән суктылармыни – лып итеп урындыкка утырды, гаҗәпсенү катыш рәнҗү белән тулы күзләре улына беравык карап тордылар да бәреп чыккан яшьләренә ирек куйдылар. Карчык тавышсыз гына елый иде. Аһ ул тавышсыз елауны! Үзәкләрне өзә, үкереп елаганнан да катырак газаплый, җитмәсә, тышта февраль бураны котыра, яман итеп җил сызгыра, чылбырга бәйләгән Актүш ифрат моңлы итеп улый, бакчадагы карт шомырт һәм алмагач ботаклары сынардай булып каерылалар, лапасның кадагыннан ычкынган түбә тактасы, ачуланып, шыгыр-шыгыр килә, гүя кемгәдер дулый.

* * *

Аннан соң нәкъ ярты ел узды. Гамир әкәм-төкәм кебек үз кабыгына йомылды: беркем белән ачылып китеп сөйләшми, колхоз акча биргән көнне элеккеге кебек эштән соң шоферлар белән җыелып хезмәт хакын «юмый», дуслары белән аралашмый, бары машинасын гына баштагыча ярата, ремонт вакытларында гаражда кичкә кадәр булырга тырыша. Дөресен әйткәндә, ул үзенә «бәхетсез» дигән ямьсез ярлыкны ертык күлмәккә таккан җөй итеп ямап куйды.

Бүген аның күңеле боек. Төшендә үзенең үлгәнен күрде. Ничек кергән андый төш! Менә аны кара авызын ачып торган кабергә ап-ак кәфенгә урап салалар... Ул кабер төбенә дә төшеп җитми, тиз-тиз генә (әйтерсең ялгыш чыга күрмәсен дип) балчык кантарлары ыргыта башлыйлар. Шап-шоп, шап-шоп! Күз ачып йомганчы каберен күмәләр дә зираттан югалалар... Аның өчен ник бер елаучы булсын, аннан-моннан өелгән каберен яшел чирәмле кәс белән матурлап әйләндереп алырга ник бер кеше калсын... Ул боларның барысын күреп тора, имеш... Күреп тора һәм шаккатып тора, имеш...

Эштән ике сәгать чамасы алдан кайтып китте. Гөлзифа карчыкның сораулар белән тулган карашына игътибар итмәстән, чишенде дә диванга барып ятты.

– Нишләп иртәләдең, улым?

– ... ...



Рәсем: Наталья Васильева



– Нишләп иртәләдең, дим?
– Кәеф юк...
– Аш та пешеп җитмәде әле...
– Эч поша...

Карчык, аның өчен күеп әрле-бирле таптанып торгач, ничә еллар хезмәт иткән җиз комганын күтәреп, тышка чыгып китте. Ә Гамир күзләрен йомган килеш диванда ята бирде.

Күп тә узмады, өйгә кемдер керде, ничектер кыюсыз гына, үзе белән исәнләшкәндәй итеп:

– Исәнмесез? – диде.

Гамир күзләрен ачты, бер мәлне томанлы сын күрде, аннан соң үз-үзен көзгедә түгел, тереләй, җанлы килеш күргән кебек бөтенләй өнсез калды.

– Сә-ри...-я? – аның тавышы чыкмады булса кирәк.

Авыр тынлык... Бу тынлыкны бозар өчен икесе дә бомба шартлатырга риза иделәр. Әйе, бомба шартлатырга! Болай торганчы, каядыр очарга һәм югалырга. Юк, юк! Очарга була, әмма югалырга ярамый! Аның күзләренә карамыйча, беренче сүзне яшь хатын башлады:

– Мин... миңа... Минем яшь язуым белән язылышу турында кәгазь... сездә... бездә... монда калган иде.

– Бирмим! – дип кырт кисте ир.

Ә хатын борып куелган магнитофон кебек сөйләвеннән туктый алмады:

– Без... безнең... авылның Гайфул... (Сәрия күрше авылныкы иде) сорап килгән иде... Ризалык... синең белән дә... безгә суд белән аерылышырга...

– Аерылышырга?! – Гамир аптыравыннан калтырый башлады.

– Юк, бирмим! – диде ул тагын кырт кисеп.

Һәм тиз генә Сәрияне кочаклап алды да диванга утыртты, аннан соң йөгереп барып өй ишегенең келәсен төшерде.

– Бирмим! Бернәрсә дә бирмим... Беркемгә дә бирмим... Сине беркемгә бирмим, ышанасыңмы, бирмим. Минем кеше өчен әзерләп куйган хатыным юк. Минем хатыным бер генә... Сине кешегә бирсәм, үземә нәрсә кала? Юк! Юк! Юк!.. Бирмим!!

Ул аның өстен чишендерә-чишендерә шулай сөйләнә, сүз саен «Бирмим!» дип кабатлый, аны коча-үбә, шашыныр дәрәҗәгә җитеп иркәли. Ярты ел үзара сагынышып яшәү икесен дә исерткән, ә сөю дәрте вакытлыча бөялеп торганнан соң, үзенә юл алган язгы ташкын су кебек – тыйгысыз, көчле, омтылучан, дәһшәтле!

* * *

Ишекне бер кулы белән генә ача алмаган Гөлзифа карчык, аптырап торгач, җиз комганын җиргә куйды да ике куллап тартып карады. Юк! Селкенми дә...

– Улым... Улы-ы-ым!

Җавап бирми. «Йокыга киткәндер...» – дип уйлады карчык.

Ул елны август салкын килеп, яңгыр койды да койды. Шуңамы, өстенә Гамирның иске кәчтүмен генә салып чыккан ябык гәүдәле карчык туңа ук башлады. Арык беләкләре, яшәү төсен онытып, күгәреп үк чыкты.

«Уянгач ачар әле... Менә әкәмәт! Нигә бикләде икән ул аны?.. И-и Аллам, шул килен киткәннән бирле сәер тота бит инде ул үзен. Бер-бер хәл-әхвәл булмаса гына ярар иде...» – дип сөйләнә-сөйләнә, җиз комганын кулына тоткан килеш күршеләренә юл тотты.

Ләкин анда да озак утыра алмады, бер чынаяк чәй эчкәч, унбиш минутлап утырды да чыгып китте. Кайтып керсә – тамаша! Улы диванга утырып, әллә ничә көннәр әйтеп тә төзәтергә оныткан электр плитәсен рәтли, өстәлдәге чәчәкле-чуклы поднос өстендә дәү самавыр бар көченә җырлап утыра, казанда быгырдап аш кайнап ята, ә элеккегә караганда да яшәреп һәм матурланып киткән килене, ак алъяпкычын ябып, савыт-саба, чәй чынаяклары юып маташа. Өйгә тәртип кергән, юк, хәтта почмакларына кадәр нур иңгән!

* * *

Аннан соң тагын дүрт ел узды. Кунакка кайткач, аларга кереп утырдым (безнең әни белән Гөлзифа карчык бертуганнар иде). Гадәттәге чәй янында гәпләшә торгач, мин берсенә дә карамыйча гына шул узган хәлләрне сәерсенгәндәй сорап куйдым (дөресен әйткәндә, мәнсезрәк сорау иде ул):

– Ничек булды соң ул сезнең аерылышу?

– Казус... – диде Гамир, бу темага керергә теләмичә.

Мин елмаеп куйдым: ул һаман казус, парадокс, хаос кебек сүзләрне кыстыргалап сөйләшергә ярата икән.

– Бер болганмый су да тонмый, – диде Сәрия көлемсерәп һәм чиксез ярату белән иренә карады.

– Сынау булды, зур сынау икесенә дә... – дип куйды Гөлзифа карчык, алтын пута йөгертелгән чынаягына чәй агыза-агыза.

Шул вакыт түргә як ишеге ачылып китте һәм туп кебек тәгәрәп кара чәчле, чия күзле ике игезәк малай килеп чыкты: болар бер-берсенә су тамчысыдай охшаганнар иде.

– Әннә! – диде сулдагысы.

– Әттә! – диде уңдагысы.

Гөлзифа карчык, кочагын киң җәеп, аларны чакырып алды да берсен сул тезенә, икенчесен уң тезенә утыртып, әле берсенә, әле икенчесенә чиратлап чәй эчерә башлады.

Гамир Берлинны алган солдат сыман шатланып түшен киерде, ә Сәриянең болай да түгәрәк йөзе кояш формасын алды.

«Менә сиңа тамаша!» дип уйладым мин, сөенечемне яшерә алмыйча. Кеше бәхете – ир белән хатын бәхете өчен чиксез дулкынлануымны күрсәтмәс өчен, «берәрне кабызып керәм әле» дигән булып, ишегалдына чыктым. Ник дигәндә, күзләремне хыянәтчел яшь бөртекләре каплаган иде...

Без белми торганбыз: тышта кояшлы җылы яңгыр – ләйсән яңгыр ява икән!

1978 ел, Шөн.

БЮРО **B** БАНУ

ТР, Казан, Габдулла Тукай ур., 72 нче йорт, 2 нче офис. Тел. +7 917-250-25-89 burobanu



Бүгенге көн белән үткәннәр арасын бәйләүче җепләр сузганда BURO BANU (БЮРО БАНУ) брендына нигез салучы Элара Шәйхи һәм Гөлнара Хәмәева тарихи орнаментларны яңадан торгызу, милли татар бизәкләрен заманча трендлар белән үреп бару, саклык белән генә борынгы гореф-гадәтләрне яңарту максатларын күз алдында тотып эшлиләр.

«BURO BANUда ай саен кабатланмас яңа эшләнмә тәкъдим итәбез. Аларның һәрберсе алга таба коллекциянең бер өлеше булып кереп кала. Бөтен нечкәлекләрен, детальләрен исәпкә алып зәвыклы образлар тудыруга зур игътибар бирәбез. Элек кулланылган фасоннарны, киселешләрне, декоратив элементларны кертеп, махсус чаралар өчен үзенчәлекле образлар гына тудырып калмыйча, көндәлек тормыш өчен уңайлы кием иҗат итәбез. Заманча җәмгыять таләпләренә җавап бирерлек киемнәр булсын дип тырышабыз», – ди Элара Шәйхи.

«Татар милли модасын хәзерге заманда куллану трендын Президентыбыз Рөстәм Миңнеханов кертеп җибәргән иде. Без дә аны куәтләп, милли киемне популярлаштыру максатыннан эшләнмәләрне, костюмнарны прокатка да бирәбез. Шул рәвешле, теләге булган һәр кешегә татар милли образында күренергә, узган эпоханың тарихи-мәдәни кыйммәтен үзләрендә тоярга мөмкинлек тудырабыз», – ди Гөлнара Хәмәева.

BURO BANU туган ягыбыз мәдәниятен һәм татар модасын популярлаштыруга үз өлешен кертә алуы белән чын мәгънәсендә горурланырга хаклы!

РЕКЛАМА

RESEDA ODOR®

RESEDAODOR – молекуляр косметика бренды ул. Профессиональ һәм өй шартларында тәрбияләү, тирене яшәртү өчен кулланыла.

Косметика Хәләл сертификатына ия, зарарсыз булуны тагын бер кат раслый.
«In Cosmetics» халыкара конкурсында 8 молекула инновацион молекулалар һәм
тәэсир итү механизмнары буларак алтын һәм көмеш медальләр яулаган.
Барлык активлар да Франциянең һәм Италиянең R&D лабораторияләрендә
җитди клиник тикшеренүләр узган һәм халыкара сертификатларга ия.









Фотода: тән тиресене сизгерлеген киметүче мономолекула №1

Казан шәһәре, Шиһабетдин Мәрҗани урамы, 24 офис 205, т. +7 987 232 08 88

www.resedaodor.com / resedaodor

РЕКЛАМА



Кадерле «Сөембикә» редакциясе!

Минем әни Мария – рус кызы. Ләкин гомере буе татар хатыны булып яшәде, телен, динен белүче татар балалары үстерде.

Шәфкать туташына укып чыкканнан соң, Әтнә районы Олы Мәңгәр авылында әйбәт кенә эшләп киткән белгечне: «Диагнозларны бик дөрес куя, трахома белән интегүче кешеләр күп, безгә җибәрегез әле ул кызны», – дип, Шурабаш авылына күчерүен сорыйлар.

Яңа авылга килгәч, авырулар санын исәпкә алыр өчен әни өйләр буйлап киткән. Әти яшәгән йортка кергәч, фотосурәттә гармун тотып утырган озын буйлы, чибәр егетне күреп, онытылып басып калган. «Булачак кайнанам эндәшкәч, сискәнеп киттем», – дип искә ала иде әни. Шул көнне кичке уенда әти белән танышалар да инде. Әтием Мәликне мулла кызына өйләндерергә теләгәннәр. «Төшемдә бик матур бер кызны кочтым, өйләнмим, көтәм әле», – дип баш тарткан әти. Насыйп эше инде...

Никах укытканда әнигә Мәрьям дип исем кушканнар. Гел татарча сөйләшкәч, аны рус кызы дип белмиләр дә иде. Әни янына күзләрен каратырга алты авылдан, мари ягыннан, Киров өлкәсеннән үк киләләр иде. Кулы җиңел дип мактап, дарулар алып китәләр дә, савыгалар иде шул кешеләр. Авыл җирендә шәфкать туташы бөтен авыруларны да карый инде, күзләрне генә дәвалап булмый. Әни тынычлап ашый да алмый иде, ярдәм сорап ишек шакыйлар. Эшләр өчен уңайлы булсын дип әти аңа өйдә кабул итү бүлмәсе дә ясап бирде. Өйгә терәп, чоланнан гына керә торган ишек ясаганын да хәтерлим. Авырулар урам яктан керәләр иде.

Әни җәй көне сумкасын асып кырда, басуда йөри, укучыларга беренче ярдәм кагыйдәләрен өйрәтү өчен кичен мәктәпкә төшә. Һәр өй саен кереп, чисталык тикшереп тә йөри иде әле. «Мәрьям апа кергәнен күргәч, тизрәк тәрәзә ачып чебеннәрне дә куа идек», – дип искә ала иде авыл апалары. Трахома дигән күз авыруы кечкенә балаларда да күп булды без үскәндә. Күз эченә вак бетчәләр чыга, аларны гел пинцет белән сытарга кирәк, бик авырта торган процедура. Сугыш еллары һәм аннан соңгы чорда да ашарга җитми, әни шул балаларга печенье, ипигә май ягып бирә иде. Шуңа кызыгып, балалар да сабыр итеп түзәләр.



Әти – башыннан ахырына кадәр сугышны үткән кеше. Ике тапкыр бик каты яраланып, Ленинградтан Ладога аша чыккан. Аны Арча госпиталенә кайтардылар. «Ашарына алып килсәң, савыга», – дигәннәр әнигә. Батыр йөрәкле әнием 60 чакрым араны узып, ат белән йөргән Арчага. Бүре көтүләреннән качуларын, качкыннардан котылуларын сөйли иде. Әнинең тәрбиясе әтине аякка бастырды. Ике тапкыр яраланып кайтуында да әти колхоз идарәсендә эшләргә өлгерде. Әтинең сугыштан кайтканы әле дә күз алдымда. Бүләк итеп алып кайткан коңгырт төстәге юбка-кофтадан бигрәк, әнинең кып-кызыл битләрен хәтерләп калганмын. Мич кызуында кызарган алсу битләрен күреп, безнең әни ничек матур дип уйлап куйганымны һич оныта алмыйм...

Әни 94 яшендә вафат булды. Соңгы елларда аяклары йөрмәсә дә, бик күп укыды. Пушкин, Лермонтов шигырьләрен яттан сөйли иде. Бик нечкә матур тавыш белән «Шомыртым» җырын башка-

Фото: www.pixabay.com

ра иде әнием. Яшь вакытларында да шулай булды – әти гармунда уйный, әни бии. Клубка чыккач та, Мәрьям апа бие әле, дип сорап биетәләр иде аны. Кәбестә, гөмбә тозларга, холодец ясарга ул авыл хатыннарын да өйрәтте. Әле дә рәхмәт белән искә алалар аны.

...Гомеренең соңгы елында икебез баскычка чыгып утырдык. Әнигә шигырь сөйлим:

Кайттым әле, әнкәй, яннарыңа.
Исән чакта күреп калыймчы.
Дөнья хәлен һич тә белеп булмый,
Бәхиллегең алып калыймчы...

«Кызым, мин бик риза сиңа, – диде әни шуннан соң. – Саф татар балалары үстерүем белән бик бәхетле мин, күңелем шатлана».

Р. ХӘСӘНОВА.
Казан шәһәре.

«Күршеңнең сиңа күрсәткән хөрмәте һәм синең аңа карата эшләгән яхшылыкларың газиз анаңның сиңа һәм синең газиз анаңа күрсәткән хөрмәтенә тиң», – диелә хәдисләрдә.

«Күршеләр, күршеләр – иң якын кешеләр», дип җырлана җырларда. «Өй салганчы күршеңне сайла», «Күршең үзеңнән яхшырак булсын», «Күршең начар булса, теш сызлавыннан яман» диелә халкыбыз мәкальләрендә.

Аллаһка шөкер, күршеләремнән шулкадәр уңдым. Гөлсинә Нәфыйкова кирәк чакта төпле киңәшен бирүче, ярдәм итүче, авыр чакта юатучы күршем булды. Без 40 елдан артык янәшә яшәдек. Әгерҗе районы Салагыш авылында туып, шунда кияүгә чыгып төпләнеп калган дустым ул. Төп нигезне саклап, шунда балалар, оныклар үстереп яши.

Гади колхозчы гаиләсендә туган Гөлсинә. Җиде сыйныфны тәмамлагач, беркая да китмичә, үз авылында калган. Печәнен чабып, чөгендер басуында эшләп, гектарлаган бәрәңгесен казып, колхозда хезмәт куйган. Авылда балалар бакчасы ачылгач, кече тәрбияче булып урнашты. «Гөлсинә кулында иң елак балалар да тынычлана», – дия торганнар иде. Күз салып йөрүчеләр күп булса да, ике өй аркылы гына яшәүче Муллаянга насыйп була кыз. Татар әдәбияты классикларын да, рус язучыларын да күп укый торган егет иде. Шәһәргә китәргә мөмкинлеге булса да, әти-әнисен ялгыз калдырмады Муллаян. Колхозның алдынгы механизаторы, аннары тәэминатчысы булып эшләде. Бер түбә астында өч буын яшәде алар. «Татулыкта – бәрәкәт», диләр андый гаилә турында. Кайнанасы өч елдан артык хәтерсезләнеп яшәде, кайнатасының сигез ел күзләре күрмәде. Олыларга ихтирам күрсәтеп, соңгы көннәренә кадәр тәрбияләде аларны Гөлсинә. Оныклары да, оясында ни күрсә, очканында шул булыр дигән кебек, әби-бабаларын хөрмәт итеп үстеләр. Муллаян абыйның вафатына 20 елдан артык вакыт үтте. Гөлсинә улы, килене, оныклары белән бергә гомер итә. Кайнанасы-кайнатасына күрсәткән кадер-хөрмәткә үзе дә тиенеп яши хәзер. Ул моңа бик лаек!

Гөлсинә белән сөенечләребез дә, борчуларыбыз да уртак булды. Балаларыбыз бергә үсте. Уналты ел элек 40 яшендә улым вафат булды, 7 яшьлек оныгым ятим калды. Менә шушы авыр хәсрәттә дә мине юатучы, киңәшләрен бирүче – Гөлсинә дустым, аның гаиләсе булды. 30 яшендә каты авырудан ирем вафат булгач, 3 һәм 4 яшьлек балаларым белән тол калдым. Ялгыз кешегә тормыш алып барырга бер дә җиңел түгел. Авылыбыз су астында каласы булганга, безгә күченергә туры килде. Өемне күчерү өмәсендә күршем аш-суны үзләрендә әзерләп, эшчеләрне ашатырга бәлешләргә кадәр пешерде.

Тормышта күп сынаулар үтәргә туры килде миңа. Ике ел эчендә әти, әни, кайнанам, абыем, ирем вафат булдылар. Күргән хәсрәтләр эзсез үтмәде, йөрәк авырулы булып калдым, катлаулы операцияләр кичердем. Шушы иң авыр вакытларымда олы йөрәкле, киң күңелле дустым, күршем Гөлсинә һәрвакыт ярдәм итте. Үзем юкта балаларымны карады, хуҗалыгыма күз-колак булды.

Бик юмарт куллы да әле ул. Умарталарын карагач, балдан авыз иттерми калмады, сыерлары бозаулагач, туганнарын, күршеләрен чакырып, угыз ашы белән сыйлады.

1990 нчы елларда хезмәт хакларын, пенсияләрне тоткарлаган вакытта бурычка алу өчен дә күршеләргә кердек. Бервакытта да борып чыгармадылар, процент та алмадылар. Моның өчен аларга мин генә түгел, күпләр рәхмәтле.

70 нче елларда телевизор да сирәк кешеләрдә генә иде. Муллаян абыйлар йортында күршеләребез, балалар белән җыелып, сериаллар, фигуралы шуу буенча ярышлар карадык. Кич утырып, чәйләр эчеп чыга идек – менә нинди киң күңелле кешеләр.

Авылдашларга, күршеләренә күрсәткән мәрхәмәте өчен Аллаһ Гөлсинәгә бәхетле картлык та насыйп иткән. Оныгы Илнур хаҗга алып барды аны. Халкыбыз йолаларын саклап, дини йолаларны үтәп, өлкәннәрне хөрмәтләп яшәгән мондый балалар, оныклар Гөлсинә өчен генә түгел, авылдашлар өчен дә горурлык. Бу гади, кешелекле гаиләгә мин гомерем буе рәхмәтле. Гөлсинәгә сәламәтлек, бәхетле тормыш, аяз күк йөзе, уңышлар теләп калам.

Фәйрүзә ИСМӘГЫЙЛЕВА.
Теләче районы.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

ЯЛГЫЗ ИТТЕН...

Хатыны турында сөйләгәндә йөзенең балкып китүен, күз карашларының җылынуын, тавышының йомшаклануын мин генә түгел, мөгаен, башка тамашачылар да хәтерлидер. Йөзенә елмаю кунуын! Югыйсә Хәмзә Ильяс улының шактый кырыс кеше икәне экран аша да сизелә иде: аның вазыйфасындагы җитәкчегә башкача мөмкин дә булмагандыр. «Адәм белән Һава» тапшыруының Самара шәһәрендә яшәп ятучы Мингуловлар гаиләсенә багышланган чыгарылышы иде ул.
Бөтен җирдә Лилия Мингулова башкаруында «Мин яратам сине» җыры яңгыраган чак. Тамашачы каршына аны иренең яратуы да алып чыккан дип күңелемә салдым: бу гаилә, бу мәхәббәт тарихын бер язарга иде!
Тик соңгы вакытта Лилия экраннан, сәхнәдән нигәдер югалды. Самарага юлым төшкәч, иң беренче итеп аны эзләп таптым. Лилия МИНГУЛОВА белән ачыктан-ачык сөйләшәбез.



Озаграк җырламаган саен, сәхнәдән читләшәсең, каушау, дулкынлану барлыкка килә.

– Нигә сәхнәдән югалдыммы? Әйе, сәбәбе булды...

Сез беләсез, беренче тапкыр сәхнәгә чыкканда мин әле профессиональ җырчы түгел идем – Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университетын, Венера Ганиева классын 2018 елда гына тәмамладым. Әмма гомер буе җырларга яраттым. Мин генә түгел, ирем дә. Һәр мәҗлес безнең өчен шуңа да бәйрәмгә әверелә иде. Самарага килгән бер генә татар концертын калдырмадык дисәм дә була. Алай гына да түгел, артистлар белән якыннан аралашып яшәдек. Безнең өйдә кемнәр генә кунак булмады! Салават, Венера Ганиева, Раяз Фасыйхов, Фидан Гаффаров, Ләйлә Дәүләтова, Мөнир Рахмаев, Иркә... Кундырып, мунчалар кертеп, ял иттереп җибәрә идек... Кызык яшәп алдык берара. «Тавышыгыз бар, әйдә, берәр җыр яздырып карыйбыз», – дигән сүзне иң беренче булып якташыбыз, баянчы Рөстәм Вәлиев әйтте. Нишлибез дип иремнең күзләренә карадым. Ул каршы түгел иде... Хәмзә бер Казанга барганда, мин дә аның белән утырып киттем. Рөстәм белән очраштык, җырны аның бер танышы фатирында яздырдык. Ярыйсы гына килеп чыкты. Аннан Ләйлә Дәүләтова шалтыратты: «Матур җырлар яздым, берәрсен җырлап карагыз әле», – диде. Мин ризалашуга: «Әйдәгез, клип та төшерик», – дип үгетләргә кереште. «Казан нуры» оркестры җитәкчесе Рәсим Ильясов белән дә үзе сөйләште. «Мин яратам сине» җыры шулай туды... Тәҗрибәм юк – шактый авыр булды. Байтак борчу да китерде – музыка белгечләре тарафыннан тәнкыйть сүзләре яуды гына. Бер үк шигырьгә төрле композитор көй яза ала, әмма бер үк көйгә төрле шагыйрь шигырь яза алмаганын – моның авторлык хокукларын бозу икәнен белми идем. Сара апа Садыйкова кичерсен... Җырны халыкка ишеттерү өчен ротациягә бирергә кирәклеген дә Ләйлә әйтте. Шулай эшләдек тә... Тыңлаган һәркем: «Күптән җырларга кирәк булган сиңа!» – диде. Мондый җылы сүзләр канат куйды, әлбәттә. Әмма күңелдә шик тә бар иде. Җыр, чыннан да, уңышлы булдымы? Бәлки аның көе генә халыкны җәлеп иткәндер? Ә бәлки сүзләре генә җанга үтеп кергәндер? Үземне тагын бер сынап карарга кирәк иде. Ирем гел үзе җырлап йөргән «Ялгыз иттең» җырын башкарырга тәкъдим итте. «Бигрәк моңсу бит», – дим. «Җырла әле, күңелем сизә, аны кабул итәчәкләр, яратачаклар», – диде Хәмзә. Җырның авторлары билгесез, исеме дә, мөгаен, алай булмагандыр.

Иркәм, сине яшьли сөеп йөрдем,
Яшьли сөеп йөрдем мин сине.
Нигә, иркәм, алай иттең –
Гомерлеккә ташлап киттең,
Нигә ялгыз иттең син мине?

Клибы да беренчесеннән азрак бюджетлы булып чыкты. Паркта төшердек без аны. Көз иде. Көн шундый салкын. Суык үзәкләремә үтте – чирләрмен дип курыктым. Чәчне дә үзем генә ясадым, машина көзгесенә карап кына буяндым... Ирем ялгышмады: халык җырын халыкның яратмавы мөмкин түгел иде.

Зур сәхнәгә шулай чыктым. Миңа төбәлгән йөзләгән, меңләгән тамашачы арасында иң игътибарлысы Хәмзә булгандыр. Горурлана иде ул минем белән! Сөенә иде! Казанда каядыр чыгыш ясыйсым булса, эше никадәр тыгыз булса да, гел минем белән барырга тырыша иде. Ә мин, киресенчә, ул залда утырса, уңайсызлана идем...

«Иде» дип сөйләвемә игътибар иткәнсездер инде. Узган елның 11 июнендә иремне җир куенына салдым. Соңгы ун ел тормышым матур әкият сыман иде минем. Әмма бөтен әкиятләрнең дә ахыры бар шул...

Без Хәмзә белән икебез дә Самара өлкәсенең Шентала районы Татар Әбдекие авылында туып-үстек. Ул миннән дүрт яшькә өлкәнрәк. Бер мәктәптә укыгач, бер-беребезне күргәнбездер инде, әлбәттә, әмма уку елларында ук дуслашып йөрмәдек. Якыннан танышкач, өченче класста укыганда нинди кием кигәнемне, чәчем нинди булганны сөйләп шаккаттырган иде. Ни өчен игътибар иткән булгандыр, белмим. Хәмзә мәктәптә бик яхшы укыды, иң көчле укучылардан саналды. Самара университетын, физматны тәмамлады. Авылда аны «бик акыллы», дип сөйлиләр иде. Без кабат очрашканда ул инде армиядән кайткан иде. Минем дә бер айга ялга кайткан чагым. Ул көнне чәйнекне ялгыш төшереп, битемне, аягымны пешердем. Әмма яшьлек бит – барыбер клубка киногa киттем. Хәмзә безнең артта утырды. Сүз катты. Матур киенергә ярата идем – күзе төште, күрәсең. Ә мин борылып та карамадым. Тик ул янымдагы туганым белән сөйләшүдән шәһәргә кайсы көнне китәсемне белергә өлгерде. «Бергә барырбыз», – диюенә җавап та биреп тормадым... Август ахыры иде. Карасам, автобуста, чынлап та, ул да бар. Яныма ук килеп утырды. Сөйләшеп киттек... Ул көнне туган көнгә чакырулы идем – без анда икәү бардык. Тик ул мине озатмады, шуннан ук икенче туган көнгә китте. Кемгә, кая – бер сорау бирмәдем. Әллә ничә кыз белән таныштырдым: бер көн генә бара да, кабат яныма килә. Кызлар үзләре аның артыннан йөри, ә мин игътибар да итмим – бу аның горурлыгына тиде бугай... Буй-сынымның зифалыгы белән мактана алмасам да, артымнан борылып карап кала иделәр. Нindидер сөйкемле сөягем булган, күрәсең. Узган ел, Хәмзәнең үләренә өч ай кала, апаларына бардык. Хатирәләргә бирелеп, апасы иске фоторәсемнәр табып чыгарды. Аңарда безнең үзебез дә күрмәгән рәсемнәр бар икән. Хәмзә шунда: «Яшь чагында чибәр идең, шуңа өйләндем бит инде сиңа», – диде. Уенын-чынын кушып әйтте.

Фото: Анна Арахамия

Әгәр ирең кире кайта дисәләр, ярты гомеремне бирер, җәлләмәс идем.

Без очраша башладык, аннан өйләнештек. Беренче кызыбызны табарга бала тудыру йортына кергәч, студентлар тулай торагындагы комендант, бөтен булган әйберемне покрывалга төреп, бүлмәдән чыгарып куйган. Кайтып керер урын юк! Хәмзә мине бала белән авылга – әниләренә алып кайтты. Сентябрь ае иде, беренче суыклар башланган мәл. Кое суында бала чүпрәкләре чайкап, күкрәгемә салкын тидердем. Температурам кырыкка кадәр күтәрелде. Хәлем юк, баланы били дә белмим... Бер күкрәктән сөт китте. Хастаханәгә эләктек. Үз әнием авылда фельдшер булып эшли иде, шуңа күрә генә безне бала белән аерым палатага салдылар. Аннан соң да аякка басканчы әни тәрбияләде: мине дә, баланы да.

Ике айдан соң гына Хәмзә безне үзе белән алып китте. Кеше почмакларында яшәүләр башланды. Бер йорттан – икенчесенә, икенче фатирдан өченчесенә күчүләр... Җиде-сигез ел эчендә күпме җиһаз шулай ватылып бетте, күпме кеше пычрагын җыйдым... Туксанынчы еллар: кибетләр буш. Әниләр авылдан туңдырып сөт китерәләр – эретеп балага шуны эчерәм, ботка пешерәм. Ите, каймагы, бәрәңгесе – барысы да әниләрдән. Авыр еллар булды ул. Хәмзәне әллә ничә тапкыр Чечняга җибәрделәр. Анысы үзе бер тарих... Ут эченә бара бит – әллә исән кайта, әллә юк...

Самарада иремнең әбисе яши иде. Олы кызыбызны укырга кергән елны аның улы яман шештән үлеп китте. Абыйны җирләргә баргач, әби кулыма ябышты һәм: «Зина, мине калдырма, берүзем яши алмыйм», – диде. Беренче килененең исеме белән дәшә – азрак бутала иде инде. Нәрсә эшләп була – тулай торактагы бүлмәбезгә алып кайттык. Энем дә бездә торган чак. Эшлим дә. Ике ел әбине кечкенә баланы карагандай тәрбияләдем. Аның фатирын ремонтлап күчәргә торганда, иремә бер дусты кредитка өч бүлмәле фатир алырга тәкъдим итте. Аннары инде әкренләп шәһәр читендә җир алдык – йорт төзи башладык. Бик озак төзелде ул. Игезәкләр – улым белән кызым туган иде инде. Олысын мәктәпкә озатам, кечкенәләрен – бакчага, аннан каршы алам. Хәмзә эштән кайтып кермәде, балалар шуңа күрә гел минем өстә булды. Ул Самара өлкәсе ГУВД начальнигы урынбасары вазыйфасына кадәр күтәрелде, полковник дәрәҗәсе алды. Соңгы вакытта Самара дәүләт икътисад университетында административ-хуҗалык эшләре һәм төзелеш буенча проректор булып эшләде, югары математика факультетында укытты. Доцент, физика-математика фәннәре кандидаты иде. Фәнни мәкаләләр язды, китаплар чыгарды. Туган авылы турында китап әзерләү иде хыялы – анысына өлгерә алмады...

Без бу йортта ун ел яшәп калдык. Һәм бер көн эчендә бөтен тормыш җимерелде – барысы да астыөскә килде. Үземнеке генә түгел, балаларның, оныкларның да. Елга кирегә аккан кебек... Өйдән ул үз аяклары белән чыгып киткән иде. Аның сулышы өзелгәнен иртән хәбәр иттеләр, кояш баеганчы исә инде без аны җирләдек. Бер-беребез белән хушлаша да, рәхмәтләребезне дә әйтә алмадык. Гафу да сорап булмады, бәхилләшеп тә. Иң үкенечлесе – шунысы...

Ансыз беренче иртәне гомер онытасым юк. Торып утырдым да: «Балалар, әтиегез киткәнгә өч көнме инде?» – дим... Көн, төн, сәгатьләр – барысы буталды. Бүген чәй эчкәнме, юкмы хәтерләмим. Кулымнан эш төште: бакчага чыгып бер чүп өзәм дә, кире өйгә керәм, өйдә бер чынаяк юам да, кире ишегалдына чыгып китәм... Балаларны борчымас өчен төнлә генә еларга өйрәндем: бөтен кеше йоклап беткәч, бакча артына барам да, шунда үксеп-үксеп елыйм... Мондый стрессларга каршы торырга хәлем калмаган иде, күрәсең. Аңарчы да күпме кичердем бит. Әни озак еллар авырып ятты, әнине җирләп дүрт ай үтүгә, әти урынга калды. Минем TMTV белән хезмәттәшлек турында килешү төзеп йөргән көннәр иде. Әти турындагы хәбәрне алуга, барысын ташлап, Самарага кайтып киттем ул чакта...

Кырык көнгә кадәр Хәмзәнең җаны гел безнең янда булды бугай. Беркөнне барыбыз бергә шушы зур диванда сөйләшеп утырабыз. Икенче катта кинәт утлар кабынды. «И-и, җаным, син мондамы, килдеңме?» – дип, баскычтан менә башлауга, утлар сүнде... Бөтен тәрәзәләр ябык, ә ишекләр кинәт ачыла. Телефоны тик торганнан өстәлдән егылып төшә... Мондый сәер хәлләр еш кабатланды. Төшкә кереп, без эзләгән теге яки бу әйбернең кайда икәнен әйтүләр. «Мин исән!» – дип үзәкне өзүләр...

Кояш һаман да шулай нур сибә, чәчәкләр дә үсә, мин дә инде көләм дә, сөйләшәм дә кебек. Ә ул йөрәктән, күңелдән бер минутка да чыкмый. Башта үземне гаепле санадым – ярдәм итә алмадым, дип. Ниндидер тәмле ризык пешерү дә гөнаһ кебек тоела иде: мин ашап утырам, ә ул җир астында ята. Бөтен затлы савыт-сабамны бәреп ватудан көчкә тыелдым...

Бер-беребезгә бик нык бәйләнгән булганбыз шул. Казанга китсәм дә, барып җиткәнче әллә ничә шалтырата иде Хәмзә, сагына иде... Машинасын җиде айдан соң гына ача алдым – аңа кадәр кулым бармады. Флешкага яздырып алып, рульдә вакытта гел җырларымны тыңлап йөргән икән. Ул флешканы ун ай узгач таптым. Балалар иртән мәктәпкә аның белән бергә чыгып китәләр иде. Алар гел: «Әти көн саен сине тыңлый», – диләр иде.

Хәмзә киткәч кичергән бөтен авырлыкларны сөйлисем дә килми. Балалар миңа, әлбәттә, терәк булырга тырышты. Олы кызым гаиләсе белән шунда ук күчеп килде, көзгә кадәр бергә яшәдек – оныклар да янда булды. Күпләр шулай юата: «Балаларың янә-

шәндә, оныкларың бар, үз-үзеңә бикләнмә, елама», – диләр. Әйе, балалар – янда, ә ир – җанда... Бер кешене икенчесе алыштыра алмаганын үз башына мондый хәсрәт төшмәгәннәр белми, аңламый. Минем кебек югалту кичергәннәрнең берсе дә алай әйтми менә. Вакыт белән бөтен нәрсә онытыла, диләр, юк, алай түгел. Югалтуның зурлыгын тагын да күбрәк аңлыйсың, тагын да күбрәк сагынасың гына... Сиңа инде бернәрсә дә кызык түгел – ниндидер хыяллар белән яшәмисең. Яшәргә мәҗбүр булып көннәр-төннәр уздыруны яшәү дип атап булса... Әйе, балалар янда булмаса, нишләп бетәр идем икән?! Башка нинди генә начар уйлар килмәде... Сыгылып төшәргә дә ярамый: улым белән кызымны укытасым, урнаштырасым бар бит әле. Әби: «Гыйбрәт өчен унга да кара, сулга да кара», – дия иде. Миннән дә авыррак хәлдә калганнар бар бит. Берьюлы ике-өч якын кешесен озатканнар. Алар да түзә... Нишли аласың: язмышыңа язганны күрмичә китеп булмый. Ярый әле без ирем белән азмы-күпме яшәп калдык, ә бит яшь-яшь килеш, кечкенә балалар белән тол калучылар бихисап. Алма кебек матур чакларында, бәхет куенында яшәр мәлдә... «Раббым, бу кайгыны күтәрерлек көч бир!» – дип, үземә генә түгел, аларга да теләк телим. Шуларны уйлагач, берникадәр тынычланасың. Азга гына... Кайчак балалар: «Бераз онытылырсың, йөреп кайтыйк», – дип, паркка алып чыгып китәләр. Күз нигәдер гел парлыларга төшә, өлкән яшьтәгеләргә. Кулга-кул тотынышып, ашыкмыйча гына атлыйлар... Балалар да күрә икән: «Әни, ә нигә сиңа язмаган икән бу бәхет?» – диләр. Аларның да, минем дә күзгә тагын мөлдерәп яшь тула.

Иремнең үлеме яшәү рәвешемне генә түгел, тормышка мөнәсәбәтемне, гомумән, тормыш кыйммәтләрен үзгәртте. «Теге кирәк», «бу кирәк», «фәләннәр шунда барган, минем дә барасы килә», диюләр артта калды. Кием-салымның да артыгы кирәкми икән. Алганнары да шул килеш эленеп тора әнә... Хәсрәт безнең гаиләне берләштерде, бер-беребезнең кадерен күбрәк белә башладык. Авыр чакта Аллаһы Тәгаләгә һәм якыннарыңа гына таянып булганын аңладык. Безгә килгән бу сынау тирә-юнебездәге бик күпләрнең чын йөзен ачты. Мин күрәсе, ишетәсе килгән кайбер кешеләрнең бүгенгәчә кайгымны да уртаклашканы юк. Әйтерсең лә алар кайчандыр түремдә утырмаган, кунакчыллыгымны кабул итмәгән... Хәер, концертларда, сәхнә артында күзгә карап, исәнләшми дә узучылар аңарчы да булгалады. Танымаганга салышып... Мин бит барысын да аңлыйм. Бүген берәүнең дә проблемасын чишә алмыйм, нидер хәл итмим. Әйе, безнең юллар шушы урында аерыла. Киләчәктә алар кисешерме-юкмы, бер Аллаһы Тәгалә генә белә... Әмма бит матур итеп саубуллашу өчен берничә минут кына табарга була?!

Шул ук вакытта моңа кадәр бик якыннан аралашмаган кайбер танышлар, шалтыратып хәлемне белде. Каяндыр бу хәбәрне ишеткәннәр, телефон номерын да тапканнар. Мондый чакта җылы сүз шундый кирәк икән. Ул сүзгә юанып тагын берникадәр яшисең... Яхшылыклары үзләренә кайтсын дип, елый-елый теләк телим. Дөньядагы бөтен кеше миннән борылса да, Аллаһы Тәгаләм генә ташламасын.

Сәхнәгә яңадан чыгарсызмы, дисез... Җырларга дип алган биш-алты җырым ята. Инде авторларыннан уңайсыз... Хәмзәне югалтканнан бирле сәхнәгә бер тапкыр да чыкканым юк әле. Җырлаганым да юк. Хәтта җыр тыңлаганым да... Алай гына да түгел, телевизорны кабызып, ниндидер тапшыру да караганым булмады. «Югалдыгыз, сезнең җырлаганны көтәбез!» – дип, үземә дә бик күп язалар. Ә балалар дин юлына ныклап басарга үгетлиләр. «Дин сиңа күбрәк юаныч бирер», – диләр. Дөрес, дин белән җырны параллель рәвештә алып баручылар да юк түгел татар эстрадасында. Минем иң зур проблемам – Татарстаннан читтә яшәвем. Казанда каядыр чыгыш ясарга чакырсалар да, биш минутлык бер җыр башкару өчен ике көн юлда булырга кирәк. Үзем рульгә утырып, 400 чакрым ераклыкка чыгып китәргә җөрьәт итмим инде хәзер. Хәмзә дә моны рөхсәт итми иде миңа.

Күреп торасыз, ялгыз, үз иркендәге, берәр оешмага кереп эшләмәгән минем кебек җырчылар сәхнәдә озакка тоткарланмый. Репетиция өчен зал, гастрольгә чыгу өчен транспорт, ротация өчен акча табу – боларның барысы да аның үз өстендә. Сәхнә түрендә калыйм дисәң, аерым төркем тупларга кирәк. Ә Самарада мин аны оештыра алмыйм – андый уен коралларында уйнаучылар аз бездә. Казанга – чит шәһәргә барып үз төркемемне оештыру да мөмкин эш түгел. Әллә нигә бер барып кайтып кына, моның белән шөгыльләнә алмыйсың. Ә күченеп китәргә? Балаларымны калдырыпмы? Юк, ирем моңа риза булмас иде... Гаилә минем өчен гел беренче урында булды – ул инде хәзер генә үзгәрмәс. Аерым тәкъдимнәр булса, аларны кабул итәргә менә әзермен. Ә болай мин Татарстанга кирәкмим, яшь чагым булса, минем белән акча эшләргә мөмкин булса, әлбәттә, онытмаслар иде. Аннан шунысы да бар – моңарчы җырлап баемадым, хәзер генә бу шөгыль миңа табыш китерер дип уйламыйм. Сәхнәгә чыгуым күбрәк күңелем өчен, җан рәхәтем өчен иде. Иремне сөендерү теләге дә көчле булгандыр.

...Безнең һәр иртәбез хәзер бер сораудан башлана: «Кем бүген төшендә әтисен күрде? Ничек күрде, ул нәрсә әйтте?» Кызганыч, очрашулар төштә генә шул... Һәм ул яраткан җырларда...

Өннәремдә эзлим урамнардан,
Төшләремдә күреп саташам.
Гомер юлын бергә узмасак та,
Мин барыбер сине яратам!

Гөлнур САФИУЛЛИНА



НАЗЛАРЫМНЫ КИЧЕР – СОҢАРДЫЛАР...



Шундый җырлар була: сүзләре дә, көе дә җаннарны актарып ташлый, башкаручылары да... Айгөл Бариева белән Ришат Әхмәдуллин «Кичер» җырын әнә ничек йөрәккә үтәрлек итеп җырлыйлар! Тыңлаганыгыз бардыр инде... «Назларымны кичер – соңардылар! Язларымны кичер – соңардылар!..» Исегезгә төштеме? Айгөл ул җырны заманында әтисе – Камал театры артисты Шамил Бариев белән дә җырлаган иде әле. Матур хатирәләр саклана... Театр сәхнәсе. Бөтен барлыгыңны сихерли торган музыка аккордлары яңгырый. Зал җыр ритмында тибрәлә... Ла-ла-ла, ла-ла-ла... Җыр канатында күкләргә очасың! Ә бит ул җырның бик кызыклы тарихы бар. Режиссер Дамир Сираҗиев диплом спектакле итеп «Кияү белән кәләш»не сайламаса, спектакль өчен Фуат Әбүбәкерев җыр язарга алынып, Зөлфәт шигыренә тукталмаса, кияү белән кәләшне Шамил Бариев белән Фирдәвес Хәйруллина уйнамаса... Мөгаен, бу җыр тумаган да булыр иде. Әнә никадәр шартлары бар икән!
Инде арабызда Зөлфәт белән Дамир Сираҗиев та, Шамил Бариев белән Фирдәвес Хәйруллина да юк... Җыр тарихын эзләп, Камал театрына – ярты гасырдан артык шул театр оркестрының сәнгать җитәкчесе һәм дирижёры булган, атаклы скрипкачы, композитор Фуат абый Әбүбәкерев янына ашыгам. Күңелдә инде аның «Зәңгәр кыңгыраулар»ы, «Ак вальс»ы, «Ява карлар»ы яңгырый башлый. Сүз уңаеннан, Фуат абый 150 ләп спектакльгә җыр язган кеше ул! Гримерка бүлмәсендә – китаплар, китаплар... Күбесе – шигырь җыентыклары! Ярымачык гардеробыннан төрле төстәге, төрле сурәтләр төшкән, һәр спектакль өчен аерым сайланган галстуклар күзгә чалынып кала. Бүлмәдә күңелнең иң нечкә кылларына кагылып, скрипка, виолончель моңнары түгелгәндәй, флейтаның тылсымлы аһәңнәре ишетелеп киткәндәй була. Хатирәләргә чумып, үткәннәрне сагынып, искә төшерер өчен уңайлы бер мохит. Һәм без кабат «Кичер» җырына әйләнеп кайтабыз...
Дөресрәге, Фуат абый сөйли, мин тыңлыйм.



Эльмира ЗАКИРОВА

Кичер

Назларымны кичер – соңардылар,
Язларымны кичер –соңардылар,
Күзләремне кичер – соң бактылар,
Сүзләремне кичер – елаттылар.
Буш булганы өчен – кулларымны,
Кушылмавы өчен – юлларымны,
Ашыкканы өчен – елларымны,
Ашыкмавы өчен – уйларымны.
Ла-ла-ла-ла-ла-ла...
Барысын да кичер елап-көлеп...
Мин кичергән, гафу иткән кебек.



Фирдәвес Хәйруллина белән Шамил Бариев. 1980 нче еллар.

– ...1980 ел. Режиссер Дамир Сираҗиев диплом спектакле итеп кыргыз драматургы Мар Байҗиевның «Кияү белән кәләш» пьесасын сайлаган. Төп рольләрдә – минем үлеп ярата торган актерларым Шамил Бариев һәм Фирдәвес Хәйруллина. Фирдәвес... Ул дуамал! Ут, өермә инде менә! Түзгән кеше генә түзә аңа! Пьесаны бирделәр. Укып чыктым. «Нәрсә телисең?» – дим Дамирга. «Ну, үзең беләсең бит инде!» – ди. Аңа хәтле берничә спектакльгә музыка язганым бар иде инде. Музыкаль як өчен җаваплы булгач соң... Тирә-юньдә композиторлар да бик күренми иде бит әле ул чакта. Белмим, нишләптер пьесаны укып чыгуга ук эзләнә башладым. Атаклы Хачатурянның кинофильмнар, театрлар өчен язган музыкалары күңелдә яңгырап киткәндәй була... Фирдәвес холкына туры килерлек давыллы булырга тиеш, дим. Шамил дә аңардан ким түгел! Тегесен алып киләм, монысын... Барысы да бата кебек. Тик сизәм: барыбер нидер җитми. Дамирга түгел, Шамилгә! Ул бит җырчы да иде, хисле җырчы! «Үз ягыма кайтсам...» дип, көчле, иркен тавышы белән җырлап җибәрсәме! Гастрольләргә чыкканда, автобуста бөтен белгән җырларны җырлап бара идек. Шамил башлап җибәрә!..

– Җыр кирәк, җыр! – ди Шамил. – Миңа түгел, безгә! – ди...

...Мине Хәлим Җәләлов дуслары белән таныштырган иде. Анда Рөстәм Мингалим, Батулла, Зөлфәт, Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов... Самый акулалар!.. Танышып киттек. Аларның компаниясе шундый итеп бәхәсләшә иде! Шаккатмалы! Аннан шигырь укый башлыйлар. Аеруча Мөдәррриснең ярсып, йодрыкларын төйнәп шигырь укуы күз алдында һаман... Шул чорда Зөлфәтнең «Утлы бозлар» дигән шигырьләр китабы чыкты. Мин аны сатып алдым. Ә менә монысын үзе автограф белән бүләк иткән иде... (Китапның титул битендә Зөлфәт абыйның «Фуат бөегем! Мең рәхмәт сиңа!» дип язылган таныш почеркы ярылып ята. – *Э. З.*) «Утлы бозлар»дагы бер шигыре тынычлыгымны алды бит! «Назларымны кичер – соңардылар» дип, үзе үк җыр сорап тора!

Ике-өч көн үткәч, җырны алып килдем. Җырлап күрсәтәм. Ул чакта әле мондый «япон такталары» юк иде. Скрипка да баян гына... Күрәм: йөзләрендә сөенечле канәгатьлек.

– Уф-ф! Менә булды! – дип, Шамил җиңел сулап куя.

– Булды, булды! – ди Фирдәвес тә. Аннары аптырап калып: – Ә танышканга? Танышканга шигырь юк бит! Монда бит аерылышу... Шамил, әйт инде!.. Без танышканда шул ук җыр булса... Туры килми. Ну, аңлагыз инде, аңа бит икенче сүзләр кирәк! – дип өзми-куймый кабатлый.

– Ә мин анысын каян белим? – дим. Шунда ук бу хәлдән чыгу әмәлен уйлап табам: – Әйдә, Зөлфәткә барып кайтыгыз.

Фирдәвес «үзем барам!» ди. Җыентыкны алды да ялт кына чыгып та китте. Икенче көнне бер сүз әйтми: ләм-мим. Кичкә, репетиция бетүгә, Зөлфәт үзе килгән: «Менә, тыңлагыз, нәрсә килеп чыкты!» – ди вәкарь генә. Мөгаен, ул аны ярты сәгатьтә язып аткандыр инде. Бәясен күтәрү өчен шулай кылануы!

Пафос белән яңа вариантны укый.

Нишләде бу йөрәк, нәрсә булды?
Бар дөньяга кинәт нурлар тулды.
Нигә бөтен дөнья якты шулай?
Якты бәхетемне таптым бугай.
Бар назларым сиңа – гомерлеккә,
Сүзләремнең моңы – сиңа гына,
Күзләремнең моңы – сиңа гына.
Ла-ла-ла-ла-ла-ла...
Бар дөньяга кинәт нурлар тулды,
Нишләде бу йөрәк, нәрсә булды?

Бөтен җан, тән чемерди. Шамил: «Гений! Гений!» – дип кабатлый. Башта танышканда җырлыйлар, аннан – аерылышканда... Еламыйлар гына. Үзләре шулкадәр ихлас һәм матур күренәләр! Алар тормышта да, сәхнәдә дә бер-берсенә хөрмәт белән карыйлар иде. Ә җыр шулхәтле бизәде! Лейтмотивлар белән бит әле... Бу спектакльне уңышым дип саный алам. Чөнки җыр сүзләрен үзем таптым, музыкасын үзем яздым. Премьера көне килеп җитте. Бик ошаттылар җырны. Дамир диплом яклады. Ә кияү һәм кәләш роле Шамил белән Фирдәвесне тагын бер баскычка күтәрде...

Фуат абый тынып калды. Аннары безне әсәрендергән җырны тагын бер кат тыңлатты. Бу юлы аны өчәүләп җырлыйлар: Фирдәвес Хәйруллина кызы Нәфисә, Шамил Бариев кызы Айгөл һәм Фуат абый Әбүбәкерев үзе! Искиткеч! Җыр беренче тапкыр яңгыраганга инде 40 ел үткән, ә ул һаман сәхнәдә, концертларда, кассеталарда... Инде җырны Айгөлнең улы Камил дә үз репертуарына алырга җыена икән.



Җырны тыңлар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.

ТЫЛСЫМЛЫ ШӘРЫК ӘКИЯТЕ

Соңгы елларда СССРның элеккеге союздаш республикалары буйлап сәяхәт итү популярлашып китте. Гаҗәеп матур җирләр күрәсең, телләрен белмим дип тә торасы юк – аралашу бар халык та белгән телдә. Ташкентта, башка төрки телле республикаларда исә без рәхәтләнеп үзебезнең татар телендә дә аңлашабыз.

Советлар Союзы республикалары белән танышуны аклы-каралы совет фильмнарын караудан башларга киңәш итәр идем. Азәрбайҗанның – «Аршин мал алан», Грузиянең – «Отец солдата», Үзбәкстанның – «Ты не сирота», «Об этом говорит вся махалля», «Тахир и Зухра», Төрекмәнстанның «Шахсанам и Гариб» фильмнары... Шулар аша әлеге халыкларның кемлеген, мәдәниятен, гореф-гадәтен, яшәү рәвешен аңлап була.

Төрле төсләр, хуш исләр, тәм-том һәм гаҗәеп бай колорит бары Чорсуда гынадыр кебек!

Мин, Ташкент кызы буларак, туган шәһәрем турында гел сөйләп торыр идем. Үзбәкстан башкаласы Ташкент – изгелек, җылылык, яктылык аурасы чолгап алган шәһәр ул. Үзәк Азиянең иң яхшы оазисларыннан саналуын да әйтергә кирәктер. Бөек ефәк юлында уңайлы урында урнашып, төрки дөньяның ныгытмасы хезмәтен дә үти. Шәһәр буларак, Ташкент турында беренче мәгълүматлар безнең эрага кадәр II гасырда ук күренә башлый.

Ташкент Тянь-Шань тау итәгенә урнашкан, шуңа күрә эссе җәй анда бездәгедән җиңелрәк үтә. Биек агачларның яшеллеге, рәйхан гөлләренең хуш исе җанны иркәли. Яз көне өрек, айва, алмагач, слива, чияләр чәчәк атып утырганда шәһәр ак, алсу төсләрдәге нәфис чәчәкләргә күмелә. Җиләк-җимеш өлгерүгә исә кунакларны һәрчак яңа уңыш белән сыйлыйлар. Сезне әле революциягә кадәрге чордан ук сакланып калган реликтив агачлар һәм скверлар да таң калдырыр. Роза чәчәкләре диңгезенә чумгандай булырсыз. Алла Пугачёваның «Миллион алых роз...» җыры күңелдә яңгырый башлар.

Үзбәкләр олыны олы итә, кечкенәләрне ярата торган халык. Ташкентта узган балачагымны, яшьлек елларымны искә төшерәм дә... Без күпмилләтле зур, тату бер гаилә кебек идек. Безнең подъездда гына да руслар, татарлар, әрмәннәр, уйгырлар, үзбәкләр, таҗиклар яшәде. Бәйрәмнәр, кайнап торган мәхәллә тормышы, традицияләр, шатлыгы-кайгысы – барысы уртак, күршеләр туганнардан да якын иде.

Ташкент – ул табигать бүләге дә, кешеләр тудырган матурлык та. Борынгы шәһәрнең тар урамнары, урта гасырлар архитектурасы, фонтаннар, Сталин конструктивизмы стилендәге биналар, «чал» мәчетләр, заманча иркен проспектлар, гаҗәеп зур чинар агачлары һәм иманнәр, боздай салкын һәм чиста су чылтырап аккан арыклар, чәчәкләр, гөлләр... Беркайда да шундый хисләр гаммасын кичермәссез: барысы да гаҗәеп матур һәм искиткеч тәмле! Үзбәкстанның борынгыдан ук килгән күп гасырлык тарихы «Мең дә бер кичә»дәге шәрык әкиятләрен хәтерләтә.

Урта гасырларда Ташкентны Шаш дип йөрткәннәр, һәм ул уңайлы сәүдә капкалары булып торган. Дүрт су дип тәрҗемә ителгән борынгы Чорсу мәйданы шәһәрнең кәрван өлешенә керү урыны исәпләнгән. Борынгы шәһәр мәйданы IX гасырда ук барлыкка килгән. Базарга инде мең елдан да артык, ул «Эски Жува» мәйданына урнашкан. Сәүдә үзәге – төрле фәрманнар укыла торган урын; сәүдәгәрләр, һөнәрчеләр, фәлсәфәчеләр, галимнәр, авантюристлар, дәрвишләр, гади халык, бергә җыелып, соңгы яңалыкларны белгән, бәяләрне тикшергән, чәйханәдә гәпләшеп утырган. Мәйданда театраль тамашалар оештырылган. Гасырлар дәвамында базар мәйданыннан күп хакимнәр үткән.

Бөек Ватан сугышы елларында башкаладан бергә эвакуацияләнгән атаклы кешеләр базарга азык-төлек алырга йә төрле әйберләрне алыштырырга дип килгән. Атаклы Фаина Раневская шундыйларның берсе булган. Ул Анна Ахматова белән бер фатирга кереп яшәгән дә әле. Маргарита Терехова, Лариса Луппиан шулай ук Ташкентта туганнар. Бүген Чорсу Үзәк Азиянең туристик Мәккәсе санала. Әле хәзер дә Чорсуда «кинначи» – бозымны, сихерне кайтаручылар очрый.

Ташкент гомер-гомергә һөнәрчеләре, архитекторлары белән данлыклы саналган.

Мин сезне рәхәтләнеп Ташкент базарларында йөртер идем! Үзем тукымаларга битараф булмагач, теләсә кайсы хатын-кызга хас сыйфаттыр ул дип беләм. Һәм сезне бик рәхәтләнеп тукымалар базарына алып китәм. Ул шундый зу-у-ур! Казанның ике ипподромы чаклы! Соңгы тапкыр «сандык тукымалары» эзләп йөргән идем. Үзбәкләрдә дә бездәге кебек гадәт саклана: кияүгә чыккан кыз сандыгында бүләккә әзерләнгән ефәк, крепдешин йә шифон тукымалар була. Ә кайбер тукыма кисәкләре йөзәр ел яткан да булырга мөмкин. Ул сандыклар чып-чын хәзинә җыелмасы инде. Мәсәлән, иптәш кызым Николай патша заманыннан калган ике башлы бөркет сурәтле төймәләргә тап булган хәтта! Базарда гаҗәп матур бизәнү әйберләрен дә, урта гасыр керамикасын да очратып була. Әмма антиквариатны Үзбәкстаннан алып чыгарга ярамый, закон тарафыннан тыела.

Иске шәһәрдә махсус икмәк базары да бар. Аннан узганда авыздан сулар килә! Мин сезне шул базарга да алып барыр, яңа пешкән икмәктән авыз иттерер идем әле. Үзбәкләр тормышы икмәк белән тыгыз бәйләнгән. Моңа бәйле күп ырымнар, ышанулар да яши. Мәсәлән, көлчәне (лепешка) ашъяулыкка йөзе белән генә куярга кирәк, аны сындырып куюны гаиләнең иң олы кешесенә тапшыралар. Ипи йорт сакчысы санала. Французлар иртәнге кофены круассаннан башка күз алдына да китермәгән кебек, ташкентлар иртәнге чәйне яңа гына пешкән кайнар көлчәдән башлый. Күпкатлы йортларның һәр ишегалдында пешереп саталар аны.

Ташкентның зәңгәрсудан күк зәңгәрлегенә күчә барган кабатланмас мозаикасы төп декор булып торган. XXI гасырның заманча архитектурасы борынгы биналар

Киңәш: шәхси кунакханәләргә урнашудан баш тарта күрмәгез – рәхәтләнеп җирле халык белән аралашырсыз, бәяләр дә шактый түбән. Зур кунакханәләрдәгегә караганда тәмлерәк тә ашаталар. Андый отельләрне интернет аша табып була.



■ Чорсуда ни генә юк! Хәтта елан тиресен дә табарга була! Ул төрле авырулардан дәвалый, кара көчләрдән, күз тиюләрдән саклый, диләр. Тарихы мең еллар белән исәпләнгән тоз-борыч савытларын каян табар идегез әле!

■ Ә бала бишекләрен?! Йөз еллар элек ничек кирәксә, хәзер дә ихтыяҗ зур аларга.









белән янәшә тагын да матуррак күренә. Иске шәһәрдә XVI гасырда ук төзелгән Кукельдаш мәдрәсәсе бар. XIX гасырда мәдрәсәдән ерак түгел татар мәктәбе ачылган. Татарча китаплар басылган. Сугыштан соң ачылып, узган гасырның 70 нче елларына кадәр Ташкент педагогика институтында татар теле факультеты булган. Мәдрәсәдән ерак түгел татар мәхәлләләре урнашкан.

Үзбәк аш-суы турында зур тәгълиматлар, китаплар язылган. Әбугалисина, мәсәлән, тавык шулпасы белән ничек ашказаны авыруларын дәвалап булганын, хәлсезлек вакытында нинди чикләвек ашарга кирәген тәфсилләп язып калдырган.


Сүз уңаеннан, Ташкентта суны краннан гына да эчәргә ярый: су таулардан килә.

Пылау, шашлык, хасип, нарын, патыр, сомса, юпка, мампар, лагмон, манты, хоним... Барысы да үзбәк ашлары! Һәм аларны санап кына да бетермәле түгел. Җиләк-җимештән елына өч-дүрт тапкыр уңыш җыеп алсыннар әле! Атаклы «Ялла» группасының «На Востоке, на Востоке что за жизнь без чайханы...» дигән популяр җырын кем генә хәтерләми икән?! Үзбәкстанда тәмле итеп пешерәләр, тәмле итеп ашыйлар, һәм бары Үзбәкстанда гына беркайда булмаганча сыйлый беләләр! Хәтерлим, берчак дус кызларым белән атаклы норин һәм варака чучвараны авыз итеп карарга булдык. Шуны әзерли торган кафены эзләп хәлдән таюыбыз истә. Кафе ике урам чатында урнашканлыктан, берәүләр аны Мәликә фабрикасы янәшәсендә дип аңлатты, икенчеләре Тахтапул урамында, дип сүзен бирмәде. Барып чыга калсагыз, шул бер үк бина инде ул, безнең сыман адашып йөри күрмәгез! Ә мин икесенә дә барырга әзер идем инде! Чучвара – кыздырылган пилмән ул, ләкин һич тә бездәгегә охшамаган. Ул зур, итләч. Йомшак төче камырдан ясала. Эчлеге ваклап туралган ит, тәмләткечләр, суган, тоз салып әзерләнә. Фаршны җиңелчә генә томалап пешерәләр. Суганны майда кыздырганнан соң, аңа ит, тәмләткечләр һәм паприка кушалар. Эре итеп бөгелгән пилмәннәр кайнап торган майда кыздырыла. Чучвараны балалар бик ярата.

Шәһәр үзәгендә, «Узбекистан» кунакханәсе янәшәсендә Әмир Тимур музее урнашкан. Аз гына вакыт эчендә дә ул бөтен дөньяга танылып өлгерде. Ташкентка килсәгез, күрми китмәгез. Кул сузымында гына ташкентлыларның һәм килгән кунакларның яраткан кафесы «Уголок». Ул «Цыплёнок табака»сы белән бөтенесен үзенә җыя. Чебешләрне Советлар Союзы вакытындагы кебек итеп шәп рецепт буенча әзерлиләр.

Сынлы сәнгать, гамәли сәнгать музейлары шулай ук дөньякүләм дан алган. Гамәли сәнгать музеенда меңьеллык ефәк фрагментларын, ислам кабул ителгәнгә кадәр үк тукылган келәмнәрне күрергә була. Музейда татар халкының борынгы көнкүреш әйберләре дә урын алган. XVIII–XIX йөзнең атаклы йомшак табанлы читекләре, зәркән бизәнү әйберләре... Кызганыч, безнең музейларда алар сакланмаган. Ә читекләр Бөек ефәк юлы буйлап сәяхәт итеп, Шәрыккача килеп җиткән.

2020 елда Бөек Җиңүнең 75 еллыгы уңаеннан Ташкентта Җиңү паркы һәм Дан музее (Шон-шараф музее) ачыла. Фашизмны җиңүгә үзбәк халкы да үзеннән зур өлеш кертә. Бөек Ватан сугышы елларында Үзбәкстан СССРга фронт узган җирләрдән миллионга якын кеше эвакуацияләнә,



■ Ташкент ул әле фонтаннар шәһәре дә!



■ Алишер Навои исемендәге опера һәм балет академия театрының эчке өлешендәге диварлар милләттәшебез, Үзбәкстанның һәм Татарстанның халык рәссамы Чыңгыз Әхмәрев эшләре белән бизәлгән.



■ Әмир Тимур музее.

шуларның 200 меңнән артыгы әти-әнисез калган балалар була. Ташкент халкы балалар эшелоннарын каршы ала, аларны үзләренә сыендырып, соңгы телем икмәген бүлешә. Борынгы үзбәк мәкале искә төшә: «Болали уй – бозор, боласиз уй – мозор». Ягъни: «Балалы өй – базар, баласыз өй – зират» мәгънәсендә.

30 ел эчендә бәйсезлек яулап, Үзбәкстан ил үсешенең иң югары баскычына күтәрелде.


Үзбәкстанга барырга уйласагыз, төрле чаралар календарена да күз салыгыз. Күңелле бәйрәмнәрнең тамашачысы да, кунагы да булырсыз. «Ефәк һәм тәмләткечләр фестивале», Гамәли сәнгать һөнәрмәндләре бәйрәме, Сабантуйлар... Күп алар!

Ташкентка хәзер туры рейслар ачылды. Самолетка яки поездга билетларны алдан ук алып куеп, кунакханәләргә интернет аша заказ биреп була. Сәяхәт турлары бөтен нечкәлекләренә кадәр уйлап оештырылган. Ташкентның үз стиле, үз йөзе! Күзем йомсам, чәчәкләре-гөлләре, аллы-гөлле келәмнәре, фирүзә гөмбәзләре, мәчет манаралары, тар-тар урамнары, шәфталу, бадам, анарлары, өрек-йөземнәре белән Ташкент күз алдыма килеп баса. Һәм тылсымлы шәрык әкиятенең дәвамын эзләргә кабат Ташкентка ашкына башлыйм. Юк, сөйләү – бер нәрсә, бу искиткеч шәһәрне үзең барып күрү кирәк!

Рәмзия КАШАПОВА

«Үзбәктуризм» пиар бүлеге,
Шөһрәт Йосыпов һәм автор фотолары.

МИЛЛИ РИЗЫК



Норин – бәйрәм ашы. Ул ат итеннән һәм камырдан әзерләнә. Камырны токмач баскан кебек каты итеп басып җәяләр, 6–7 см киңлегендә, 15–20 см озынлыгында катламнарга кисәләр. Кайнап торган шулпада пешереп, ашъяулыкка җәеп суыталар. Аннары аларны үсемлек мае белән майлап, берсе өстенә берсен куеп, пешкән камырны нәзек кенә токмач итеп кисәләр. Ат казылыгын һәм ат итен сүрән утта пешерәләр, шулпага суган, эре кишер салалар. Шулпада пешкән итне алып, шулай ук юка гына итеп кисәләр. Токмач озынлыгы белән салам кебек телеп киселгән ит бер чама булырга тиеш. 2 өлеш иткә 3 өлеш токмач туры килә. Аннары барысын кушып болгаталар. Борыч сибеп, өлеш тәлинкәләрендә табынга бирәләр. Өреле шулпа аерым бирелә. Норинны шулпага салып та ашыйлар.

Норин әзерләү шактый мәшәкатьле, шуңа аны гадәттә туйларга, юбилейларга, аеруча тантаналы вакыйгаларга гына әзерлиләр.

«ЙӨРӘГЕМ БЕЛЕП САЙЛАГАН»



Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк Галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән? Сүзне аларга бирик әле.

ИлГӘРӘЙ (Илназ Гәрәев), җырчы; гаилә стажы – 11 ел; балалары – Адилә (10 яшь); Камилә (6 яшь).

1 Иң элек хатын-кызның сез нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Айгөлне беренче тапкыр күргән мизгелне бүгенгедәй хәтерлим. Студент чагым. Фоат абый Галимуллин мине «Ягымлы яз» фестиваленә катнашырга җибәрде. Муса Җәлилнең «Төрмәдә төш» дигән шигырен сөйләргә тиеш идем. Баскычтан төшеп барганда янымнан зур гына күзле бер кыз узып китте. Бу күзләргә игътибар итмәү мөмкин түгел иде... Сәхнәдән чыккач аны тагын очраттым. Телефон номерын да таптым. Тик әле ул чакта ватсаплар юк, ә минем «смс»ларыма ул җавап бирмәде. «ВКонтакте» социаль челтәре популяр вакыт. Башта мин аны шуннан озак кына эзләдем. Ниһаять, таптым! Әмма ул мине дуслыкка кертмәде. Аның уе укуда гына булуын соңрак аңладым. Мин аның йөрәген ике ел яуладым. Диплом алыр вакытым килеп җиткән иде инде, тагын юлыма очрады. «Сәлам!» – дип исәнләштем. Дәшми узар дип уйлаган идем, ә ул елмаеп җавап кайтарды! Икәү кафега кереп чәй эчтек. «Нигә миңа бер тапкыр да җавап бирмәдең?» – дип сорадым. «Чын ирегет башта кызның янына килеп исәнләшергә тиеш», – диде ул. Аның тәрбиясе шундый.

2 Хатын-кызның кайсы сыйфатларын гафу итәргә була?

– Безнең арада да төрле хәлләр булды. Каты гына сүзгә килгән чаклар да. Савыт-саба ватып ук түгел, әлбәттә... Өйләнешүгә, кем өйдә хуҗа икәнен ачыклау башланды. Син моны эшләргә тиеш, дигән сүзләр яңгырады... Без ул вакытта Айгөл белән бер нәрсәне аңладык: бер-береңне ишетә белү кирәк икән. Тыңлау белән ишетү арасында аерма бик зур шул... Тагын бер аңлашылмаучанлык булды. Анысы – бала тугач. Мин ул чакта концерт-гастрольләрдән, банкетлардан кайтып кермәдем. Ә Айгөл кызыбыз белән гел дүрт стена арасында... Мин аңа бәйрәмдә генә йөргән кебек тоелдым. Җырчыга кияүгә чыкканын белә иде, моңа әзерләнде дә, әмма бу кадәр авыр буласын күз алдына китермәгән, күрәсең... Мин ул вакыт эшне түгел, гаиләмне беренче урынга куярга өйрәндем: өйдәгеләреңә мәхәббәтеңне күбрәк бүләк итсәң, алар да сиңа шулай җавап бирә. Канатларың ачыла – эштәге проблемалар да җиңелрәк хәл ителә.

3 Ә нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Бу сорауга төгәл җавап бирә алмыйм. Бәлки, хыянәттер... Хатын миңа хыянәт итәргә мөмкин, дигән уй башка да кергәне юк анысы. Кайчак Айгөлгә: «Сез менә идеаль гаилә, ничек шулай яшисез? Иремнең телефонын актарган идем, шундый «смс»ка тап булдым, нишләргә икән?» – дип шалтыраталар. Хатын да, ир дә беркайчан бер-берсенең телефонына рөхсәтсез кагылырга тиеш түгел дип саныйм мин. Бер гаилә булсагыз да, шәхси әйбер ул. Аннан телефондагы кайбер язулар аркасында күңелегездә әллә нинди фантазияләр туарга мөмкин. Анысына барыбыз да оста. Кавышкансыз икән, бер-береңә ышану, хөрмәт кирәк. Айгөл шалтыратучыларга: «Син – хатын-кыз, түземрәк булырга тиеш. Иреңнең күбрәк яхшы яклары турында уйла», – дип җавап бирә.

4 Хатын-кызлар икегә бүленә: ир-атны илһамландыручы алиһәләр һәм өйдә аның өчен комфорт тудыручы хуҗабикәләр.

– Айгөлдә аларның икесе дә бар! Кайчак эштән бик нык ярсып, ачуланып кайтып кергән көннәр була. Ул моны күрүгә аңлый, әмма берни дәшми. Каршы алып, киемемне элеп куя да: «Бар, телевизорыңны кабыздым, залыңа кереп тор», – ди. Берәр сәгатьтән тынычланам, суынам, ул арада аш бүлмәсеннән тәмле исләр чыга... «Матурым, әйдә, ашап ал», – дип чакыра ул. Минем тамак туйгач кына, шаярткан булып: «Бик дулкынланып кайттың, бер-бер хәл булдымы әллә?» – дип сорый... Андый көннәр Айгөлдә дә очрый. Мин исә ишекне ачуга: «Нәрсә булды?» – дип сорыйм. Ул шунда ук сөйли башлый. Хатын-кыз сөйләргә ярата. Бу вакытта киңәш бирмим әле, тыңлыйм гына – бушансын. Аннан кочаклап, үбеп алам: «Ярар, матурым, андый хәлләр була инде», – дим. Чәй эчәргә утырабыз – борчулар онытыла.

5 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Була ала! Дөресен әйтсәм, Айгөл минем өчен дус та, хатын да, сөяркә дә. Элек әти-әнигә сөйләгән булсам, хәзер

бөтен серемне хатынга ачам, аның белән киңәшләшәм. Ул мине бөтен кешедән күбрәк белә. Безнең өйдә булган проблемалар беркайчан тышка чыкмый: әти-әниләргә сөйләмибез. Юк, без дә моны сөйләмәскә кирәген башта ук аңламадык. Әни кеше үз баласын гафу итә, ә менә киленне (кияүне)... Хатыныңны әниеңә сөйләп, аны әниең каршында дошманга гына әйләндерәсең. Хатының үзенекеләргә белгертсә, ул да шул ук ялгышны кабатлый. Дус кызларга да ачылырга ярамый. Арага апалар кергән гаиләләр бар. Алар киңәш бирергә ярата, үзләренең бәхете булмаса – бигрәк тә. Ничек кенә авыр булса да, юк, сөйләргә ярамый: бөтен нәрсәне өйдә, икәү генә хәл итеп бетерергә кирәк.

6 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме әле?

– Кайбер адымнарны алдан уйлап түгел, кинәт эшләп куя торган гадәтем бар. Тәкъдим ясаганда да шулай булды. Кинодан соң машинада кайта идек. Кыш иде бу – Яңа ел алды. «Айгөл, матурым, әйдә, июльләргә өйләнешик», – дидем аңа. Ул сүзсез калды, югыйсә инде ике ел очраша идек. «Укып кына бетерәм, эшкә дә урнашмаган бит әле», – ди. «Риза», – дигән сүзне икенче көнне генә әйтте. Шундый иде Айгөл! Ул миңа үптермәде дә. Ике елдан соң гына беренче тапкыр үптем мин аны. Шуңа күрә гомергә истә дә калды – 16 апрель иде. Гомумән, 16 саны белән күп нәрсә бәйле безнең. 16 ноябрьдә аның туган көне. 16 июльдә кавыштык. Туй вакытында Кремльгә фотосессия ясатырга кердек. Каршыбызга ат килә, өстендә – 16 саны! Үзебез дә шаккатып, бу хакта видеооператорга сөйлибез, үзебез шул минутта, стена янына басып, фотосурәткә төшәргә әзерләнәбез. «Ә сез кая басканыгызны беләсезме, өскә карагыз әле», – диде ул елмаеп. Карасак, баш өстебездә 16 саны!

Кыз сорарга әти белән әни генә түгел, Гайшә әби дә барды. Әнинең әнисе ул. Балык Бистәсе районы Чирмешән авылыннан. Туксанынчы елларда ук Казанга күчкән иде. Гомер буе хат ташучы булып эшләгән – кеше белән сөйләшә белә. Барысы да татар халкының йолалары буенча башкарылды: Айгөлнең әнисе, бернәрсәдән хәбәрдар булмагандай: «Нишләп йөрисез?» – дип сорады. «Оныгымны башлы-күзле итәргә иде», – дип җавап бирде Гайшә әби. «Иртәрәк түгелме икән?» – дип, булачак әби каршы төшеп маташты. «Нәкъ вакыты!» – дип Гайшә әби аны «ризалатты»... Без өйләнешүгә, әти белән әни, фатирны безгә калдырып, үзләренә йорт салдылар. Никахлар алып барганда: «Үз балаларыңа булышу оят түгел, – дим. Аннан өстим: – Алар синең кадер-хөрмәтне тойганда оят түгел...»

7 Ир кеше хатын итеп әнисенә охшаган кызны сайлый диләр, шулаймы?

– Нәкъ шулай! Дөрес, йөргән вакытта мин аны үзем аңламадым. Йөрәк сайлаган! Сөйләшүләре, аралашулары, көлүләре, йөзләре – барысы да охшаш аларның. Уртак телне дә бик тиз таптылар. Кайчагында икәү мине сөйләп тә алалар. Сөйләсеннәр, мин каршы түгел. (*Көлә.*)

8 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар...

– Безнең гаиләдә андый хәл булганы бар. Кыенсынганымны хәтерләмим... Тормышта төрле ситуация булырга мөмкин: акча бүген бар, иртәгә юк ул. Без бит гаилә! Девизыбыз шундый: «Айгөл – бүген, ә мин иртәгә нәрсә ашыйсыбыз турында уйларга тиеш». Әмма... Пандемия башлангач, сигез ай эшсез утырырга туры килде, һәм ничек кенә тырышсам да, акча запасларым бетте. Ә Айгөлнең хатын-кыз зирәклеге безне коткарды: аның күпмедер җыелган акчасы бар иде – шуңа яшәдек.

9 Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип саныйсыз?

– Айгөл белән йөргәндә беркайчан да аңа үземне булганымнан әйбәтрәк итеп күрсәтергә тырышмадым. Югыйсә очраша башлаганда гел тәти булып кына күренәсе килә бит. Ә өйләнешкәч кинәт яңа якларың «ачыла»: нинди начаррак гадәтләрең бар, барысы да калкып чыга. Ә хатын-кыз сине бөтенләй башкача дип белеп, кияүгә чыгарга ризалашкан була... Ике арада проблемалар шуннан да башлана. Ул сине нинди бар, шул килеш яратырга тиеш. Син дә – аны.

10 Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?

– Киенүемә *(көлә)*. Яңа костюмымны күреп: «Бу сиңа килешә!» – дисеннәр. Мин бит костюмнар кияргә яратам. Татар эстрадасында бик күп җырчылар минем костюмнарны кабатлый.... Гардеробымда иллеләп костюм бар. Әмма аларның барысын да тамашачы күреп туйган инде... Бүген менә кабат дизайнер белән очрашабыз: яңа сезонга ике-өч яңа костюм кирәк. Мәрхүм Рәшит абый Шамкай гел: «Сәхнәгә чыккансың икән, ботинкаң ялтырап торсын, чәч каралган булсын», – дия иде. Хатын-кызның күзе иң элек шуларга төшә.

11 Ир-атны артык чибәр һәм көчле хатын-кызлар куркыта, диләр. Бу, чынлап та, шулаймы?

– Юктыр, алай түгелдер. Хатыным менә кеше күзе төшәрлек чибәр, һәм аның минем янымда булуы белән бик горурланам. Башка ир-атларның үземә көнләшеп караулары ошый, шундый чибәр хатын-кыз яныннан каядыр бару...

12 Шундый очракны күзаллыйк әле: сез ачыгып, арып-талып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән...

– Андый көннәрдә хатынның гына түгел, балаларның да кәефе булмый әле ул... Тик мин нишләргә икәнен яхшы беләм: барысы да ишетерлек итеп: «Пиццага заказ бирәм, кемниндине ашый?» – дим. Барысы да елмая башлый. Йокларга яткач кына: «Матурым, кәефең юк иде, берәр нәрсә булдымы әллә?» – дип сорыйм... Үзем нәрсә пешерә беләммe? Йомырка! Тагын бәрәңге! Пилмән! Юк, ясамыйм, әзерне суга салып пешерә беләм. Күптән түгел ютубтан карап пылау пешерергә өйрәндем әле менә.

13 Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә.

– Без беркайчан да бер-беребезгә әйтмичә, сорамыйча бүләкләр алмыйбыз. Бүләкне дөрес сайламасаң, акчаны бушка сарыф итү генә була бит ул. Быел 35 яшьлек юбилеема Айгөл сюрприз ясады: бөтен туганнарны җыйды. Алдан белсәм, ризалашмас идем – рестораннарны бик яратмыйм: минем өчен эш урыны бит алар. Ә туганнар белән күрешү ошады – онытылмаслык очрашу, минем өчен бәйрәм булды.

Тулысынча укыгыз »





Кыз баланың балигълык чорына аяк басуы аның үзе өчен генә түгел, әти-әниләре өчен дә катлаулы вакыт. Кайчагында кызының сәламәтлеге өчен әниләр баланың үзеннән дә ныграк борчыла. Бигрәк тә яшүсмернең күрем циклы башлану тоткарланса яки төрле тайпылышлар белән узса. Бу аңлашыла да, хатын-кызның сәламәтлеге балачактан ук формалаша. Әлеге четерекле һәм яшерен тема хакында Республика балалар клиник хастаханәсенең табиб-гинекологы Лилия ХӘЙРУЛЛИНА белән сөйләшәбез.

КЫЗЫМ ИНДЕ ЗУР ҮСТЕ...

Кыз балаларда балигълык чоры 11–15 яшьләрендә башлана. Менструаль цикл тулысынча урнашып җитсен өчен тагын бер-ике ел вакыт узарга тиеш. Бу вакытта әле кыз баланың җенес гормоннары тиешле күләмдә түгел, күрем килүенең тоткарлануы, төрле тайпылышлар белән килүе әнә шуның белән аңлатыла. Беренче елларда күрем унар көн, хәтта аннан да күбрәк килергә мөмкин. Баштагы ике елда бу хәл табигый, аның өчен борчылырга кирәкми. Ләкин мондый халәт ике елдан да озагракка сузылса, күрем циклы нормальләшмәсә, ул чагында инде баланы гинекологка күрсәтергә кирәк. Ул махсус тестлар белән тикшереп, организмдагы үзгәрешләрнең сәбәпләрен ачыклый. Организмда тумыштан килгән тайпылышлар һәм төрле шешләр булмаса, гормоннарга тикшерү үткәрелә. ВСГ, ЛГ, пролактин, ТТГ, Т3, Т4, ДГЭА-С, 17-ОНП, АКТГ, тестостерон, кортизол дәрәҗәләре билгеләнә. Функциональ гормональ пробалар дифференциаль диагностика үткәрү максатыннан алына. Ихтыяҗ булса, кыз баланы эндокринолог, терапевт, невролог, психологка юллыйлар.

Күрем циклын җайга салу өчен күп очракта гәүдә авырлыгын нормага китерү генә дә җитә. Тиеш дип тапса, балалар гинекологы цикллы витаминнар курсы, үсемлекләр нигезендә ясалган тынычландыручы препаратлар, гомуми чирләрне дәвалауга юнәлтелгән препаратлар, эндокрин системасындагы тотрыклылыкны тәэмин итү өчен гормоннар билгеләргә мөмкин. Гормоннар белән дәваланырга дигәч, күпләр куркып кала. Организм өчен зарарлы йогынтысыннан шикләнәләр. Әйе, гормоннарны дөрес итеп билгеләү бик мөһим. Дөрес сайлаганда һәм гормонның күләмен контрольдә тотканда, әлеге терапияне озак еллар буена дәвам итәргә була. Ул күрем циклын җайлап кына калмый, сөт бизләрендәге төрле шешләрне, аналык ялкынсынуын, күкәйлектәге кисталарны да кисәтә. Яшүсмернең бит тиресе чистара, чәчләре матурлана. Чөнки боларның барысы өчен дә шул ук гормоннар җаваплы.

ТАБИБ КИСӘТӘ: күрем булмау хатын-кызның гомере өчен куркыныч тудырмый, ләкин киләчәктә әни булу бәхетеннән мәхрүм итәргә мөмкин. Вакытында табибка күренеп, бу тайпылышларны төзәтеп була әле, соңга гына калмаска кирәк.





Кыз баланың сәламәтлеге өчен мөһим:
- сәламәт яшәү рәвешен тәэмин итү;
- тиешенчә туклану;
- гәүдә авырлыгы аз булганда калорияләргә баерак ризыклар ашау;
- йокы режимын саклау (яшүсмерләр кимендә 8 сәгать йокларга тиеш);
- көч җитәрдәй генә физик күнегүләр белән даими шөгыльләнү (иртәнге зарядка, йөзү, фитнес).

Диагностика чаралары:
- эчке органнарга УЗИ үткәрү;
- калкансыман бизне тикшерү (кирәк дип табылса, бөер өсте бизләре дә тикшерелә);
- баш миенең гипофиз өлешендә шешләрне инкарь итү өчен контрастлы КТ яисә МРТ үткәрү;
- генетик тикшеренү;
- гормоннарга анализ һәм функциональ пробалар алу.



Фото: www.pexels.com

Күрем циклы бозылуның физиологик сәбәпләре:
- начар экология шартлары;
- гаиләдәге даими низаглар, баланың психологик киеренкелектә яшәве;
- нәселдәнлек (әнисендә күрем соң башланса, кызында да бу кабатланырга мөмкин);
- баланың уку һәм иптәшләре белән бәйле стресс кичерүе;
- чамадан тыш физик көчәнеш, спортның бокс, каратэ, авыр атлетика, көрәш ише авыр төрләре белән шөгыльләнү;
- баланың алҗу халәтендә яшәве;
- дөрес тукланмау, ризыкта кыйммәтле матдәләрнең җитешмәве, минераллар һәм витаминнар кытлыгы;
- организмда матдәләр алмашы бозылу, артык авырлык.



Безнең бөерләребезгә бик зур вазыйфа йөкләнгән: алар канны чистартып, андагы барлык калдыкларны үзләренә ала һәм бәвел белән бергә организмнан чыгара. Бөерләр – кешенең яшәве өчен беренчел кирәк булган парлы орган. Гадәттә, алар аша тәүлегенә 1700–2000 литр кан уза һәм 1,5–2 литр бәвел бүленеп чыга. Үтә дә мөһим саналган әлеге органнар эшләмәсә, кеше гомере өчен куркыныч туарга мөмкин. Татарстан Респуликасы Сәламәтлек саклау министрлыгының баш урологы, Республика клиник хастаханәсенең 1 нче урология бүлеге мөдире Булат ШӘЙХРАЗЫЕВ белән бөер чире – гидронефроз хакында сөйләшәбез.

ГИДРОНЕФРОЗ

Бөерләрдәге касә-лакан системасының киңәюен гидронефроз дип әйтәләр. Ул иң элек бәвел бүленеп чыгуның тоткарлануы белән билгеләнә. Гидронефроз – халык арасында шактый киң таралган чирләрнең берсе. Бөерләре авыртып, табибка мөрәҗәгать иткән балаларның 15 процентына шушы диагноз куела. УЗИ ясаган вакытта ул хәтта әнисе карынындагы балаларда да күзәтелә. 20–40 яшьлекләрдә исә бу сан 1 процентны тәшкил итә. Ир-атларга караганда, авыручылар арасында хатын-кызлар бер ярым тапкырга күбрәк. Кырыктан өлкәнрәк кешеләрдә исә гидронефроз ниндидер башка бер авыруның да билгесе булырга мөмкин.

Аның тумыштан булган яки яшияши барлыкка килгән, бер яклы яисә ике яклы төрләрен аералар. Шулай ук кискен (кинәт башланган) һәм хроник формасы да очрый. Дәваланмаган очракта, хроник гидронефроз аркасында пиелонефрит башланып, хәлнең тагын да катлауланувы ихтимал. Аеруча ике бөернең дә берьюлы зарарлануы куркыныч.

Гидронефроз һәрвакыт бәвел бүленеп чыгу юлында ниндидер каршылык булганда барлыкка килә. Шуның аркасында бәвел, бөерләргә тупланып, аның касә-лаканнарын киңәйтә, бөер эчендәге басым артып, паренхималар (бөернең төп тукымасы) сытыла. Мондый каршылык бәвел бүленеп чыгу системасының теләсә кайсы участогында күзәтелергә мөмкин. Күп очракта гидронефрозның ниндидер аерылып торган билгеләре булмый да. Пациентлар ешрак бил авыртудан зарланып килә.

Диагнозны, әлбәттә, табиб кына куя. Төгәллек өчен, УЗИ, кан һәм сидек анализы билгеләнә, компьютер томографиясе уздырыла. Гидронефрозны ачыклауда соңгысы төп тикшеренү ысулы булып тора.

Дәвалауга килгәндә, ул чирнең дәрәҗәсенә һәм бәвел бүленеп чыгуның никадәр тоткарлануына бәйле. Иң беренче максат: җыелган бәвелне чыгарып, бөерләргә булган басымны киметү. Шул рәвешле бөерләрнең сафтан чыгуы кисәтелә. Соңыннан инде гидронефрозга китерелгән башка сәбәпләр юк ителә.

Билгеләре:

- дизурия – кече йомышны кыенлык белән башкару;
- сирәк кысталу;
- бил тирәсендә авырту тою;
- бәвелдә кан булу;
- бәвелнең төсе тоныклану.

Сәбәпләре:

- бәвел юлында ташлар;
- бәвел юлының тараюы;
- ирләрдә мәни бизенең ялкынсынуы (простатит);
- корсак куышлыгындагы төрле шешләр;
- йөклелек (бу очракта ниндидер дәва чаралары таләп ителми, бала тапканнан соң ул үзеннән-үзе бетә);
- аналык төшү;
- мускуллар зәгыйфьлеге аркасында бәвел капчыгының һәм сидек юлларының торышы үзгәрү.



БУ МӨҺИМ:

Симптомнарсыз гына узучы гидронефроз тормыш өчен куркыныч тудырырга мөмкин. Озакка сузылган патологик процесслар аркасында бөерләрнең тулысынча эштән чыгуы ихтимал.



БАКЧАДА – СЕНТЯБРЬ

Бакчада тып та тып сентябрь алмалары коела. Сентябрь ул – җәйдән көзгә күпер. Бакчаларда әле җәй гөлләре кояшта иркәләнә, ләкин табигать ритмының инде сүлпәнләнгәне сизелә. Тик көз җитте дип, бакчаларда эш тукталмый. Безнең ритм әле шул ук – утыртабыз, чәчәбез, җыябыз, алабыз...

Чәчәкләр яратучыга

Август ахырыннан алып сентябрь урталарына кадәрге вакыт – чәчәк сөючеләрнеке. Күпьеллык чәчәкләрне күчереп утырту өчен моннан да кулайрак чакны табуы кыен. Кояш инде артыгын кыздырмый, туфракта дым бар, көннәр җылы. Иң нәзберек гөлләр дә сентябрьдә күчереп утыртуны яхшы кичерә.



Дельфиниумнар яратсагыз, хәзер аларны бүлгәләп, яңа урынга утырта аласыз. Төпне казып алып, тамырчаны берничә өлешкә бүлгәләгез. Алар җиңел аерыла. Утырткан вакытта дельфиниумны тирән күмдерергә ярамый, су сипкәннән соң, тамыр муентыгы җир белән бертигез булсын.

Розаларны күчереп утыртырга теләсәгез, сентябрь урталарыннан да калмагыз. Башта куакны кыскартып кисегез. Розаны сак кына туфрагы белән бергә казып алып (су сипсәң, моны башкаруы җайлырак), тамырларын чокырдагы туфрак өеменә җәйлап салыгыз, мул итеп су сибегез. Су сеңгәч, туфрак белән күмдерергә була. Элек ничек үскән булса, шул тирәнлектә генә утыртыгыз. Тагын бер тапкыр яхшылап су сибегез дә, тамыр бикләгәнче бераз күләгәләп, үсемлекне тынычлыкта калдырыгыз. Ара-тирә чама белән генә сугарыгыз.

Сентябрь – беренче кыраулар ае да. Кызганыч, бакчабызның күрке булган чәчәкләр беренче кырауларга кадәр генә яши... Георгиннарның бүлбеләрен казып алуны сузмагыз, өшесәләр, аларны саклап булмаячак. Барысын да кояшта яхшылап киптереп, төсләренә туры килә торган җеп белән тамгалап куегыз. Киләсе язда бу сезнең эшегезне күпкә җиңеләйтер. Бүлбеләрне коры ком яисә пычкы чүбенә күмеп, базда яки идән астында саклау отышлырак.



Гладиолус суганчаларын исә сабаклары саргаеп, чәчәк бөреләре атып бетергәннән соң казыйлар. Иртәрәк казып алсагыз, суганчалар әле өлгереп җитмәгән булырга мөмкин.

Агачлар



Сентябрь ае – агачларның озын кышкы тынлык чоры алдыннан көч җыяр вакыты. Менә шуның өчен дә агачларның уңышын вакытында җыярга, озаграк торган саен, тәмлерәк дип, кара көзгәчә калдырмаска кирәк. Сортына карап, җимешләрнең өлгерүен ачыклавы кыен түгел. Моннан тыш, сентябрь урталарыннан агач һәм куакларның тамыр системасы интенсив үсә башлый. Көз коры килсә, бу вакытта аларны тиешенчә сугарырга онытмагыз.

Уңышларны җыеп алганнан соң, яфраклар әле коелганчы, агачларны мочевина белән эшкәртү яхшы нәтиҗә бирә. 1 чиләк суга 500 г мочевина алына, аңа 700 г хлорлы калий да кушарга була. Ләкин соңгысын башта кайнар суда җебетергә кирәк. Әлеге чара агач һәм куаклардагы гөмбәчек авыруларын, корткыч бөҗәкләрдән сакларга булыша. Көннәр кояшлы торганда агачларның кәүсәләрен бакча өчен махсус эмульсияле буяу белән кышка агартып калдырсаң яхшы. Яз көне бу аларны ярылудан саклаячак, чөнки иртә язда кайсыларыбыз гына бакчага барып кәүсәләрне агартып йөри алыр икән?!

Куаклар



Кура һәм карлыганнарның карт, корыган ботакларын да сентябрьдән дә калмый киссәң әйбәт. Салкыннар башланганчы кискән урыннар җөйләнеп өлгерергә тиеш. Гадәти кураның ике еллык ботаклары гына уңыш бирә. Болар – быел җәйдән үсеп чыгып, көзгә кадәр ныгыган ботаклар. Ә җиләк биргәннән соң, алар корый. Менә шуларны кисеп, куралыкны чистартабыз. Кискәндә төпләр тырпаеп калмасын! Соңыннан куакларны бер җыемга җыеп, җиргә яткырып бәйләп куябыз. Болай эшләсәгез, аңа салкыннар да, кыш көне сыйланырга дип бакчага кергән куяннар да куркыныч түгел.

Сентябрь ахырында бакчага яңа агачлар утырту эшенә керешергә була. Тик ике-өч атна алдан чокырын әзерләп куярга гына иренмәгез. Сатып алган үсентеләрнең тамырын утыртыр алдыннан берничә сәгатькә суга тыгып торырга кирәк. Бу аларны сыгылмалырак итәчәк.

Кара карлыган үсентеләрен 10–15 см чамасы күмдерәләр. Ботакларын кыскартып кисүне язга калдырсаң, яхшырак. Быел утырткан карлыган дүрт елдан соң гына тулы куәтенә уңыш бирәчәк. Ел да үсеп чыккан ботакларның бары тик өчесен, иң көчлеләрен генә калдырыгыз.

Фото: www.pexels.com

ХАНБИКӘЛӘР СЫНЫ

Буй-сынның төз булуы хатын-кызлар өчен үтә әһәмиятле. Иңбашлары төшеп, башын алга сузып, бөкрәеп йөргән кеше үзенә ышанмаган, уңышсыз, бәхетсез кеше тәэсире калдыра. Ә тышкы кыяфәт, үз-үзеңне тота белү җәмгыятьтә бик зур роль уйный. Төз итеп, горур йөргән хатын-кызлар игътибарсыз калмый, аларга тартылалар. Бәхетсез кыяфәтле кеше белән кемнең аралашасы килсен? Бөкрәеп йөрү тирә-юньдәгеләр белән аралашуга гына түгел, сәламәтлеккә дә зыян сала. Бу гадәттән арыну өчен, арка мускулларын ныгытырга кирәк, чөнки умыртка баганасы алар нык булмаганлыктан деформацияләнә. «Һәр иртәне махсус күнегүләрдән башларга һәм көн дәвамында сынның туры булуын контрольдә тотарга кирәк», – ди проектыбызның даими тренеры Резеда МУСИНА.



1 «Йөзүче». Корсакка ятабыз да, кулларны алга сузып, бармак очларын идәнгә тигезәбез һәм булдыра алган кадәр җилкәне идәннән аерабыз. Сулыш чыгарганда, чиратлаштырып, әле бер кулны, әле икенче кулны артка җибәрәбез. Суда йөзәм дип күз алдыгызга китерегез.



2 «Мәче сырты» ясыйбыз. «Дүрт аякка» басабыз. Сулыш алганда умыртка баганасын өскә таба бөгәбез, сулыш чыгарганда – аска таба. Бу күнегү умыртка баганасын тарттырыр өчен бик тә файдалы. Мәчеләр йокыдан уянгач, юкка гына иң беренче эш итеп сыртларын кабартмый.



3 «Көймә». Кабат корсакка ятабыз, кул-аякларны сузабыз. Сулышны алганда аякларны һәм җилкәне идәннән аерабыз, кулларны ян-якка җибәрәбез. Сулышны чыгарганда элекке халәткә кайтабыз.



4 Стенадан этеләбез. Туры итеп бөгеләбез дә учлар белән стенага тотынабыз. Бу вакытта аяклар һәм умыртка баганасы бераз бөгелергә тиеш. Шул рәвешле 10–15 секунд басып торабыз.



5 «Фәрештә». Аякларны тездән туры итеп бөгеп (тез капкачы аяк очлары тигезлегендә), стенага терәләбез. Умыртка сөяге, бил, баш чүмече стенага тиеп тора. Кулларны ян-якка җәеп, терсәктән туры итеп бөгәбез һәм аска-өскә күтәрәбез. Куллар стенадан аерылмый.



6 Арканы бөгәбез. Корсакка сузылып ятабыз да, куллар төзәйгәнче гәүдәне күтәрәбез. Шул халәттә 10–20 секунд торабыз. Бу күнегүләрнең һәрберсен 10–15 тапкыр ясыйбыз. Арка мускулларыгыз ныгыр да, бөкрәеп йөрүне онытырсыз.

QR-код аша кереп, күнегүләрне видеодан да карап ясый аласыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Бакча коралы тәртип ярата

Сентябрь – бакчаларның бушап калган чоры. Суганнар күптән алынган, кыяр-помидорлар тозланган. Кишерләр, чөгендерләр, кәбестәләр ныгыр өчен салкын көннәрне көтә торсын, ә без бакча коралларын кайгыртыйк. Көрәк-тырма, сәнәк-себеркеләрне сарайда сакларга гадәтләнсәгез дә, анда да аларны тәртип белән тезеп, һәммәсенә урын билгеләүгә ни җитә?! Беренчедән, аларны рәткә китерү урынны бушата; икенчедән, бер урыннан алып, шунда ук кире куярга гадәтләнәсең. Яз көне яңадан аларның урак өсте башланачак бит. Кыш чыгуларын алдан кайгыртып, сарайны тәртипкә китереп куярга кирәк хәзер. Тирә-юньне оештыру остасы Лилия ШӘРӘПОВА – ике кыз әнисе. Белгечлеге буенча инженер-технолог булса да, декрет ялында үзенә иҗади шөгыль тапкан ул. Кием киштәләрен, аш бүлмәсе шкафларын тәртипкә китерергә яратуы әнә шулай яңа һөнәрле итә Лилияне. Аның киңәшләре бакчасы булган һәр кеше өчен файдалы булачак.

Алсу ШАКИРОВА әзерләде.
Фото: Алсу ШАКИРОВА.





■ Арбаларны вертикаль рәвештә тоткычлары белән өскә бастырып сакларга киңәш итәм. Болай эшләгәндә арба аз урын ала. Тоткычларын иске резин каеш белән беркетеп куярга, арбаны аскы яктан агач балкага эләктереп куярга була.



■ Вак эш коралларын – кайчылар, җир йомшарта торган әсбапларны элеп сакларга җайлы. Элмәк урынына иске тырма кулланырга да була. Яисә элек өйдә кулланган иске элмәкләрне кадаклап куегыз. Инструментларның элер җире булмаса, аларга элмәк рәвешле баулар беркетеп куярга була.



■ Гадәттә саплы бакча кораллары күп урын ала, терәтеп куйган җирдән авып китә. Аларны йә тегендә, йә монда онытып калдырабыз. Шуңа күрә көрәкләр, сәнәкләр, себеркеләр, тырмалар өчен дивар кырыенда бер урын оештыру уңайлы булыр. Шул рәвешле аларны алырга да, кире элеп куярга да җайлы. Сарайдан чыга торган урынга якынрак урнаштырсагыз, отышлырак та булыр. Мондый җайланма эшләр өчен иске төпсез чиләкләр дә, ПВХ торбалар да, лак, буяудан калган тимер савытлар да ярый. Чиләкне урталай кисеп, буяп, уңайлы җайланма көйләргә мөмкин. Тагын бер вариант бар: фотода күрсәтелгәнчә, көрәкләрне элеп куяр өчен агач киштә ясарга була. Бакча коралын киштәгә урнаштырыр алдыннан балчыктан чистартып, кайрап куйсагыз, тагын да яхшырак булыр.



■ Су шлангыларын җыеп куяр өчен иске көпчәк дисклары – уңайлы вариант. Шлангыны аларның эчкә таба уелып торган ягына чорнап куегыз. Шулай эшләсәгез, шлангылар буталмас та, өзелмәс тә. Диск урынына чиләк, табак та кулланырга була. Аларның эчендә су сибүдә кулланыла торган вак-төяк кораллар сакларга мөмкин.







■ Вак әйберләр өчен сарайда тартмалар тотарга киңәш итәм. Мәсәлән, перчаткалар, пумалалар, шлангы башларын, орлык савытларын бүлгәләп, кечкенә үтә күренмәле контейнерларга салып куегыз. Һәр тартмага язу беркетсәгез, тагын да уңайлырак булыр. Кайсында нәрсә салынганын бутамассыз. Мондый контейнерларны 49 сумга да алырга була. Сусипкеч, чиләк, гөл савытларын сарайга кертеп куйсагыз, салкынны яхшырак кичерерләр, ярылмаслар. Аларны тезеп куяр өчен иске аяк киеме киштәләрен дә кулланырга була.

■ Вак бакча коралларын шулай ук комлы савытта сакларга була. Зур булмаган чиләкләргә, буяу савытларына ком салып куйсагыз, түтәлләр янында эшләгәндә коралларны шунда кадыйсыз да куясыз. Берсе өстенә берсе менеп тормый, таралып та ятмый. Үз янында тотарга да, күчереп йөртергә дә җайлы. Комга җитен мае салып куярга кирәк. Шул рәвешле кораллар тупасланмас, пычрак ябышмас, күгәрмәс.



Мәһәр ашы



Артур КАҺИРОВ – татар егете. Үзбәкстан җыелма командасы футболисты буларак, карьерасын тәмамлагач, тренер булып эшли башлый. Утыз елдан артык Ташкент шәһәрендә яшәгәннән соң гаиләсе белән Казанга күченеп кайта. Бүген Артур Казанның «Мотор» балалар спорт мәктәбендә малайларны футбол серләренә өйрәтә. Ташкентта яшәү дәверендә гаиләсе белән бик күп милли ашлар пешерергә өйрәнгән. Гаеп, Нәүрүз бәйрәмнәрендә урамда казан асып, тәмле ризыклар, пылау, ашлар пешереп, күршеләрен сыйлап, бәйрәм итә торган гадәтләрен Татарстанга да алып кайткан яшь гаилә – ишегалдында казан асып, дусларын, туганнарын, күршеләрен үзбәк ашларыннан авыз иттерә. «Бүгенге сыебызны – мәһәр ашын туйларда пешерәләр, – ди Артур. Аның тарихы да ике язмыш кавышу – кыз сорарга килү мизгелләренә барып тоташа. Яучылар килгән йортта киңәш барганда пешерә торган булганнар бу шулпаны. Туй мәшәкатьләре, бирнә нечкәлекләре хәл ителгәч, булачак кодаларны озак кайнаган, куе булып пешкән аш белән сыйлаганнар. Сентябрьнең соңгы кояшлы көннәреннән файдаланып, бакчагызга казан асыгыз әле. «Мохара шурва кылабыз!»

Кирәк

- 400 грамм суда тоткан нут борчагы;
- 2 баш суган;
- 500 грамм ит (сарык ите дә, сыер ите дә ярый);
- 2 помидор;
- 2 аш кашыгы томат пастасы;
- 150 грамм татлы борыч;
- 100 грамм кишер;
- 2 литр су;
- тәменчә тоз, зира, кориандр;
- бизәр өчен яшел үләннәр.





Эш барышы

■ Нут борчагын төнгә җылы суга салып калдырабыз. Суы борчактан ике тапкыр күбрәк булырга тиеш.

■ Казанга май салабыз.

■ Эре итеп туралган итне казанга салып кыздырабыз.

■ Ит янына ярым түгәрәкләп туралган суган салабыз да бераз кызартабыз. Тоз өстибез.

■ Ит белән суган янына помидор белән томат пастасын салып, барысын бергә 3 минут кыздырабыз.

■ Казанга нут борчагын салабыз, 2 литр тирәсе су өстибез. Шулпа кайнап чыккач, күбеген җыеп алабыз. Тәменчә тоз кушабыз.

■ Эре итеп туралган кишер һәм татлы борычны шулпага салабыз.

■ Уч төбендә уып, зира, кориандр өстибез. Сүрән утта 3 сәгать пешерәбез.

■ Табынга яшел үлән һәм туралган суган салып чыгарабыз.



Видеоны карар өчен смартфонның камерасын QR-кодка якынайтыгыз.
Фото һәм видео: Анна Арахамия.



Баклажан согы

Күзге менюга баклажанны ничек кертмисең инде?! Әзерләгәндә күп май сеңдергәнгә, беренче карашка бу яшелчә дөрес туклануга һич туры килми кебек... «Әмма аның файдасы шулкадәр күп, баклажан, һичшиксез, сезнең рационда булырга тиеш», – ди дөрес туклану рубрикасының даими авторы Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА. Ул безгә баклажаннан сок ясарга киңәш итә.



Баклажаннан диетик ризыклар әзерләүнең сере – аны аз май кулланып, парда, духовкада яки мультиваркада пешерү.

100 грамм баклажанда нибары 25 калорий бар, ләкин шул ук вакытта анда клетчатка күп, ул организмдагы шлакларны, артык сыеклыкны чыгарырга булыша. Баклажан – аксымга бай яшелчә, аны аз углеводлы диета рационына да кушарга рөхсәт итәләр. Ябыгырга теләүчеләр дә баклажанны үз менюларында куллана ала. Баклажан согы да артык килограммнардан котылырга булыша. Бу яшелчә составында сапониннар – файдалы кушылмалар бар, алар табигый юу чарасы хезмәтен үти: май молекулаларын җимереп, аларның организмга үтеп керүеннән коткара.

Сокның файдасы

- Баклажан согында клетчатка булу метаболизмны көчәйтә һәм эчәкләр эшчәнлеген яхшырта.
- Баклажан согы тиешле күләмдә натрий һәм калийга бай, ә алар йөрәк һәм нерв системасы эшчәнлеге өчен кирәк.
- Канда шикәрне арттырмау сәбәпле, диабетиклар өчен дә файдалы.
- Шәп антиоксидант, яшелчә составына антоцианнар һәм Е витамины керә, алар исә йөрәк авыруларыннан һәм яман шешнең кайбер төрләреннән саклый.
- Сөяк тукымасы өчен бик кирәкле булган фолий кислотасы йөкле хатыннар өчен аеруча файдалы: яралгының дөрес үсешен тәэмин итә ул.
- Бавыры белән проблемалары булган кешеләргә файдалы.
- Магний һәм тимергә бай. Ә бу исә анемияне булдырмый калырга, иммунитетны күтәрергә булыша.

Баклажан согы

• 1 зур баклажан; • ярты литр су; • 1 лимон согы кирәк.

Баклажанны кабыгыннан чистартырга кирәкми, чөнки нәкъ менә кабыкта атоциан кебек бик әһәмиятле булган антиоксидант бар: ул яман шеш күзәнәкләрен җиңәргә, картлыкны кичектереп торырга булыша.

Яшелчәне вак шакмакларга турап кәстрүлгә салырга, өстенә су агызырга һәм бер-ике сәгать төнәтергә кирәк. Аннары кәстрүлне капкач белән каплап, утка куярга. Кайный башлау белән лимон согы өстәгез. Ул тәмне яхшыртачак, С витаминына баетачак.

Катнашма 15 минутлап кайнасын. Аннары, суытып, баклажанны суы белән бергә блендерда ваклыйлар. Иләк аша үткәрәләр. Мондый күләмдәге сок бер көнгә генә исәпләнгән. Һәр көн саен яңасын әзерләргә тырышыгыз.

Килеп чыккан сокны өч тапкыр кулланырлык итеп бүләргә һәм диета дәвамында ашар алдыннан 15 минут кала, көнгә өч мәртәбә эчәргә кирәк.

Әфлисунлы баклажан согы

• Бер чирек чистартылмаган баклажан; 1 стакан су; 1 әфлисун.

Баклажанны телемләп кисеп, биш-алты сәгатькә бер стакан суга салып калдырыгыз. Аннары баклажанны шул суы һәм бер әфлисунның согы белән блендерда ваклагыз.

Холестерины югары булган кешеләргә әфлисунлы баклажан согын ач карынга көн саен эчәргә киңәш итәләр. Бу артык авырлыктан котылу өчен дә менә дигән чара. Әмма ул дөрес туклану зарурлыгыннан һәм спортзалга йөрүдән азат итми.

Игътибар! Әгәр сез көн саен әфлисундагы һәм кишердәге А витаминын, бу витаминга бай башка продуктларны күп дозада кулланасыз икән, артык витаминнар файдага түгел, зыянга эшли башлый! Витаминнар артык күбәеп китү сөяктәге кальций һәм кан күзәнәкләрендәге калий югалуга сәбәп була, гемоглобинны киметә, кан китүләр, буыннар авырту, мигрень, тиренең корылыгы һәм кубырчыклануы күзәтелә, тырнаклар уалучанга әйләнә Шуңа күрә чаманы онытмаска кирәк!

Фото: www.pixabay.com

Сөмбелә хатын-кыз

Сөмбелә йолдызлыгында туган хатын-кызлар – югары интеллектлы, үз-үзен тота белүче, тирәннән уйлап эш итүче ханымнар. Икейөзләнә белмиләр, ышанычлы, тыныч кешеләр. Сөмбелә үзенә дә, башкаларга да таләпчән. Юкка да тиз борчыла башлый. Энергияләре ташып тору сәбәпле, максатларына ирешә беләләр. Күбрәк бертөрлелек яраталар, аларга консервативлык хас. Сөмбеләнең хөрмәтен яулар өчен, тырышырга кирәк булачак.

Мәхәббәт. Сөмбелә уңышлы, төшенкелеккә бирелми торган, шаккаттыра белүче ирләрне сайлый. Мәңгелек мәхәббәт вәгъдә итүче ирләргә дә ята күңеле. Ирдәге юмор хисен, үз фикерен әйтә белүне дә бәяли белә. Эмоцияләргә саран, хисләрен белдерә белмәүче ирләргә борылып та карамый.

Мөнәсәбәтләр. Сөмбелә романтик зат түгел. Мөнәсәбәтләрдә ягымлы һәм назлы булырга тырыша, ләкин бу һәрвакытта да барып чыкмый. Сөмбеләгә аны якларга сәләтле кайгыртучан ир кирәк. Кабынып китүчән булуына карамастан, йөрәгенә ачкыч таба алган кеше белән җылы, ышанычлы мөнәсәбәтләр урнаштыра. Хаталарны гафу итә белми, озак үпкәли торган гадәтләре бар.

Гаилә. Сөмбелә – искиткеч хуҗабикә. Тугры, ихлас тормыш иптәше. Гаилә булдыруга омтыла, никахтан идиллия өмет итә. Балалар үстерүдән тәм таба, алар һәрвакыт беренче урында булачак. Ләкин балалар өчен җаваплылыкны тулысынча үз өстенә алачак дип уйламагыз, иренә дә үз өлешен кертергә туры киләчәк.

Йолдызнамә октябрь

Кучкар. Сәламәтлек ягынан уңышлы булса, эш ягыннан катлаулырак чор булыр. Кайчандыр игътибарсыз калдырган мәсьәләләр сәбәпче моңа. Җайлап, төгәл эшләсәгез, барысы да уңай чишелер. Нинди карар кабул итәргә туры килсә дә, яхшылап уйлагыз.

Үгезбозау. Бар әйберне дә үз өстегезгә алмагыз. Мондый активлык сәламәтлегегезгә зыян килү белән тәмамаланырга мөмкин. Сабыр төбе сары алтын, диләр. Тиз кабынып китүдән сакланыгыз. Дуслар, туганнар белән очрашыгыз, күптән өзелгән араларны җайлар өчен бик уңай вакыт.

Игезәкләр. Янәшәгездә ышанычлы дуслар булса, сезгә берни куркыныч түгел. Сәламәт яшәү рәвеше алып бара башларга, спорт белән шөгыльләнүне яңартырга теләсәгез, нәтиҗәле, дәвамлы адым булыр. Мәхәббәт һәм романтика өчен дә менә дигән вакыт.

Кысла. Төшенкелеккә бирелеп китүегез бар. Ләкин яңа проектлар планлаштыру тормыш энергиягезне арттырыр. Айның беренче яртысында сәламәтлегегезне ныгыту белән шөгыльләнегез, икенче яртысында башлаган эшләргә әйләнеп кайтырга да була, киеренкелек халәте кимеп китәчәк.

Арыслан. Дәртегез дә, дәрманыгыз да ташып торыр. Ләкин максатка ирешү өчен күп кенә киртәләр узарга туры килер. Иң мөһиме – туктап калмагыз, барысы да сез уйлаганча булачак. Сынаулар холкыгызны гына ныгытыр. Янәшәдә шикле кешеләр барлыкка килеп, зыян салмасын, игътибарлы булыгыз.

Сөмбелә. Үз-үзегезне кулда тотыгыз, алтын урталыкны табарга тырышыгыз. Октябрь сезнең өчен гади генә ай түгел. Көн үзэгендә – гаиләнең матди иминлеге. Акча мәсьәләсендә күбрәк үзегезгә ышаныгыз.

Бизмән. Айның беренче яртысында нык һәм кыю булырга кирәк, шул рәвешле барлык киртәләргә дә каршы тора алырсыз. Алга таба шактый гына сынаулар үтәргә туры килер, мөмкинлекләрегезне дөрес бәяләп, әзер торсагыз, җиңел генә җиңеп чыгарсыз. Әзер булып тору – ярты уңыш.

Чаян. Стрессларга каршы тора алучы иң көчле йолдызлык астында туган кеше буларак, бу айда сезне бернәрсә дә какшата алмас. Бераз гына ял алып, шәхси тормышыгызны үзәккә куегыз, мавыгуларыгызны искә төшерегез. Уңышлы эшләрегез генә алга барыр. Барып чыкмастаена вакыт та әрәм итмәгез.

Укчы. Планлаштырган эшләрегезне айның беренче яртысында эшләп калырга ашыгыгыз. Гаилә мәсьәләләрен чишәр өчен, кыйммәтле әйберләр алыр өчен бик уңай вакыт. Айның икенче яртысы борчулы булса да, көтелмәгән очрашулар, тәкъдимнәр алып килер.

Кәҗәмөгез. Профессиональ даирәгә кереп чумарсыз. Максатка ирешү өчен кеше башыннан йөрүгә үк барып җитүдән тыелыгыз. Ләкин кулларны төшерергә, бирешергә дә кирәкми. Ниятегезгә тугры калыгыз. Бу чорны сәяхәттә, ялда уздырып җибәрсәгез, тагын да яхшырак булыр.

Сукояр. Бер адым – алга, ике адым артка барган кебек тоелырга мөмкин. Ләкин иң мөһиме – туктап калмаска. Сез барган юл барыбер җиңүгә алып киләчәк. Элеккеге мәсьәләләрне чишәр өчен бик яхшы мөмкинлек барлыкка килер.

Балык. Үзгәрешләр чоры башлана. Ләкин моның өчен уңайлылык зонасыннан чыгарга кирәк булыр. Рухи яктан да карашларыгызны үзгәртерсез, бәлки. Тормышыгызда конфликтлы вазгыять барлыкка килергә мөмкин, дусларыгыз-туганнарыгызга таянсагыз, барысын да җиңел генә үткәрерсез.

«Хатын-кыз галәме» сәхифәсен Алсу ШАКИРОВА, Чулпан ГАЛИӘХМӘТОВА, Лилия ГӘРӘЕВА әзерләде.







ГАҖӘЕП ОСТАЛЫК

Киндерләргә майлы буяулар белән язылган картина өсләкләрен пыяла белән капларга туры килгән аңа. Чөнки тромплёй ысулындагы әсәрләрне шулай итеп кенә тамашачылар кызыксынуыннан саклап буладыр. «Нишләтәсең, ул шундый ысул инде, – ди рәссам. – Борынгы Римда ук уйлап табылган әлеге ысул XVII гасыр сынлы сәнгатендә бик алга киткән. Һәрбер әсәрнең буяу катламы калынлыгы, ягъни «корпусы» рәссамның темпераментына турыдан-туры бәйле: кемдер аларны бик юка катлам белән яза, кемдер калын һәм тупасрак итеп... Ә мондый картиналар сурәтнең тирәнлеге бик нык тоемланырлык булып һәм иллюзияләр килеп чыгарлык калынлыкта иҗат ителергә тиеш, әмма аларны иҗат иткәндә рәссамның холкы әллә ни зур роль уйнамый. Чөнки мондый әсәрләр язганда ул яктылыкның әйбер шәүләсен килешле итеп күрсәтүен, тукымада җыерчыклар булуын, якты тапларның көчәйтелүен дә исәпкә ала. Рәссам китапларны, тәбрикнамәләрне, юл карталарын тасвирлаганда, ышандырырлык чынбарлыкка туры китерү өчен еш кына өслеккә бармак эзләрен, су тамчыларын, кителү, кыршылуларны да бик тә килешле итеп сурәтли». Рәссам Рамил Шаһидуллинның бу аңлатмасы аның үз картиналарында, яссы өслектә күләмле мохит иллюзияләре сурәтләнгән хезмәтләрендә дә ярылып ята. Рамил Сәлимхан улы иҗат иткән натюрмортларга күз салсак, анда «җанлы», куларга алырдай әйберләр бихисап: ярмалар, чәчәкләр, җиләк-җимешләр... Рәссамның осталык дәрәҗәсе хакында картиналары үзләре сөйли! Ул аңа гына хас тыйнаклык белән: «Мондый натюрмортларны башка рәссамнар да яза ала, ләкин аларны иҗат итү өчен әлеге рәссам аерым психотипта булырга тиеш: киндердәге сурәтләрне җентекләп язарга ярата торган, ашыкмаучан холыклы, сабыр...» – дип аңлата.

Рамил Шаһидуллин балачактан ук рәсемнәр ясаган, гимнастика буенча җитди ярышларга барырга, балалар сынлы сәнгать мәктәбендә укырга да өлгергән. 1984 елны Казан сынлы сәнгать училищесын тәмамлап, Түбән Кама Сынлы сәнгать фондында унбиш ел эшләгәннән соң, 1995 елда гаиләсе белән Казанга күченгән. «Кызыбызның яхшы музыкант булып үсеп җитүен теләдек. Чыннан да, Әдилә – альтта иң яхшы уйнаучылар рәтендә, музыка буенча докторлык диссертациясен яклады, АКШта яши. Ә олы кызыбыз Алинә Санкт-Петербургтагы А. Л. Штиглиц исемендәге дәүләт сынлы сәнгать-сәнәгать академиясен тәмамлады, шул шәһәрдә дизайнер булып эшли, хәләл җефетем Жанна да – талантлы рәссам», – ди ул.

Рамил Сәлимхан улы байтак еллар буе Казан галереялары белән хезмәттәшлектә. Рәссамның талантына сокланучылар аның шәхси күргәзмәләренә дә бик теләп килә. «A la prima» галереясында узган «Гади әйберләр», «Филадельфиядә һәрчак кояшлы!» шәхси күргәзмәләреннән соң, ул үзенең тагын бер күргәзмәсен, АКШтан чакыру алып, Филадельфия шәһәрендәге шәхси галереяда да ачкан.

Рамил Шаһидуллин һәр көн яңа картиналар иҗат итүдә. «Кайчак гаҗәеп төшләр керә миңа, – ди оста. – Имеш, зур музей заллары буйлап барам. Анда бик күп картиналар... Мин аларга сокланып, боларны кайсы рәссам ясаган икән дип уйлыйм. Чөнки аларны чын тормышта күргәнем юк. Кайсыберләре янына якын ук килеп, рәссамның исемен укырга телим... Әмма уянып китәм. Һәм бар күргән картиналар шул мизгелдә үк онытыла. Аңлыйм: алар башка язу ысулларында, төрле стильләрдә. Төрле жанрдагы картиналарның никадәр җиңеллек белән иҗат ителә алынуына гаҗәпләнәм!»

Әлеге талантлы рәссам әсәрләрендәге реализм, төрле төс һәм төсмерләр матурлыгы кемне генә сокландырмас! Ә инде тирә-юнь мохит, шәһәрләр сурәтләренә карагач, без үзебезне шул дөньяда итеп тоябыз. Рамил Шаһидуллин әсәрләреннән аңа бик тә хас игелек, кояшлы күңел күтәренкелеге, позитив караш бөркелә.

Зилә НИГЪМӘТУЛЛИНА









РАМИЛ ШАҺИДУЛЛИН





ӘЙДӘГЕЗ, ХАТЛАР ЯЗЫЙК, ЯҢА ДУСЛАР ТАБЫЙК, БӨТЕН ДӨНЬЯ ТАТАРЛАРЫ БЕЛӘН БЕРЛӘШИК!

Хатлар йорты – открыткалар җибәрү сервисы



16+

ООО «Медиа – партнёр» Адрес: 420066, г. Казань, ул. Декабристов, д. 2, пом. 14, ГРН 1111690004469. Реклама